# Казан утлары

сентябрь
№ 9
1966

## *Кадерле иптәшләр!*

*„Казан утлары“ журналына язылу, бүтән еллардан аермалы буларак, быел 1 сентябрьдән 25 ноябрьгә кадәр генә кабул ителә.*

*Журналга мөмкин кадәр иртәрәк язылырга онытмагыз. Бу төрле аңлашылмауларга юл калдырмас, журналның үз вакытында, төгәл килеп торуына ярдәм итәр.*

РЕДАКЦИЯ.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

*КЫРЫК БИШЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА*

## Бу санда:

ПОВЕСТЬ. ПЬЕСА. ШИГЫРЬЛӘР

Х. Сарьян. Әткәм һөнәре. Повесть. Ахыры . . . 3
Г. Хуҗиев Таныш күзләр, таныш карашлар. Шигырь. 40
Ш. Хөсәенов. Зөбәйдә — адәм баласы. Трагикомедия . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
Р. Гатауллин. Лирик сөйләшүләр. Шигырьләр . 86

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

А. Хәсәнов. Яшь наратлар. Хикәя . . . . . . . 93
Б. Хәлимов. Кереш сүз; Таң букеты; Мәхәббәтем турында монолог; Иркәлә, бәгырем; Күзләр хушлашканда; Мендәң дә син Урал тауларына; Йолдызларны көндез күзләмә. Шигырьләр . . . . 98

ДУСЛАР ҖЫРЫ

Бездә кунакта Ленинград шагыйрьләре . . . . . . 102

Ш. РУСТАВЕЛИНЫҢ ТУУЫНА 800 ЕЛ

Ш. Руставели. Автандилның күк яктырткычларына ялваруы. «Юлбарыс тиресе ябынган батыр» шигъри романыннан . . . . . . . . . . . . . . . . 106

ОЧЕРК

Г. Сабитов. Һәр нигезнең тарихы бар . . . . . . 108
Ш. Максудова. Башкортстан белән очрашу . . . 113

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ф. Хатипов «Ихтыярсыз» геройлар һәм кырыс дәреслек . . . . . . . . . . . . . . . . . 117

9

СЕНТЯБРЬ
1966

КПССның
ТАТАРСТАН ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

Х. ФӘЕЗХАНОВНЫҢ ТУУЫНА 145 ЕЛ

М. Госманов. Олы мирас . . . . . . . . . 124

ФИКЕР АЛЫШУ, БӘХӘСЛӘР

Г. Халит. Бер бәхәс уңае белән . . . . . . . . 133
Х. Зәбиров. Тукайның тәрҗемәи хәле хакында берничә сүз . . . . . . . . . . . . . 138

СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ

А. Файнберг. Художникның эзләнүе . . . . . 139

ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА ШАГЫЙРЬ

Р. Гәрәй. Шагыйрьнең иҗат шатлыгы . . . . . . 142
Юбилярларны котлыйбыз . . . . . . . . . . . . 144

КИТАП КҮЗӘТҮ

Э. Касыймов. Кояшны каршылап . . . . . . . 146
В. Суркова. Мөслимдә шулай эшлиләр . . . . . 149
Яңа китаплар . . . . . . . . . . . . . . . . 152
Укучылар сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . . 156
А. Ключарев. Онытма. Җыр. Н. Дәүли сүзләре.

*Редакциягә килгән кульъязмалар кире кайтарылмый*

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

ХӘСӘН САРЬЯН



# ӘТКӘМ ҺӨНӘРЕ

С. КУЛЬБАКА рәсемнәре.

*Повесть*[1]

## Уникенче бүлек

Локман карт эсседә башына яулык бәйләп эшли: ул аны өскә шуып менмәсен өчен, маңгай астыннан ук бәйләп куя, яулык читеннән ике күзе генә кысылып күренеп кала; көн буена әкрен генә чыккан маңгай тире күзгә агып төшми, яулыкка сеңә барып, маңгаена рәхәт салкынлык биреп тора иде. Күлемгә туктаган саен ул аны киптереп ала, һәм һәрвакыт, яулыгын чишү белән, колак өстеннән карандашы төшеп китә иде. Ул беренче көнне үк Гаязга да яулык бәйләргә киңәш итте.

— И, күлмәгеңне дә салып эшләргә өйрән. Тәнең кояшка янсын, карайсын. Егетләргә шалкан төсле тән килешми.

Гаяз күлмәген салса да, яулык бәйлә дигәнгә, «Ярый болай да», — дип, кул гына селтәде. Барысы да яулык бәйли башласа, илла мәзәк булыр иде тегеләй!.. Ул ялан баш кына эшләргә булды. Барак салучылар да әнә ялан баш эшли, бер Кави гына кепкасын батырып кигән иде.

— Син аларга карама, — диде төпчек абзыйсы. — Тир түгеп эшләмиләр алар. Көн узсын дип кенә эшлиләр.

Ул өй салуның акчасын гына түгел, үзен дә сагынган иде, баштагы көннәрне хәтта ял итеп тә тормады. Гомумән, Локман карт кабызып җибәрелгән машина кебек эшли, туктаганда үзе дә:

— Ярар, машинага да ял кирәк, — дип куя иде.

[1] Ахыры. Башы 8 санда.

Алар өйләгә чаклы бер, өйләдән соң бер-ике генә тапкыр күлем ясыйлар, анысында да Локман ун-унбиш минуттан артык утырырга ирек бирми:

— Булды. Өйләдә ял итәрбез, — ди.

Өйләдә, күләгәгә ятып, бер сәгать чамасы йоклап алалар иде. Кичен бик соң туктыйлар. Биткә инде дулкын-дулкын җылы, дулкын-дулкын салкын һава тиеп үтә башлый; кояш күзгә яфрактай саргаеп, баюга киткән була, тик шунда гына Локман эшләрен читкә куя.

— Бүгенгә җитәр. Болай да икенде белән ахшам арасында эшләдек. Борынгылар икенде белән ахшам арасында эшләргә кушмаган, — ди.

Кич алар, эштән туктагач, бер-берсенә су салышып, билдән юынып алалар. Башта Гаяз юына, төпчек абзыйсы аңа бер кулы белән су салып тора, икенчесе белән аркасын ышкый; аның кулы чыршы ботагыдай кытыршы: тигән бер җирдән тырнап үтә иде. Аннары төпчек абзыйсы билдән бөгелеп, аңа үз аркасын куя. Алдан ук:

— Билгә бик агызма, ыштан төбенә китә, — дип кисәтә.

Аның кулы гына түгел, арка ите дә сөян бүрәнәдәй каткан — сыйпар кулга тәндәй тоелмый да иде. Бер көн Гаяз әйтте:

— Аркаң, төпчек абзый, каезланып каткан агачтай, — диде.

— Яшь чакта Груздев капчыгын да, аерым[1] капчыгын да күп ташыдык — шуңа, — диде Локман. — Беррәт шулай врачлар нәрсәдәндер укол кадарга иткәннәрие — кадый алмадылар. Петров үзе дә кадый алмады. Энәләре шундый булды микән, — аптырагач чалбарны төшереп кададылар, — дип көлде.

Барак салучылар эшкә тугыз белән ун арасында гына киләләр иде. Таудан беренче булып Кави килеп менә. Ул — бригадир. Шуна алдан килә. Ләкин ул туры эшләгән җиренә бармый, башта Гаязлар янына сугыла, исәнлек-саулык сорашып, хәл белешеп китә. Аның иртәнге сукмагы бер, сүзе дә, патефон пластинкасына язылган шикелле, һәр көн бер төсле иде.

— Нихәл, исәннәрмесез әле? — диде Кави.

Локман, эшеннән туктамыйча гына, җавап бирде:

— Бик исән әле, улым. Үзең исәнме?

— Ярый шунда, — диде Кави. Аннары ул кесәсеннән портсигарын алып тәмәке кабызып җибәрде. Аннан Гаязга дәште: — Үзең соң, апай, бик алҗымыйсыңмы?

Дүрт ел буе гел машинада эшләүдән Гаязның организмы ничектер сүлпәнәйгән, мускуллары аз хәрәкәткә күнегеп, ялкауланган; башта эшкә тотынасы килми торды: бигрәк тә, суккан саен, чәчрәп көч чыккан балта эшенә тотыну чирдән соң өзлегү белән бердәй авыр иде. Шулай да Гаяз баштагы бер атнаны аруның ни икәнен белми эшләде. Хәтта аңа, киресенчә, арка-күкрәк, беләк мускулларының үсеп-кабарып киткәндәй сизелеп торуы — гомумән үзендәге көчне туктаусыз сизеп тору рәхәт иде. Ләкин бу рәхәт озакка җитмәде.

Атна үткәч, бөтен тәне сулкылдап сызлый башлады. Бигрәк тә беләк мускуллары сөякләргә төшеп сызлый иде. Җитмәсә, кояшка пешкән арка тиресе, агач җилеме ягып куйгандай, әрнеп җыерылган, кыймылдарга да ирек бирми, кыймылдаган саен, бер җире ярылып киткән сыман иде. Шулай да ул таралып йоклый — әнисе уятканда буыннары үзенеке кебек тә түгел, көчкә торып китә иде. Ә бармаклары, балта сабы тоткандагы шикелле, катып кала — җылы су белән югач кына языла төшә иде. Аңа бу тойгыларның бөтенесе дә электән үк таныш, тик алар онытылып кына торган икән, менә хәзер, барысын да кабат тойгач, ничектер сәер булып китте.

---

[1] Колхозлашуга хәтле аерым хуҗалык көткән крестьяннарга әйтелгән.

Бүген ул Кавига:

— Әллә нишләдем әле, һаман язылып китеп булмый, — диде.

— Син, апай, бик кабынып барма, әзрәк эшлә дә ял итеп ал, әзрәк эшлә дә тагын ял ит. Эткәйгә карама, эткәй ул...

— Эшләми эшләгәнгә шулай, — диде Локман карт та. — Яшь кешегә берни дә түгел ул, бер-ике көннән үтәр.

— Ярый, эткәй, Гаяз. Арымый эшләгез. Әнә безнекеләр дә килә, — дип, Кави китеп барды.

Локман карт, таудан менгән осталарны күргәч, яратмыйча:

— Сәгатьләренә карыйлар әле ишшү! Ялгыш иртә килеп куймагаек диләр бугай, — дип карап торды. — Аларга нәстә, эш — сәгать белән, ял — «сәбәп» белән: тәмәке тарткан саен ял. Башлаганчы бер тарталар, бер-ике чапкач — тагын...

Гаяз күреп торды: барак салучылар килү белән үк эшкә тотындылар һәм бер сәгать эчендә ярты бураны мүкләп, күтәреп тә куйдылар.

Гаязларның инде күләмгә туктар вакыты иде, ләкин Локман:

— Монысын бетерик инде, — диде.

Алар инде кыекны калай белән ябарга әзерләп, идәнгә тотынганнар иде.

Идән такталарын үткән язда ук ярып, күләгәдә киптергәннәр. Нух шартын белеп эшләгән, тик өстә яткан ике-өч такта гына, тиешенчә бастырылмау сәбәпле, чалшаеп кипкән, аларын тәрәзәсез стена буена — карават, шифоньер астына җибәрделәр, каерып тигезләү бер көнне алды. Иң кыен тактаны чөйләп кыскач, ниһаять, Локман карт балтасын өрлеккә чапты.

— Ярар, машинага да ял кирәк.

Аста бөркү иде. Гаяз өрлеккә менеп, тәрәзә җиленә басты. Алар ягына туп-туры бер кеше килә иде.

«Кем булыр микән бу?» — диде Гаяз. Шунда ул Кавиның да, эшеннән туктап, бу кешегә карап торуын күрде. Бүтәннәр дә карап тора иде. Алар Кавига: «Бар!» — диделәр ахры. Кави, балтасын ике-өч адымнан атып, бүрәнәгә чапты да бу таба килә башлады.

Тегесен Гаяз, якынайгач кына таныды: ул — налог агенты Әсләм иде.

— Әсләм килә! — диде Гаяз.

Локман, яулыгын кибәргә куеп, идәнгә сузылып яткан иде.

— «Урыс» Әсләмме? — дип, кайтарып сорады да сикереп үк торды. — Авырып ята дигәннәрне бит әле — мин эшли башлагач, терелеп тә чыккан икән!

Әсләм сугыштан үз телен «онытып» кайткан татарларның берсе иде. Аның мәзәкләрен күп сөйлиләр, кайдан нәрсә ишетсәләр — аңа япсаралар: Әсләм, диләр. Хәлбуки, хас Әсләмнеке бер генә: сугыштан кайтып, пароходтан төшкәч, әнисенә:

— Как ты постарела, мама! — дип әйткән, авылдашлары белән дә русча гына дәшеп күрешкән.

— Телеңне оныттыңмы әллә? — дип сорыйлар икән дә, бу:

— Почти что забыл, — дип әйткән икән.

«Урыс» кушаматы әнә шуннан калган. Ә менә, кешеләргә үчегеп, бүре булып йөрүе — аныксы инде Әсләмнеке генә иде.

Гаяз аны бәләкәйдән үк белә: ул чакны Әсләм алар колхозында председатель иде. Гаяз хәтерендә аның, барыннан да бигрәк, тарантаска кырын төшеп йөрүе торып калган. Авыл эченнән үткәндә аңа олысы-кечесе баш иеп сәлам бирер иде, ләкин председатель ике якка асылынып төшкән симез иренен генә кыймылдатыр иде. Тагын шунысы һич тә онытылмый: баланы бер дә тыя, тыңлата алмый башласалар,

укытучы булмасын — укытучысы, эти-әнисе булмасын — эти-әнисе идарәгә генә барып әйтә — Әсләм килеп баланың арт сабагын укытып китәр иде.

Локман тиз генә Гаязга дәште:

— Кит тәрәзә яныннан, карап торганыңны күрмәсен.

— Күрде инде ул.

— Күрсә соң? Син күрмә.

Гаяз аның янына килде.

— Сүзебез бер булсын, — диде аңа Локман. — Син дә, мин дә: өч йөз, дибез.

Ул арада Әсләм урам як тәрәзә төбенә килеп туктады.

— Кая, бирәрегез бармы?

Аңа җавабында Локман:

— Кем акыра анда? — диде.

Әсләм дөп-дөп басып өйне әйләнеп чыкты да ишек авызыннан башын эчкә сузды. Әсләм һаман шул — битен-күзен сакал баскан, кырынмаган Әсләм иде. Иңбашына аскан иске сумкасына тикле шул иде. Әсләм аны салмыйча гына эч турысына китерде дә бусага бүрәнәсенә куеп ачты, бер дәфтәр алып, анысын сумка өстенә куйды. Авторучкасы кесәсендә булды микән, сумкасында микән, Гаяз күргәндә кулында иде инде.

— Ахры, син тотынгансың икән бу эшкә, — диде ул Локманга.

— Нигә, минем тотынырга хакым юкмыни? — диде Локман.

Әсләм анысына җавап биреп тормады, эшкә күчте:

— Икегез эшлисезме?

Локман юри ягымлы, йомшак тавыш белән:

— Синең кебек грамытнай кешеләр, Әсләметдин апай, башта исәнләшә торган иде. Син бит, как не как, безнең председатель дә булган кеше. Мине нитмәсәң, әнә Әбел-Гаяз бар...

— Төрттереп ятма син анда, Локман абзый, яме! — дип кадалды аңа Әсләм. — Мин исәнлек-саулык сорап йөрмим. Мин эш белән йөрим. Исәнлек сорап, хәл белешә китсәң, злоупотребляйт итә башлыйлар... Так, значит, икегез эшлисез?

— Шулай булып чыга инде.

— Күпмегә сөйләштегез?

— Кеше башлаган эшне күпмегә сөйләшәсең инде?

— Бушка эшләмисездер бит?

— Бушка диярлек, апай Әсләметдин. Аптыраганнан килеп ялландык...

Локман кинәт уйга калды: күпмедән сөйләштек дияргә соң? Әсләм үзе күренгәч кенә, исенә төшеп, уйламас баштан Гаязга: «өч йөз» — дип әйтте әйтүен дә. Хәзер уйламыйча әйтү ярамый: Әсләм дурак түгел, синең сүзеңә генә ышанып, өенә кайтып китмәс — туры Нух янына төшеп китәр әле. Нухка нәрсә? Әйтә дә сала. Әсләмне каты чирле дигәч, Локман аны терелеп чыгар дип уйламаган иде. Терелеп чыгасын уйласа, өй сөйләшкәндә үк, Әсләм сорашса дип, берәр хак куешу кирәк булган да бит. «Татар акылы төштән соң» — менә шул була инде.

— Көттермә, Локман абзый.

Ниһаять, Локман бер карарга килде: «Без сөйләшкән чын хакны Әсләм белеп, гаеп яга-нитә калса, авырлыгы я Әбел-Гаязга төшәр — карт башым белән аның алдында ялганлап тору килешмәс», — дип дәресен генә әйтергә булды:

— Туләем дүрт йөз иллегә сөйләштек, Әсләметдин апай.

Әсләм Локманга карап катты. Локман исә, ял сәгате бетмәсә дә, яулыгына үрелде, алып бәйли башлады. Телсез калган Әсләм:

— Кара аны, Локман абзый! — дип кенә әйтә алды.

— Карыйсы юк аны, Әсләметдин апай. Карасаң-карамасаң да — шул. Без әле качмыйбыз, тикшерерсен.

— Аны тикшереп торасы юк, — диде Әсләм. — Соныннан үзе дә чыга ул.

— Соныннан чыкканга бик ушыбыз китми, апай. Өй салдырган кешене үзең беләсең: дүрт йөзгә эшләтсә, соныннан «биш йөз» — ди. Тора-бара алты йөзгә дә җиткезә. Мактанырга кирәк бит! Киметеп сөйләсә, кешесе дә ышанмый аның.

Гаяз: «Кызык, шушы кешедән дә куркып йөргән чак бар иде бит!» — дип, Әсләмгә карап торганда, Әсләм кинәт аңа борылды.

— Дөресен генә әйт: шулаймы?

— Шулай, — диде Гаяз. — Төпчек абзый дөресен әйтте: икебезгә дүрт йөз илле.

Әсләм аңа да янап алды:

— Смотри, апай...

Аның күзләрендә үк «иман нуры» юк — аның күзләрендә фәкать сиңа ышанмау, миңа ышанмау, синнән шикләнү, миннән шикләнү генә бар иде.

«Барыбер ышанмады», — диде Гаяз.

Җитмәсә, аның бүген бөтен тәне ватылып сызлый иде, ләкин бу сызлау, нигәдер, арудан түгел, кояшка пешүдән түгел, гүяки Әсләмнең чәнчеп карап торуыннан иде, хәтта аның сакал баскан бите дә бөгәрләнеп яткан керпедәй кадый иде.

Гаяз шушы чәнечкеле-шырпылы йөздән тиз генә күзен алып читкә карады һәм шунда Әсләм янына килеп баскан Кавины күрде.

Кави инде баягы сабыр, басынкы Кави түгел; тешен кысып Әсләмгә карап торды да әтисенә дәште:

— Эткәй, бу нишләп монда йөри?

Тавышы гөрелдәп буш бура эченә таралды. Локман карт эчтән, белмәгән кешегә җавап биргәндәй:

— Знамо, тик йөрми. Налог салырга килгән бит, — диде.

Кави тагын Әсләмгә карады, яңак ите тагын уйнаклап алды.

— Налог салабыз диген, ә? — диде ул.

— Юк, өй салам, — диде Әсләм.

Ләкин борылып карагач, каушабрак китте: Кави яхшылыкка килмәгән иде. Шулай да ул арыклыгын белгертмәде, сыртын кабартты:

— Нәрсә? Яклашырга килдеңме? Бөтен нәселегез белән шабашкада йөрисез дә, понимаешь...

Аның сүзен Локман бүлде — чынлап та булган хәл кебек:

— Нинди нәсел сөйлисең син, Әсләметдин апай? Үзең корытып бетердең бит инде аны син, — диде.

Ләкин Әсләм кызып сөйләвендә булды:

— Акча дигәндә — чукынып барасыз, понимаешь. Берегез — әле армиядән дә кайтып өлгермәгән — уже шабашкага чыккан.

— Әбел-Гаязга тел тигезәсе булма! — диде аңа Кави.

— Ә син кысылма!

— Кысылмам әле менә мин сиңа! — диде аңа Кави. — Аяк-кулың исән чакта таймасаң...

— Ә син миңа янама, яме! Мине янап кына куркыта алмассың. Мин — представитель местной власти.

Локман эчтән тавыш бирде:

— Кычкыртмале шуны, Кави! Эшен эшләде бит инде: налогын салды. Китсен.

Әсләм, кеше ишетсен өчен, бөтен тау башын яңгыратып, телләшергә тотынды:

— Көпә-көндез кыйнарга итәсеңме? Суд та юк, чурт та юк дип уйладыңмы әллә? Но, смотри, сиңа мин статьяны тиз табармын!



Бераз басыла төшкән Кави:

— Син мине, абзый, статья белән куркытма, — диде. — Ул статьяң синең әллә кайда әле. Ә минеке — менә! — Ул Әсләмнең борынына гөл чүлмәгедәй йодрыгын терәде: — Нинди статья исе килә? Бу бер әләксә, сөяк-санакларыңны чертежга карап та жыя алмассың. Яхшы чакта, бар, эзеңне сыпыр!

— Но, смотри!.. — диде Әсләм тагын.

Локман тәрәзә янына килде, кайсы якка китәр икән дип, Әсләм артыннан карап торды. Әсләм заготзерного төшмәде, өенә ут капкан кеше сыман, йөгерә-атлый Кырлачка кайтып китте. Аның сул кулы гарип иде, ул аны гадәттә селтәми йөри иде, әле анысын да селтәп-селтәп ала башлады — күрәсең, үзенә-үзе Кави белән һаман талашып бара иде.

— Игелеккә түгел, сул кулын да селти башлады, — диде Локман.

— Ике кулын да сындырып төшерсәм, берсен дә селти алмас әле,— диде Кави.

— Нәрсәгә бәйләндең әле син аңа, абзый? — диде Гаяз.

— Бәй, апай, — диде Кави, — узган кыш Гандәлиф жизнәйләргә әткәй белән йорт салып биргән идек. Әткәй акчасын алды, ә мин — Гандәлиф жизнәйнең бик бирәсе килсә дә — алмадым. Шулай күпмедер үткәч, Әсләм миңа квитанция китереп тоттыра. Шуңа, шуңа, ди. Бик ачу килде. Тоттым да Сәйдәшев янына киттем. Анысы ышанмый:

— Гандәлиф тә туган агаң түгел, бер дә акчасыз эшләмәгәнсеңдер әле, апай. Хәзер бер туганына да буш эшләмиләр, ди, юкка бәйләнеп йөрмә инде, ди. Соң, эш налог түләүдәмени? Налог акчасын

мин аны, балтаны бер чаптым — табам. Эш — сиңа ышанмауда. Күңелне шунда бик нык рәнжетте Сәйдәшев. Элек тә нәрсәгәдер үпкәм бар иде. Чыктым да киттем заготзерного. Дурак!..

— Дурак шул, — диде аңа Локман. — Дурак булмасаң, шундый сүз сөйләп тормас идең.

— Син дә, әткәй, җанымны уртәмәле... — диде Кави. Аннары: — Ярый, арымый эшләгез, — дип үз бригадасы янына китте.

## Уненче бүлек

Төнлә белән Таһир бик каты ютәлли башлады. Бу ямьсез юеш ютәл аңа таныш иде, ул аның нәрсә икәнен яхшы белә иде. «Шут!» — диде ул коты алынып һәм тиз генә кулын өстәлдәге электр лампасына сузды. Өй эченә яшькелт абажур яктысы төште. Шул яктылыкта ул авызына тоткан чүпрәкне ачып карады, кинәт маңгаена салкын тир бәреп чыкты: ул кан төкерә башлаган иде. Ул, тагын ютәле кабып, гәүдәсе белән карават читенә сузылды.

— Инәй! Тас кайда? Кан килә...

Кифая әби бу сүздән коелды да төште. Таһир беренче кабат кан төкергән яздан бирле бу сүзне өйдә беркем дә телгә алмый, сөйләми: бу тыелган сүз иде. Шулай булса да, ул сүз һәркайсының күңелендә иде һәм, яз-көз җитә башладымы, Кифая әби изге таң сәгатьләрендә: «Йа раббн, ходаем!» дип, улының шушы алама вакытларны исән генә уздырып җибәрүен тели иде.

Быел апрель-май буена йөрәге кубып торганнан соң, ул җиңел сулап куйган иде. «Июньне көткән икән, нәгаләт төшкере! Суык килде шул май, сөякләрен майдай эретә алмады», — диде ул.

Аннары, һушын җыеп, урыныннан сикереп торды, аның киенеп торасы юк иде: Таһир авырганнан бирле, көндезге киемен салмыйча гына йоклый иде. Ул тиз генә өйалдыннан тас алып керде. Таһир аңа бер генә төкерде дә:

— Тас кирәкми, банканы бир, — диде.

Карават читенә иелгән җиреннән гәүдәсен мендәргә алып салды. Аңа хәзер иелеп, капланып йөткерергә ярамый иде. Аңа хәзер чалкан гына яту кирәк. Тик кенә! Менә шулай...

— Инәй, тозлы су ясап бир дә Гаязны уят әле. Тамараны алып килсен.

Кифая әби бер стакан суга бер кашык тоз салып болгатты да Таһирга бирде. Улы эчкәндә башын тотып торды. Аннан соң Гаязны уятты:

— Әбел-Гаяз... тор әле, улым...

Гаяз, күзен ачу белән, башта әнисенең сузылып төшкән йөзен күрде, аннары үзләренең әтәч тавышын ишетте.

— Бар, улым, фильшерны алып кил.

Гаяз, йөрәге жу итеп, шундук уянып китте. «Нигә?» — дип сораунын кирәге юк иде. Ул, тревога вакытындагы солдат кебек, сикереп торды да киенеп тә куйды.

— Кемнәрдә тора соң ул фельдшер?

— Әминә апаларында, — диде әнисе.

— Нәрсә дип әйтим?

— Кан төкерә башлады, диген. Шулай дисәң, үзе белер, — диде Таһир.

«Белер» дигәнендә кыю өмет җилпенеп алгандай булды.

«Әл дә Тамаракай килде, рәхмәтләр яугыры! Әл дә теге дуңгызы түгел...» — диде Кифая әби. Тап-таза улының, үпкә чире азып, шушы хәлгә төшүенә ул беркемне дә түгел, фельдшерны гына гаепли иде.

Шул бит Таһирга: «Пневмония, апай, пневмония. Салкын гына тигән», дигән булып, горчичник ябыштырды да банка салды, банка салды да горчичник ябыштырды. «Дуңгыз! Чучкадай симереп, унҗидеунсигез яшьлек егетләрне аздырып ятадырие — әл дә алла бирде, кудылар үзен...»

Әминә түтиләр өе ерак түгел иде — салынып яткан клубны үттенме, ике өй аша гына иде. Ишекне Әминә апа үзе ачты. Караңгыда шәйләп, Гаязны таныгач:

— И апакаччаем, синмени? — диде.

— Мин, Әминәттәй, — диде Гаяз. — Тамараны уятсаң иде.

— Тамара уянды инде. Ишек шакыдылармы, икебез дә уянабыз — мин ишек ачмага йөгерәм, ул киенә башлый. Нишләп йоклап ятсын ди? Аңа булмый, миңа килсеннәрмени төнлә? Әйдә, кереп тор.

— Мин шушында гына көтәм, — диде Гаяз.

— Алай булгач, хәзер...

Гаяз, аның белән керсә дә, әйләнеп кенә чыгасы булган икән: минут та үтмәде, Тамара киенеп тә чыкты, әйтерсең лә, ул чакырып килүләрен көтеп кенә яткак иде.

— Күптән башландымы? — диде ул.

— Юк, бер ун минуттан артык түгел.

Алар башкача сөйләшмәделәр: алар бер-берсен белмиләр иде, алар Таһирны гына беләләр иде. Аның хәлен инде Тамарага Әминә апа әйткән — Тамарага шул җиткән иде.

Башта Тамара, «Әйдәгез», дип, Гаязны медпунктка алып кереп китте. Медпунктны Гаяз юкта Әминә апалар күршесендәге буш ихатага салып куйганнар, ә ике арага, турыга йөрер өчен, койманы кисеп, бәләкәй капка ясаганнар иде.

Медпунктта да алып барасы бар нәрсә әзер, чемоданга гына саласы бар иде.

Тамара Гаязлар өенә, сагынып килгән кардәшләре сыман, җиңел аягы белән килеп керде. Ул кергәч, өй эчләре киңәеп-зураеп киткәндәй булды. Ул түргә узганда, Кифая әби:

— И Тамаракаем... — дип аркасыннан сөеп калды. Тамара:

— Шулай булып киттеңмени соң әле? — дип, Таһир янына барып утырды. Таһир да, аны күрүенә сөенеп, шаярткан булды:

— Минә әҗәл, июнь җиткәч булса да, хәл белергә килде әле, — диде.

— Хәзер без аны!.. — диде Тамара.

Аннары ул Таһирның аяк-кулына жгут кысып бәйләде.

— Ныграк кыс әле... Минә шулай. Әллә муенга да саласыңмы соң шул бауны?

— Пульсың нормальный. Көяләнер урын юк. Инде тыныч кына ят.

Аның сүзләреннән Таһирның агарган йөзенә, рәхәт җилдәй, йомшак кына җылы тын бәрелеп тора иде.

Чыннан да, тиздән Таһирның хәле шактый җиңеләйде. Күкрәк абызы турысыннан, эчтән, нәрсәнеңдер атылып тамакка йөгереп килүе ул кадәр тынны бумый иде инде.

Тамара торып шприцларын әзерли башлады. Гаяз аның йөзенә карады. Һәм аңа, шушы яшь кенә кызның абыйсы өчен үлеп торуын күргәч, күңеле тулып чиктә рәхәт булып китте.

Таһир күз кырые белән генә даруларга карады.

— Нинди укол?.. — диде ул.

— Хлористый кальций.

— Аннан соң нәрсә? Атропинмы? Уфада шуны кадыйлар иде.

— Атропин юк шул. Камфора алып килдем.

— Ул да әйбәт, — диде Таһир.

Хлористый кальций уколыннан соң аның хәле тәмам жинеләеп, кан килү туктады. Таһир изелеп йокыга китте.

Тамара күтәрелеп Гаязга карады.

— Уянгач, тагын викасол эчсен. Берәр таблеткадан өч тапкыр. Көндез үзем дә бер-ике урап китәрмен. Кайнар чәй, эссе шулпа ярамый, салкын әйберләр генә ашасын.

Кифая әбинең таш баскандай кысылган күкрәге жибәреп, иркенәеп китте. Ул тагын:

— И Тамаракаем, әл дә син бар әле...— дип, аны ишек төбендә аркасыннан сөеп калды. Гаяз озата китте.

Энә күзедәй вак кына яңгыр сибәли башлаган иде. Авыл икенче әтәчтән соң әйләнеп тә ятмаган — капланып төшкән килеш үлеп йоклый иде. Һәм шушы үле тынлык эчне упкындай суырып кына алды, күкрәк буш мичкәдәй булып калды. Убыр авызыдай ямьсез тынлык иде бу.

— Таһир абый — молодец! — диде Тамара әкрен генә.

Аның шушы, яфрак шыбырдагандай тавышы да, кинәт яңгырап, Гаязны сискәндереп жибәрде.

— Да, абый молодец,— диде ул.— Сезгә дә бик рәхмәт.

— Нәрсәсенә рәхмәт? Безнең — эш шул бит.

— «Шуның өчен акча алабыз» да дисәгез, скромностьның теге ягына чыгасыз инде!

Тамара шәһәр кешеләре сыман:

— Гафу итегез,— диде.

— Гафу нигә? Мин болай гына, сүздән генә,— диде Гаяз һәм шунда ук, ни әйтер, ни ишетермен дип, курка-курка гына сорарга булды: «Барыбер бүген булмаса иртәгә сорарга туры киләчәк», диде ул эченнән.

— Карагыз әле, Тамара, чынын гына әйтегез әле, Таһиржан абыйның чын хәле ничек? Ышаныч бармы?..— диде.

— Башта ук чиренә дөрес диагноз ясап дәвалаган булсалар, инде Таһир абый күптән савыккан булыр иде. Үзегез дә беләсездер инде: аны дөрес дәваламаганнар. Шуннан чире отыры азып кына киткән. Аңарда туберкулез очагы яшьтән үк калган булырга тиеш.

— Бик мөмкин,— диде Гаяз.— Аның самый үскән вакытына сугыш авырлыгы төште. Миңа да бераз эләгеп калды калуын. Мәгәр бәлкабзыйга ин үзәге туры килде. Сугыш беткәч тә әле — анысын миң дә хәтерлим — 49 нчы елга кадәр ипине туйганчы ашый алмый идек. Ярый әле ничек авыруга сабышып бетмәгәнбез... Хәзер бит медицина көчле. Неужели коткарып калып булмас?

— Бу турыда фтизиатр белән яки Петров кебек зур врач белән сөйләшергә кирәк,— диде Тамара.— Мин фельдшер гына. Минем әле күп нәрсәгә белемем дә, практикам да житми. Шулай да Таһир абый чирне жиңәргә тиеш. Авыр елларда үссә дә, организмы нык, йөрәге таза. Аңа операция ясарга тиешләр икән. Үзе куркыбрак торган кебек. Әйтегез — ясатсын. Тик аңынчы берәр санаторийга барып, ныгып кайтсын иде.

— Сез Бәйрәм-Алине белмисезме?

— Ишеткәнем бар,— диде Тамара.

— Шунда бик яхшы санаторий бар икән. Бәлкабзыйны шунда жибәрсәк, юл авыр булмас микән?

— Кан түкергәндә беринди юлга да чыгарырга ярамый.

— Ул — әле түгел соңыннан. Аны кайтып алачаклар.

— Ай, белмим, Гаяз. Сез Петров белән киңәшегез әле ул турыда. Путевкалар да аның кулында бит.

— Санаторий путевкаларымы? — диде Гаяз.— Мин белми идем бит...

— Чынлап та, нигә барып кайтмаска әле Петров абый янына,— диде аңа Тамара.

Ул Тамараны Әминә түтиләр капка төбенә хәтле озатып куйды да, бик пошаман хәлдә, уйланып кайтып китте. «Болай ярамый, — диде ул, — һич тә ярамый. Утырып бер уйларга, нидер кылырга кирәк...»

Клуб чатыннан өске урамга тыкрык менеп китә иде. Гаяз шунда бер генә минутка туктап, тагын бер уйлап-исәпләп торды — һәм бер карарга килеп, тыкрыктан өске урамга, Гандәлиф җизнәләренә менеп китте.

«Қ чорту Нухы! Өе дә к чорту! — диде ул. — Аның харам өе кадерләрәкме миңа — үз абыеммы? Җизнигә әйтеп куйыйм: эшкә киткәндә безгә кагылсын. Бүген үк Петров янына барам, бүген үк путевка юллый башлыйм. Қ чорту Нухы! Көтмәсә бүтән кеше яллар. Акчасы да кирәкми!..»

### Ундүртенче бүлек

Иртән тугызынчы яртыда капка төбенә тырылдап Гандәлиф килеп туктады. Мотоциклын сүндермичә генә өйгә кереп, Таһирның хәлен белеште. Таһир Гаяздан алда уянган иде, хәлем әйбәт, диде.

— Үтте сыман. Концерт та тыңладым әле менә. Бүген аеруча әйбәт концерт бирделәр.

— Алай булгач — әйбәт! — диде Гандәлиф. Аннары: — Давай тизрәк хәлләп, Таһирҗан. Аякка бас, — дип китәргә ашыкты. — Әйдә, Әбел-Гаяз, соңламыйк тагын.

Гандәлиф кайнишләренә кайниш дип тә әйтә, бер авылда үсеп гадәтләнгәч, исемнәре беләм дә дәшә, ләкин исемнәрен тутырып әйтә иде.

Алар дөбердәп-шаулап чыгып киттеләр. Өйдә җиңел бензин исе таралып калды.

Көн кояшлы, ләкин җиле бар иде. Җәймә чаклы гына болытлар ни кушылмый, ни таралмый, «Идел эче»нә агалар иде. Гаяз бүгенге таң аллын исенә төшерде. Абыйсының хәл эчендә ятуы да, энисенең курыккан күзләре дә, Тамара да, сибәләк яңгыры да — барысы да әллә кайчан булып үткән кебек. Утырган мотоциклы җил ярып, кешнәп барганда, үткән төннең соры тынлыгы да, төннең үзе дә булмаган кебек. Ләкин шул таң хатирәсе, кабер өстендәге таштай, күкрәкне басып, изеп тора иде. «Әткәй кайгысы да житкән иде лабаса! Монысы нигә? Бер семьяга күбрәк була түгелме соң?» диде Гаяз. Юл буе абыйсы өчен хәсрәтләнеп барды. Юк, үтмәгән икән әле ул үткән төн! Ул менә монда гына кереп утырган икән: йөрәк янына гына. Менә бу якты көн дә, менә бу тыгыз җил дә йөрәккә үтеп керә алмый, хәсрәтен тарата алмый иде.

«Миннән калмасын, — диде Гаяз, — миңа рәнҗемәсен. Кулыннан килгәнне дә эшләмәде бит, димәсен. Хәзер йөрмәсәм, гомерлек үкенечкә генә калыр. Гомерлек үкенечкә...»

Алар РТС усадьбасына җиттеләр. РТС Бишбүкән авылының бу ягында, больница теге ягында иде. Гандәлиф мотоциклыннан төште дә Гаяз аның урынына күчеп утырды.

— Эшең беткәч, туры кайтып кит, — диде аңа җизнәсе. — «Матай»ны калдырам дип, минем янга кереп йөрмә. Мин Әхнәфкә утырып кайтырмын әле. Ярый, юлың уң булсын.

Ләкин Гаязның юлы уңмады. Бердән, нәкъ обход вакытына эләгеп, аннары тагын әллә нәрсәләрс чыгып, Петровны ике сәгатькә якын

күтеп утырды. Икенчедән, Петров аның өчен бер нәрсә дә эшли алмады. Дөрес, анысы, төшенке күңелне күтәрерлек сүзләр әйтте, ул тикле кайгырмаска кушты: абыегызның хәле сез уйлаганча ук авыр түгел, диде, сәламәтләнеп китүенә ышанам, диде. Ләкин үзе бер нәрсә дә эшли алмады. Икенче кварталга кулында бер путевка да калмаган иде, дөресрәге: Таһирга кирәк путевканы больницаның үзенә дә бирмәгәннәр иде.

Петров яныннан Гаяз тәмам балтасы суга төшеп чыкты. «Кемгә барырга инде хәзер? Нәрсә эшләргә? Кайтып ни әйтергә...»

Ләкин Гаяз шуны аңлады: аңа, менә хәзер үк, өйгә кайтырга ярамый иде. Өйгә кайтса әгәр, аның йөзенә карау белән өйдәгеләр коелып кына төшәчәк. Шулай, күңел әзрәк үз урынына утырсын, йөрәк әзрәк басылсын.

Гаяз туры Нухларга кайтып төште.

Локман аны җәяү кайтадыр, шуңа озаклагандыр дип тора иде. Ләкин аның «матай» белән ишек төбенә үк килеп туктавын күргәч, шикләнә калды: «Ай-һай, шул гомер буе больниста гына утырмас кеше! Җизнәсе янында эш белешеп йөрмәде микән? Әллә кулына «матай» эләккәч, инәсе туганнарына барып килдеме?

Аннары ул, Гаязны шелтәләгәндәй, әйтте:

— Әй-яй-яй озак та йөрдең, байткә!

— Синең Петровың бит... — диде Гаяз.

Ул идәндә торган бүкәнгә килеп утырды. Чабып куелган балта шикелле, бер хәрәкәтсез, бер сүзсез башын да, гәүдәсен дә иеп, уйга калды. Бик озак шулай утыргач кына:

— Бер файдасыз йөрү булды әле бу, — дип, аптырап әйтеп куйды.

Гаяз каты гына бәрелгәч, Локман да, хәтере калгандай, мыегын асылындырып утыра иде. Әле инде, Гаяз үзе тавыш биргәч, сорыйсы итте:

— Петров өйдә юк идеме әллә?

— Петровы өйдә... — диде Гаяз.

— Нәрсә дип әйтә соң?

— Нәрсә дип әйтсен инде? Төркмәнстанга не в коем случае, ди. Язу бирә алмыйм, ди. Самовольно җибәрергә дә, как врач, рөхсәт итмим, ди.

— Менә әйттем бит мин сиңа! Разве алар шундый ерак юлга җибәрәләр: ул-бу булса, соңыннан алар отвечайт итә бит. Ә син якынрактан сорарлар.

Гаяз төпчек абзыйсының үзеннән ныграк белүенә, гел аныкы дөрескә чыгуына үртәлеп:

— Сорадым ла! — дип сикереп торды. Шап итеп бүкәне авып китте. Гаяз тәрәзә авызына җилгә барып басты. Локман:

— Петровны инде ике ел күргәнем юк, картайганмы? — диде.

— Каян белим мин аны! — диде Гаяз үртәлеп. Аның сөйләшәсе килми иде.

— Бәй, каян беләләрмени? Каршыда утыргандыр бит?

— Утырса ни? Мин аның битендәге сырын санап утырмадым бит! Петров — шул Петров инде.

— Картая белми торган кешеләр була инде шулай!.. — диде Локман, ләкин бу юлы ул үз-үзенә сөйләнгән сыман иде. — Кайчангы Петров инде ул, ә?

— Ярый, мин китим әле, — дип Гаяз чыгарга юнәлде.

— Тагын кая?

— Сәйдәшев абый янына төшеп менәм.

Локман да утырган җиреннән кубып, аның артыннан ишеккә килде.

— Бер эшкә ялангач, алай итенеп йөрмәскә иде инде, Әбел-Гаяз.

Тотынган эшне башта бетерергә кирәк, аннан — әйдә йөре. Болай килешми. Нух та килештермәс.

— Нух минем өчен — пустое место. Миндә аның кайгысы түгел — бәлкабзый кайгысы. Нух миңа путевка юллап бирмәс бит.

— Зато тизрәк эшләп бетерсәк, акчасын бирер.

— Туйдырды инде шул сүзен, төпчек абзый. Акча да акча, акча да акча! Биленә бәйләсен акчасын! Миңа путевка кирәк!

Локман мыегын кыйшайтты.

— Сәйдәшев бирер инде алай булгач путевканы. Депутат кеше! Черегән хатынын җибәрмичә, быел безнең Таһирҗанны җибәрер.

— Мин аннан путевка сорарга бармыйм — киңәш сорарга барам.

— Әтәң урынына калган кешенең киңәше ярамас буллымыни инде?

— Үпкәләсәң үпкәләрсең: синең киңәш белән генә, төпчек абзый, ерак китеп булмый.

Гаяз, мәгънәсез ургәлү белән педальгә тибеп, мотоциклын кабызды. Ләкин шундук, акылы килеп, газын киметте. «Машинаны да ургәргә ярамый, — диде ул. — Ул синең кеше түгел, үчен тиз кайтарыр...»

Ул әкрен генә кузгалып китте. Өйне әкрен генә әйләнеп урам якка чыкты. Аның каршына, кабынып-чәчәп, Фаягөл кортка килеп ята иде. «Шул гына җитмәгән иде тагын!» — дип, Гаяз тиргәнеп алды. Шулай да, күрәләтә китеп баруны әйбәтсенмичә, туктап көтеп торды. Фаягөл әбинең төсе-бите качкан иде, килеп җитми торып, Гаязны да танымады. Таныгач, елап җибәргәндәй, кычкырып такмакларга кереште:

— Кем дип торам тагы? Син икәнсең, игелекле бәндәләр баласы! Тагылар җыгылып төште бит теге карт! Утеп беткәнче, урынына кутәреп салыгызчы әле! Әллә уләргә итә инде, ходаем! Үлсә, ясинсыз утә инде. Мулласын алып чыгар кеше дә юк, балалары да чыктылар да олактылар!..

Гаяз аның бөтен сөйләгәннәрен тыңламады, ул моторын да сүндереп тормады.

— Хәзер керәбез, — дип кычкырды да Локманны чакырырга китте.

— Төпчек абзый, әйдәле, теге карт тагын егылып төшкән!

— Ул да бер бәла булды! — диде Локман, ләкин Гаяз артыннан ияреп Нухларга керде.

Сәмигулла картны урынына яткызгач та әле, йөрәген баса алмыйча әйтте:

— Тик кенә ятарга булмадымыни соң, Сәмигулла абзый, ә? Җиңгәйне дә борчыйсың, безне дә.

Сәмигулла картның, инде аякларында җаны калмаса да, һушы дөрес, теле бар иде әле. Караңгы почмагыннан Локманга җавап бирде:

— И Локман!.. Быел ямьле җәйләрне дә күргәнем юк бит!.. Үрмәләп булса да чыгыйм мәллә дигән идем. Кала бит ямьле җәйләр...

— Ямьле җәйләр алда әле, Сәмигулла абзый. Озакламый житәр инде, аллаһы бирса! Нух тышка да алып чыга башлар үзеңне...

Сәмигулла карт өметен өзгән тавыш белән:

— Ә-ә-ә-й!.. — дип торды. — Күзенә ярылчыгы гына тигән шул. Якынрак төшеп ярыла белмәгән шул бумбы. Ил өстенә килгән кайгы — түзәр идек әле, онытылыр иде. И-и-и, Имам-Малигем булса... Имам-Малигем юк шул: танкысы белән утырып кына янган, көлгә генә әйләнгән шул...

Фаягөл корткага да житә калды:

— Тагын егылып төшсә, ясин да чыгара алмый калырсың... Тәүбә, тәүбә, ходаем!..

— Инде төшмәс, Фаягөл жиңгәй. Инде төшмәс... — диде Локман.

Сәмигулла карт алар сүзен тырышып тыңлап ята иде әле.

— Үлсәм, мулла-мазар чакырып тормагыз, — диде ул. — Иманым, аллага шөкер, үзем белән...

— Тәүбә диген, дивана карт, — диде Фаягөл кортка. — Тузга язмаганны!..

— Ярый, мин киттем, Сәмигулла абзый. Исән булып тор, — диде Локман. Аннары Фаягөл корткага «әйдәле» дигән ым ясады. Өйалдына чыккач, әкрен генә әйтте:

— Бик шешенгән. Шешенсә, озакка китми инде ул — югала да куя, сизми дә каласың. Мин Нухка да әйткән идем, сиңа да әйтим: хәстәрен күрә башлау мишәйт итмәс.

Фаягөл кортка, елагандай, көйләп алып китте:

— И ходаем! Тәнннәре пычранып каткан килсш үләр микәнни, раббем? Өч ай бит инде мунча кергәне юк. Аста торганда, Ислам-Гали карт үзе алып барып, үзе чабып, мунча керткән иде. Нух әйләнеп тә карамый бит. Эттән тугандыр инде ул — миннән тумагандыр.

— Бар җирен дә өч кат юдырырсың. Тән каралыгы гына ничава, лишь бы иманы таза булсын...

Гаяз алар сөйләшкәнне тыңлап тормады. Сәмигулла картны күтәреп салгач та, тизрәк китү ягын карады. Локман чыкканда ул Кырлач тавына җитеп бара иде инде.

## Унбишенче бүлек

Колхоз идарәсендә бүген аеруча кеше күп иде. Урам якта да кеше, өй алдында да, коридорда да: кайсы сөялгән, кайсы чүгәләгән — барысы да ир-җәмәгать һәм барысы да үчеккәндәй тәмәкегә ябышкан — авыз-борыннары, суырмаган мич кебек, төтен кайтарып тора иде.

«Мин генә юк икән монда!» — диде Гаяз һәм үз танышлары янына барып басты.

Иртәгәме, соңгамы сал кайтасы икән, Сәйдәшев шуңа балта эшендәге барлык ирләрне чакырып сөйләшкән: «Сал каршыларга пионер кебек әзер торыгыз!» дигән. Ләкин сал төшүне инде чыкканнар да онытканнар, барысының да телендә Һабил иде, шуның мәзәген сатalар иде. Һабил бүген иртән машинасы белән, тормозы тотмыйча, Пугач тавыннан төшеп киткән икән.

— ...Башта ничектер машинасы каерылып юлдан читкә чыккан. Кире кертә алмаган, конечно, юлга. Юл өске якта — ул якка борса, машинасы белән әйләнеп кенә китәчәк булган. Шуннан — башы эшләгән тагын үзенең! — Кинәт кенә түбән якка борган да, әйдә — турыга! Ул тау битен беләсез бит инде: тигез түгел, сугыш вакытында агачларын төпләп бетергән идек бит. Төп урыннары чакыр да чокыр. Шуннан сикертә-сикертә җиппәргән генә, малай! Юл уңаенда сельподан товар төяп, Мәгъдәнияне дә утырткан булган, ярый әле үз янына утырткан. Ул ящикләр чәчелеп-чәчелеп киткән ди тау битенә! Вәрәкәмәт килгәннәр инде. Күтүчеләр күреп торган: Агыйделгә чак барып җитмәгәннәр. Мәгъдәния уштан язган...

Моны сөйләүче беренче генә кабат сөйләми иде, күрәсең, тыңлаучылары да килә тора, көлә тора иде.

— Әзрәк салган булгандыр ул Тарзан!..

— Салмагач, Тарзан буламыни ул!..

— Әллә руль дип ялгыш Мәгъдәния апага ябеште микән?..

— Шуңа ушы авып киткәндер әле...

Җыелып тыңлаган кешеләр авыз күтәреп көлеп калды. Гаяз коридор буйлап иң почмак бүлмәгә китте. Почмак бүлмә — Сәйдәшев бүлмәсе. Аның ишек төбендә җыелып торган кеше юк, ләкин председатель янына өзлексез кереп чыгып йөриләр иде.

Тышлаган авыр ишекне ачу белән, Гаязның колагына таныш тавыш килеп бәрелде: Әсләм, кулын бутый-бутый, председательгә: «Кази,

Локман...» дип нидер сөйләп тора иде. Бүлмәдә бер ул гына түгел, анардан башка тагын биш-алты кеше бар иде. Алары озын өстәл тирәсенә озаккарак утырганнар шикелле, әле тик эшләрен Әсләм генә бүлдергән шикелле: шуңар алар ул сөйләгәннәрне тыңламыйлар да, тизрәк чыгып китүен көтәләр иде шикелле: бер Сәйдәшев кенә, теше сызлагандай, йөзен бозып Әсләмгә карап утыра иде. Гаязны күргәч, аның эченә җан керде.

— Менә Гаяз үзе дә килде! — диде ул. — Бик әйбәт иттең әле, апай, килеп. Менә Әсләм Кави өстеннән жалоба белән йөри. Нәрсә булды соң анда сезнең?

Гаяз бер-ике сүз белән аңлатып бирде.

Сәйдәшев тагын Әсләмгә карады:

— Кайчан булды соң ул хәл?

— Бер атна элек, июньнең 6 сында. Мин анда язганмын.

Фаиз да идарәдә иде, ул, газетадан башын күтәрмичә генә:

— И абзый, кысканга былтыр кычкыраларммы быел?.. — дип куйды.

— Син кысылма, апай, — диде аңа Әсләм. — Тик кенә утыр! Синең яшьтә без тик кенә утыра идек. Кирәк икән, быел гына кычкырып калмам, киләсе ел да кычкырырмын! Мин әле чирләп яттым. Ул көнне аякка гына басып чыккан идем.... Кайттым да егылдым...

— Терелгәнче чыкмый торырлар иде...

— Аңлашылды, Әсләм, аңлашылды, — диде Сәйдәшев. — Ник аны син Кавиның эшләгән җиренә барып әйтмәдең соң? Ул бит хәзер бездә эшләми. Мамлиевта эшли, шуңа әйтерләр.

— Мамлиевка да әйттем. Менә сиңа да әйтәм: к сведению. Син бит — депутат. Без сиңа үз тавышыбызны бирдек.

— Яхшы, Әсләм, яхшы, — диде председатель. — Кави белән сөйләшермен.

— Сөйләш. Җавабын только письменно язып бирерсең.

— Ярый, ярый, «письменно» да язып бирер була. Бланка бар...

Әсләм, ниһаять, чыгып китте. Барысы да җиңел сулап, башларын күтәрделәр. Һәркайсы, ирексез туктап торудан файдаланып, әйтер сүз, бирер җавапларын әзерләп куйган иде, хәзер инде, сусаган — суга каплангандай, сүзләрен туктаган җирдән алып киттеләр.

— Исәпләсәң исәпләмәсәң дә, дүрт йөз бүрәнә җитми миңа, Сәйдәшев, — диде Кырлач Хәйдәр.

— Барысын да әр-яңадан салырга димәгән. Искеләрен дә кыстырып җибәрегез. Сипләсен сипләгез.

— Сипләргә дә бүрәнә кирәк. Дүрт бөртек кешемне кыстырып сипли алмыйм бит инде мин. Убыр Сәлмәннең нәрсәсен сиплисең? Сылагач балчыгыннан бүрәнәләре дә күренми.

— Ярый, апайлар, — диде председатель. — Хәзер без бүрәнә бүлешеп утыра алмыйбыз. Сал кайтсын әле. Идарә ясап хәл итәрбез. Аңынчы һәркайсыгыз бригадагызның эш күләмен точно исәпләп килегез. Ә хәзер эшләрегезгә таралышыгыз. Сал каршыларга, пожарниклар кебек, ут сүндергәч кенә килә күрмәгез тагын. Төнлә чакырабыз икән — киленнәр куеныннан чыга алмый ятмагыз. Вот шул!..

Аннары ул Гаяз ягына әйләнде.

— Килеп әйбәт иттең әле, апай, — диде ул тагын. — Рәхмәт. Ни өчен чакыртканны үзең сизенәсеңдер инде.

— Мине чакырган кеше булмады, Сәйдәшев агай. Мин әле үзем килдем.

— Ничек? — дип, председатель Фаизга карады.

— Локман бабай әйтмәдемени мин чакырганны? — диде Фаиз.

— Юк. Ул син килгәнне дә әйтмәде, — диде Гаяз.

Сәйдәшев, авызын ерып, көлеп җибәрде.

— Эшкә дә чакырып карадыңмы әллә?

Фаиз, гарьлеге килсә дә:

— Чакыруын чакырмадым... Шулай да әйтеп караган идем, — дигән булды.

— Нәрсә диде соң?

— Мин пенсиядәге кеше, яшьрәкләрне эзлә инде, улым, — ди.

— Вообще, Фаиз апай, утырткан икән үзенне Локман! Разве мин сиңа әйтмәдем?..

Бригадирлар әкрен-әкрен генә чыга башладылар. Председатель Хәйдәргә калырга кушты. Хәйдәр иплəп кенә кузгалган жиреннән кире утырды. Сәйдәшев, Хәйдәр белән Фаизга, тыңлыйсызмы дигәндәй, карап алганнан соң, Гаязга сөйли башлады:

— Мин сине бүген шуңа чакырткан идем, апай: теге вакытта син миннән машина сораган идең. Бирә алам мин сиңа машина. Тик яңа түгел. И бүгеннән утырып та китеп булмый.

— Һабилныкынмы? — диде Гаяз.

— Шуныкын, — диде Сәйдәшев. Һабил исеме чыгу белән, ул бер селтәнеп алды. — Менә мин ул Тарзаннан, бик әйбәт итеп, ремонт хакын кисеп алып калам әле, понимаешь! Чак харап итмәгән бит машинаны! Ярый әле, бөтенләй капланып төшмәгәннәр. Алгы рессоры сынган да тягасы кәкрәйгән... Алары сиңа бер көнлек эш инде аның. Бер рәттән башка жирләрен дә карғштырырсың. Җә, ничек? Ризамы?

— Юк, — диде Гаяз. — Әйтүен өчен рәхмәт, Сәйдәшев агай. Тик мин ул машинага утырмыйм. Мин аны беләм: ремонтка керттенме — ай ярым пычранырга кирәк аның белән. Яңа машина булса инде?.. Аннары, Сәйдәшев агай, бу көннәрдә мин бик күп уйлар да уйладым әле. Кулымда — балта, күңелемдә — эткәй. Кайсы гына коралына килеп тотынмыйм — яныма эткәй килеп баскандай була, өйрәтеп, сөйләшеп торгандай була. Эткәй кулына жайлашып беткән кораллар минем кулга да ип килеп тора. Миңа алар белән эшләү жиңел, рәхәт...

Шунда Гаяз күзенә саркып кына яшь килүен тойды. Хәзер аңа, башын күтәреп, күзен ныграк ачарга кирәк иде. Күз бәбәген йоммыйча гына йөрткәләп, яшен йотарга кирәк иде. Ләкин Гаяз башын күтәрә алмады.

«Әй, оят түгел әле!» — диде ул һәм чәчрәп чыгарга житешкән яшен, балалар шикелле, жиңе белән сөртеп алды.

— Әлеге эштә, конечно, дәрт биреп эшләп булмый, — диде ул. — Эше эш түгел, кешесе кеше түгел. Көн саен тышаулы ат кебек кенә киләм.

— Кайту белән, үзеңә дә андый эшкә тотынмаска кирәк иде, — диде председатель.

— Анысы ихтыяри-мәжбүри сыманрак килеп чыкты инде аның, Сәйдәшев агай. Теләсәм, бүген үк ташлап китә алам мин. Ә менә, бер тоткач, эткәй коралларын бүген-иртәгә генә инде ташлый алмыйм. Бер көн син минс, Сәйдәшев агай, балта эшенә чакырган идең. Аннан соң без шул турыда Фаиз белән дә сөйләштек. Менә мин килдем. Языгыз бер бригадага.

— Вот рәхмәт! — диде Сәйдәшев. Аннары, менә күрдегезме дигәндәй, бер Фаизга, бер Хәйдәргә карап алды.

— Миңа әйтәсе сүзенне оныттың бугай, Тәлха? — диде Хәйдәр.

Сәйдәшев күтәренке күңел белән:

— Юк, онытмадым, — диде. — Менә хәзер әйтәм: ал син, яшьтәш, яшьләр бригадасын. «Ай, яшәрергә!» дип тә офтана идең, әйдә яшәр!

— Картаймасалар ярый ла, — диде Хәйдәр көлеп.

— Картаймаслар. Егетләр менә дигән! Сайлап алган кебек. Хотя дөресе дә шулай инде: сайлап алдык. — Аннан ул тагын Гаязга карады: — Синең соң, апай, бу эшең кайчанрак бетә соң?

— Аптыраган инде, — диде Гаяз. — Унбиш-егерме көндә бетәр дип башлаган идек, менә егерме көн үтте — бетkәне юк. Тагын бер ун көн үтмәсә әле?.. Әллә ташлап китәсе? Мин бүген фактически эшләмәдем инде: эш кайгысы булмады. Таһирҗан абыйга путевка юллап, Петров янына барган идем дә, бу кварталга бөтенләй бирмәделәр, сентябрьгә генә бар, ди. Әллә район больницасына барып карарга микән?..

— Беркая да барып йөрисе юк, — диде Сәйдәшев. — Путевка минем өстә, Гаяз апам. Сөләйман абзый исән вакытта ук әле мәрхүмгә: путевка алырга үзем ярдәм итәрмен дип вәгъдә иткән идем. Мин Ахметов белән сөйләштем. Ул миңа шылтыратты: июнь урталарында бирәбез, дигәннәр. Менә июнь уртасын көтик инде. Булырдай булса, мин үзебезнең Верховный Советка шылтыратып алар аша юнәтербез.

— Рәхмәт, Сәйдәшев агай, — диде Гаяз. — Болай булгач, мин эшкә иртәгә үк килә алам.

— Сал кайтканны көт инде, алай булгач. Аңынчы барыбер бригада оешмый әле.

— Ну ярый, — диде Гаяз.

Председатель бүлмәсеннән аның түбәсе күккә тиеп чыкты. Ярты гына сәгать элек шушы коридордан үткәндә, шушы баскычлардан менгәндә, аның күңеле, томанлы көн сыман, күтәрелмәс кебек иде. Менә — өйләгә житкән кояштай күтәрелде дә куйды! Аны инде каткалак урам да, эреле-ваклы өйләр дә, тау битендәге пожар каланчасы да, «Сөенчесе миңа! Сөенчесе миңа!» дигәндәй, куанып каршы алдылар. Гаяз аларга яңа уянып чыккан бала төсле карап торды.

«Менә хәзер очып кайтырга да була!» диде ул һәм үзенең, беренче кабат мотоцикл артына утырып, урам әйләнүе исенә төште. Машина белән хыялланувы шуннан китте бугай. Тик машина романтикасы озакка житмәде, унынчыдан шофер правосы алып чыгуга — беткән иде инде. Хезмәттә ул моторизованный частька эләкте. Анда инде машинаның бер романтикасы юк иде. Шулай да Гаяз: «Рульгә ябыштым — инде купмам да», дип уйлаган иде. Кайтып балта чапкач, кителен кенә төшкәндәй булды.

«Шулай да «матай» алганда ярый», диде ул. Ишек төбендәге кешеләрнең, каланча башындагы пожарникның карап торуын тойган хәлдә, кайтыр якка борылды.

Культура йорты шул ук урамда иде. Килгәндә ул аны үтеп кенә киткән иде, әле туктап, кереп чыгарга булды.

Фойеда бүген беркем дә юк иде, бильярд өстәле дә, дүрт аяклы мал кебек, бер почмакта тора иде.

Земфира бүген икенче кызлар белән иде.

Гаяз, ишектән атылып керү белән:

— Кайтасыңмы, Земфира? «Матай» белән генә алып кайтам үзеңне! — диде.

Земфираның бите яңа башлады. Ул ак чырайлы иде, шуңа күрә тиз кызара иде: бит очлары алсуланып янып та чыкты. Ул, сәгатенә караган булып, йөзен түбән иде.

Гаязның шат күңеле кызларга да күчте. Алар:

— И малайкайлар! Төш тә житкән бит! — дип, жыена да башладылар. Земфираны шул коткарды да. Ул йөзен сәгатьтән алды.

— Кызлар, төштән соң килергә онытмагыз! — диде.

Алар бүлмәдән бөтенесе бергә чыктылар. Кызлар бер-берсен авылча култыклап, тезелешеп Земфираның мотоциклга бик жайсыз утырганын карап тордылар. Земфираның итәге кыска иде: утыргач бигрәк тә өскә шуып менеп китте. Земфира, калкынып, итәген тарткалап карады — барыбер жибәрмәде.

— Булдымы? — диде Гаяз.
Мотоцикл әкрен генә кузгалып китте. Кызлар:
— Өйләнеп төшә күрмә! Гаяз абыйга нык ябеш! — дип кычкырып калдылар.
Аларга артезиан коесыннан су алучы хатын-кызлар да карап калды.
«Иртәгә сөйли башлаячаклар, — диде Земфира. — Юк, бүген үк. Иртәгә инде авылга таралачак. — Ул инде ник утырганына үкенә дә башлады: — Юкка утырдым... Халык теленә генә кереп калам инде... Итәкләрен бик ачып киткән иде дә, башлады да ташлады, диячәкләр. Әйдә, дисеннәр! Дисәләр дә, барысы да кызыгып, көнләшеп карап калды әле... Башлады да ташлады?.. Чынында, башлау юк — ташлау да булмаячак иде. Башламагач, ташлыйлар микәнни?.. Ул Халидә апаны ярата...»
Гаяз бер көнге туры юлдан китмәде: туры юл биш кенә минутка житә иде. Ә бүгенге уйларны жилгә тарату өчен биш кенә минут житмәячәк иде. Гаяз Имай тыкрыгына борылды. Моннан ул басу юлы белән ком юлга [1] менәчәк, ком юлдан заготзерногa төшәчәк. Болай кайтканда ун минут үтәчәк иде.
Урамны чыккач, Гаяз, артына борылмыйча гына, Земфирага дәште:
— Шәбәйтсәм курыкмыйсыңмы?
— Ю-у-к! — дип кычкырды Земфира.
— Ныграк ябеш алайса!
Мотоцикл уктай очып үргә менә башлады. Земфира Гаязның биленә ныграк тотынды. Ике яктан да колак төбендә жил выжларга кереште. Ләкин Гаяз артында ышык — жил биткә бәрми, арттан чәчне генә жилфердәтеп бара иде. Земфира, Гаязның киң жилкәсенә карап:
«Әйдә, авыл тутырып сөйләсеннәр!..» дип куйды.
Гаяз да аны уйлап бара иде. Бу кыз бер Флюсның гена башын әйләндерми торгандыр. Башка егетләргә Флюс кенә ирек бирми торгандыр: барысы да аның кебек көчле түгел бит. Тик Флюс аңлап бетерми әле: мондый эштә көчкә таянмыйлар. Мондый эштә йөрәккә таяналар. Мин Флюсне, теләсәм, юлдан ала алам. Ләкин Земфираны ярата алмыйм. Мин очраган бер матурны ярата алмыйм, күрәсең. Яраткач, чынлап яратырга кирәк! Чынлап яраткач, өйләнергә кирәк. Ә мин Земфирага, яратсам да, өйләнә алмаячакмын. Ул — әйбәт кыз. Әнисенә охшаган. Гармун уйнавы да әнисе ягына тарткан. Ләкин әтисе... Аңа мәңге «бабай» дип әйтә алачак түгелмен...
Земфира аның биленнән кысып тоткан иде. Кул битләренең кайнарлыгы, пиджак, күлмәк аша үтеп, бөерләрне жылытып бара иде. Күкрәге турысыннан арка үзәгенә эссе бәреп торган кебек иде. Кинәт, мотоцикл жиледәй агылып, Гаязның бөтен тәне буйлап кайнар хис дулкыны йөгереп үтте — буыннарына төшеп, һушларны алып үтте. Әллә шушыннан туп-туры, ни унга, ни сулга каерылмыйча, бу кызны Агыйдел буена алып төшеп китәргәме?.. Чынлап та, менә шуннан туп-туры имәнлеккә алып кереп китсәң, ни уйлар иде икән?..
Ләкин бу теләк саф хискә нигезләнмәгән теләк иде, күңелнең ничектер, кызлар тансыклап, бер жилпенеп куюы гына иде. Гаяз абыйсын күз алдына китерде — күңеле шундук үз урынына төшеп утырды. «Чынлап уйлаганда, шатланырга иртә әле. Бик иртә...» диде ул.
Каршыга, юлны аркылы бүлгәндәй, ком юл килеп ятты. Ул мондый юлдан илле-алтмыш сантиметрга, ә урыны-урыны белән бер метр чамасы биек-калку иде. Мотоцикл аңа сикереп барып менде — Гаяз аны заготзерно ягына борды.

[1] Вак кына таш катыш эре ком жәеп ясалган юлларга бу якларда ком юл дип әйтәләр.

Өйлә вакыты житкән иде инде. Алардан әз генә алда Земфираның этисе белән әнисе дә төшлеккә кайтып керде. Туры үзләренә таба килүче мотоциклны күргәч, икесе дә болдыр төбенә басып, көтеп тордылар. Яннарына мотоцикл туктап, күренми килгән жирдән кызлары килеп төшкәч, әнисе шаккатып:

— Бәй! Земфира кызым, син түгелме соң? Каян килеп чыктың? Бер генә кеше утырган төслө иде ләбаса! — диде.

Нух аның кебек гажәпләнмәде, бик ягымлы тавыш белән Гаяздан:

— Юлларың ничек, үндымы соң, апай? — дип сорады.

Гаяз Зимфира төшкәнне генә көтеп торган иде.

— Үнды, — диде дә, Нухка әйләнеп тә карамыйча, Кави янына борылып китте. «Башка киңәшер кеше юк, киңәшим әле үзе белән», диде ул.

Кави авыз тутырып ак ипи белән ит ашап утыра иде. Каршында шешә белән сөте дә тора иде.

— Әйдә, апай, син сөйли тор, ә мин, Сәлмән карт әйтмешли, ашый торыйм, — диде ул. Елмаеп кына Сәлмән картны сөйләп алды: — Сугыш вакытында шулай трактор каравылчысы булып торган. Тракторчылар белән бергә моңа да ашарга бирәләр икән. Тик биргән ашлары Сәлмән бабайның кече теленә дә йокмый инде. Беррәт шулай колхоз боламык пешереп менгезгән. Сәлмән бабай үз өлешен тиз-тиз генә ашап бетергән дә, читкә борылып, тәмәке тарта башлаган. Тәмәке дә юк чак. Түбән оч Әбел-Нәгыйм түзмәгән, ашавыннан туктап: «Каяле, Сәлмән абзый, төпчеген булса да калдыр әле», — дигән. Сәлмән әйткән: «Бәй, апай, мә, тәмәкесен үк бирәм, дигән. Син тарта тор, ә мин синең боламыгыңны ашый торыйм», дигән. Әбел-Нәгыйм тәмәке тартып бетергәнче, майлы боламыктан жилләр искән шул. Мин дә шуның сыман инде. Әйдә, синең дә корсагың ачкандыр, ал әле менә бу кисәгең. Мөгаллимә жингән бүген мул тамызган.

Гаяз шунда гына үзенең бүген валчык та ризык капмаганын исенә төшерде — ихтыярсыз иткә үрелде.

— Авыз ит әйдә: яшь тәкә ите, — диде Кави, аннары үзе үк: — Шулай булып киткән икән Таһиржанның хәле, — дип, Гаязның үйларын бер эзгә салып жибәрде. Шуннан соң инде, ялгыш та бүлдермичә, Гаяз сөйләгәннәрне тыңлап торды. Кеше сөйләгәндә ул шулай, авызына су капкан кебек, тыңлый белә иде. Тик сүз эш турысына күчкәч кенә, бигрәк тә Хәйдәр исеме чыккач кына:

— Тапканнар икән кеше! — дип, сүзгә катнашып китте.

— Нигә? — диде Гаяз. — Общее руководствога бер өлкән кеше кирәк бит инде.

— Агач корты кебек үзәгегезгә үтә икән!

— Әйдә, үзең кайт алай булгач.

Шунда Кави, Гаяз бөтенләй икенче жавап көтеп торганда:

— И апай, бик кайтыр идем дә... — дип офтанып куйды.

— Ә нигә кайтмыйсың соң?

— Сәйдәшев абзыйга ни күзем белән күреним соң кайтып? Ул нәрсә уйлар? Артыннан ялынып килгәнне көткән иден дә тәпи-тәпи генә үзең дә кайтып килдеңме, дип әйтерме?

— Әйтмәс, — диде Гаяз. — Ике рәт очраштык, икесендә дә сине мактап торды. Син инде үзең, көйсез кияү сыман, артыннан ялынып килгәнне көтәсең. Сәйдәшев агай синең кебек эре түгел, «барып сөйләшәм», — диде.

— Син дә авыр сүз әйтмә әле, ичмасам, апай! Болай да башым дивана булып йөри. Бу яңа директор белән дә килешеп бетеп булмый. Колхоздан — монда, моннан — колхозга китеп йөрсәм, ничек була инде ул?.. Менә бит аның нинди ягы бар.

Земфира Гаязны бая бер ашарга чакырып киткән иде инде, әле тагын килде. Монысында инде эшкә китеп бара иде.

Аның артыннан ук диярлек Нух белән Локман да чыкты. Икесе дә янә өй ягына юнәлделәр. Локман Гаязларга таба күз дә ташламады. Ул Гаязның кайтып төшкәнен дә, Кави янына киткәнен дә күреп торды: башка вакыт булса, йөгереп яннарына килер иде — бүген килмәде. Бүген ул Гаязга үпкәләгән иде, ачуы чыккан иде.

Кави егетләре дә менә башлады, менгән бере, аштан соң дип, өй түләгәсенә килеп ава иде; бер вакыт барысы да, имезлек капкан сабый бала төсле, тәмәкеләрен имә башладылар.

— Ярый, мин дә кузгалыйм. Кит дип әйтүче булмас. — диде Гаяз.

Локман белән Нух бик бирелеп сөйләшеп утыралар иде. Мотоцикл тавышына шып тукталдылар.

Локман бая сөйләшкәннәрне исендә тота иде әле, шуңа яннарына Гаяз килү белән:

— Ничек соң, Сәйдәшев путевканы биреп тә җибәрдеме? — диде.

Гаяз тыныч кына:

— Путевка таба алмаса, хәерләр бирер идем дип, әллә ният әйтенме, төпчек абзый? — диде.

Локман Нух алдында, суга баткан бүрәнә шикелле, бүртенеп чыкты, гайрәте кайтып:

— Мин туры сөйлим, син кәкрәйтмә, улым, — диде.

— Бик туры инде — дуга кебек!

Локман инде аның алдында яхшы атланырга әзер иде, ләкин шул вакыт ул үзләренә таба Шагалиевның килүен күрде. Шагалиев, унике ел буе заготзернода директор булып эшләп, былтыр көз генә пенсиягә чыккан иде. Аңа хәзер — теләгән җиренә китеп яшәргә мөмкин булса да, ул беркая да китмәде, үзе торган өйдә яшәп калды. Быел яз тау башыннан җир алып, кар эрү белән үк, койма тотып куйды, ләкин йортка диган бүрәнәләре аста ята иде әле. Аның үзенең тау башына менәргә исәбе юк, җирне ул малаена алды: шунда өй салып, малаен башка чыгарырга җыена иде.

Шагалиевны Нух та күреп алды, йөзенә кара коелып:

— Әллә бу җирән алаша сине, Локман абзый, малаеның өен эшләттерергә кодалап йөриме? — диде.

— Әллә тагын? — диде Локман. — Әйткәне юк әле. Ихатасын карарга менәдер... Бер-берегезне бер дә яратмыйсыз инде, күрше булып ничек яшәрсез икән?

— Үзе менмәсә, малае белән килешеп була, — диде Нух һәм, Шагалиев килеп исәнлек бирү белән: — Кара, обед бетеп килә икән! — дип урыныннан торды.

— Өченче ярты инде сәгать, — диде Шагалиев.

Алар чынлап та бер-берсен яратып бетермиләр иде. Нух башта, кыткан елында, заготзернода эшләде. Ләкин аны эшкә Шагалиев үзе түгел, Зәкиев алган иде. Өч ел элек иде бу. Ул елны Шагалиев, ревматизм бәгәрләп салгач, өч айдан артык эштән аерылып торды: шуның ике аен больницада, бер аен Кисловодск санаториенда үткәрде. Зәкиев аның урынбасары иде һәм ул юкта бөтен эшләр — кеше алу һәм чыгаруларга кадәр — аның өстендә булды: Нухны Зәкиев нәкъ шул вакытта алды. Нух аның авылдашы иде, хәтта әнисе ягыннан дүртенче буын кан-кардәше дә иде.

Шагалиев белән алар арасы бигрәк тә җир бүлгәндә бозылды. Шагалиев аңа җир бирмәү ягында иде, чөнки Нух инде заготзерно эшчесе түгел: Зәкиев үзе күчкәч, аны да бер-ике айдан райсоюз системасына күчергән иде.

Локман Нух киткән якка башын селкеп, көлеп куйды:

— Бигрәкләр дә яратмый инде сине, Шагалиев. Сине күрсә, тан атәченнән курыккан шайтан төсле кача.

— Ул кемне генә ярата икән? — диде Шагалиев. — Үз әтисен дә яратмый бит ул. Кешедән оялмаса, бүген үк чыгарып ташлар иде.

— Шулай инде анысы... — диде Локман.

Гаяз, куләгәгә китеп, коралларын көйләргә утырды: бер көн эшләмәгәч, коралларга күптәннән кул тимәгән төсле иде. Ул балтадан башлады. Дөрес, әтисеннән калган балтасы каты иде, хәзерге түн тимер түгел — чапкан саен йөзе кайтарылмый иде. Шулай да, барыбер, көнгә бер көйләргә кирәк. Хәзер алар тәрәзә яңакларына тотыначаклар — димәк, аркылы балта да кирәк булачак, ә анысын, көйләү генә түгел, чарга үк тотып аласы бар; наструк тимерләренә ике көн инде кайрак, беләү тигәне юк иде.

Локман белән икәү генә калгач, Шагалиев сүз башлады:

— Мин синең янга менгән идем, Локман. Исәннән чыкмаган булса, без бер сөйләшкән дә идек инде.

— Өй чутындамы? — диде Локман.

— Ну.

— Моны бетерү белән синекенә генә күчәрнек тә бит, Шагалиев... Интәш юк.

— Бу егет Сөләйман абзый малае бит әле?

— Абзый мәрхүмнең төпчек улы инде.

— Ул ничек соң?

— Кырык җиргә тарткалыйлар әле аны. Гандәлиф, РТСка, ди. Анысына кичә отказ итте бугай инде. Сәйдәшев үзенә колалый — төзелешкә. Комсомольский бригада төзибез дип, Фаизының башы-күзе әйләнгән. Әбел-Гаязыбызның дәрте башта машинада ие. Хәзер, белмәссең, әллә балтада, әллә машинада? Синен директор чак булса, тартып кына алырсң дә бит... Менә үзен җайлап кына сөйләшеп карале. Ну, тегеләй, салып та бирерсек инде йортынны бер төсле! — Ул шунда, муенын сузып, Гаязга кычкырды: — Әбел-Гаяз, кил әле монда! Сиңа Шагалиев абыеңның бер сүзе бар.

Гаяз, тәмам бирелеп, балтасын көйли генә башлаган иде, торып алар янына килде.

— Нәрсә? — диде.

Локман җавап бирергә ашыкты, ләкин бик урау юлдан башлап алып китте:

— Менә син, улым, Шагалиев абыенны беләсең инде: ул инде — карт коммунист, безнең заготзерноны аякка бастырган кеше. Ие. Авторитетлы кеше. Хәзер пенсиядә...

Ләкин аның сүзен Шагалиев бүлде:

— Туктале, Локман, — диде ул. — Болары нигә кирәк? Син мине мактама да, яманлама да...

— Алай булгач, үзең сөйләш, бәй.

Шагалиев килгәч үк, аның нигә килүен Гаяз сизенгән иде инде, шуңа туп-туры үзе сорады:

— Әллә өй салдырырга йөрисезме, Шагалиев абый?

— Шулай шул. Улым, башка чыгып, шушында менәргә җыена бит. Менә Локман абзыеңны шуңа димләп торам әле. Әллә икенчесенә сине чакырып карарганы дип уйлаган идем дә ул үемнән кире кайттым инде.

— Чакырсагыз да, бармас идем, — диде Гаяз. — Әле генә төзүчеләр бригадасына язылып кайттым.

— Ну вот, бик әйбәт булган! — дип, Шагалиев хуплап куйды. — Балта эшенә китүең ярый: ни әйтсәң дә — әткәң һөнәре бит! Почетлы да эш аннан соң.

— Бүтән йомышыгыз юкмы, Шагалиев абый? — диде Гаяз.

— Юк, улым. Эшеңнән аерганга ачуланма инде.

Гаяз киткәч, Локман баш селкеп торды:

— И сөйләштең дә инде!..

— Ул яшь әле, — диде Шагалиев. — Бу яшеннән үк мондый юлга басмасын, дидем.

— Кемне табасың инде хәзер?

— Мамлиевтан сорыйм, — диде Шагалиев.

Локман дәртләнеп:

— Сора, бәй, Кавины! — диде.

— Тоттырыр Кавины сиңа! Хәмит кебеген бирсә дә шөкер.

Шагалиевның эшкә чакырып менүе Локманның үзенә дә өй салу теләген тагын кузгатып җибәрде. Шагалиев үзенә агачны райсовет аша гына алган иде, хәтта аңа, персональ пенсионер да булгач, бигрәк якыннан — Әңгәсәк урманыннан бирделәр.

«Тагын бер өйлек сорый аламы ул? Билгеле, сорый ала. Теләсен генә. Теләсә, аның авторитеты белән, районга дигән лимитны алырга була. Әллә әйтеп карыйм микән? Чынлап та. Сораганның битенә сукмыйлар», дип уйланып утырды да Локман, ниһаять, сорарга булды:

— Өеңне салырбыз аңысы, Шагалиев, — диде ул. — Миннән эш калмас. Түлке што син дә миңа бер яхшылык ит: агачка язу алып бир син миңа. Эш хакына сугарбыз.

— Нинди агачка? — дип аптырады Шагалиев. — Утынгамы?

— Утынга буламыни? — диде Локман. — Утынга — Кавиның да теле бар: сорар әле яңа директордан. Миңа бүрәнәлек агач кирәк.

— Үзеңәме? — диде Шагалиев.

— Үземә булмый, кемгә булсын?

— Бер дә андый уең юк иде бит әле, Локман?

— Юк иде дә бит — атна эчендә булды да куйды. Уйладым, уйладым да салыйм әле дидем.

Шагалиев көлемсерәп:

— Балта остасының аның, кешегә йорт салган саен, үзенә дә саласы киләдер инде, — диде.

— Килүдән түгел. Йортың әйбәт булса, бер дә килми.

— Синең өй таза күренә бит әле, Локман.

— Каян таза булсын сипләнгән йорт. Тыштан гына таза күренә ул. Эчтән череп агарга җиткән. Утыз ике ел тора бит инде. 31 нче елны сипләп салган идем.

— Нигә аны син ел башыннан әйтмәдең соң, Локман? — диде Шагалиев. — Үземә алганда ничек тә кушып сораган булыр идем әле. Хәзер булмый. Икенче катка сорый алмыйм. Агач алтын бәясе белән бер йөри.

— Ярар, йөрсә, — диде Локман. — Кешеләр таба — без дә как-нибудь тә табарбыз әле.

— Өй эшләү өчен бүрәнәне шарт итеп куймыйсыңдыр бит?

— Юк, нигә?..

Шагалиев кайтырга кузгалды. Үзенә: «Исән булып тор син дә!» — дип дәшкәч, Гаяз да өйдән чыкты.

Шагалиев киткәч, Локман бөршәеп калгандай булды. Башын игән, кулларын тез өстенә салган килеш, байтак утырды. Гаяз кузгалып китә алмыйча, төпчек абзыйсының бөкрәя төшкән җилкәсенә, баш түбәсенә карап торды. Төпчек абзыйсының башы кечерәйгән сыман иде, куллары да кечерәеп, себерке чыбыгыдай, тамырлары бүртеп-бүртеп чыккан иде. Гомумән ул, торышы-утырышы белән, караеп төерләнгән карт каен кебек иде. Шунда ул Гаязга әллә ничек кызганыч булып китте: җан тартмаса да, кан тарткан кеше — әтисенең энесе бит! «Аның да яшь чагы булган, бәләкәй чагы булган, хәтта анадан туган чагы булган», дип уйлады Гаяз. Ләкин боларның инде барысы да артта калган — хәтта булган кебек тә түгел, ә алда бер нәрсәсе дә юк иде.

Тора торгач Локман телгә килде:

— Эт үпкәләр — хуҗасы белмәс, — диде. Бу аның гомере буе тел очында йөрткән сүзе иде. — Ярар, бурәнә тапмаса тапмас, эшләрмен инде: акчасы булыр.

Гаяз да кызып китте.

— Шушы яшеңә житкән башың белән, акча дип, кешегә ялланып йөрмәсәң ярамыйдыр шул? Белмим, сиңа нәрсә житмидер. Гомер буе эшләгәнсең, ичмасам, картлыгында әзрәк ял итәр идең.

— Ялы да юк миңа, койрыгы да, — диде Локман. — Эшсез бер көн дә тора алмыйм — үләм.

— Бик эшлисең килсә, әйдә колхозга. Кил безнең бригадага. Арып эшләмә дә. Бир һөнәреңне яшьләргә. Ичмасам, даны икенче булыр. Ичмасам, картлык көнендә: «Акча сугып йөри», дип әйтмәсләр.

Локман көрсенеп куйды.

— Әгәр инәй мәрхүм терелеп, мине янадан тапса, мин гел син кушканча гына эшләрием, — диде ул. Гезенә таянып, жәһәт кенә урыныннан торды. — Әйдә, тотыныйк булмаса тәрәзә яңакларына.

Берме, икеме сәгать тын да алмый эшләгәннән соң, тураеп, бил язып торганда, Локман, күңеленнән һаман да әлеге сүзне дәвам итеп, Гаязга карады:

— Әгәр үземә генә аерым договор төзесәләр — мин эшләргә риза. Сүз-мазар чыкса, әйт Сәйдәшевкә шулай дип.

### Уналтынчы бүлек

Халидә иртәнге сәгать алтыдан кичке тугызга чаклы биш көн эшли дә биш көнен ял итә иде. Ләкин бу юлы аңа, икенче повар югалып тору сәбәпле (башта аны, чирләп ята, дигәннәр иде, ләкин соңыннан беленде: Зәкиев рөхсәте белән Уфага киткән булган) өч смена рәттән эшләргә туры килде, шуңа Халидә — биш көннән түгел — унбиш көннән соң гына кайта алды.

Ул автобус көтеп тормады. Пристаньдагы складка әледән-әле райсоюз машинасы йөреп тора иде — өстен дә алмаштырмыйча, шуңа гына чыгып утырды.

Юл буена башы катып, йөрәге ярсып кайтты. Кайта-кайта, күңеле тулып, елап жибәрде — тын гына елады ул, бите буйлап яше генә агып торды. Елагач, йөрәге бераз жибәргәндәй булды. Башта аның кайтышлый ук Гаяз янына кагылу исәбе юк иде: шушы кыяфәттә аңа күренәсе килми иде. Ләкин шунда исенә Гаязның, караңгы төшмичә, өенә кайтмавы килеп төште. Караңгы төшкәч инде, ул аларга барып керә алмаячак. Бүген дә, иртәгә дә шулай булачак. Ә Гаязны ул бүген үк күрергә тиеш. «Минем хәлне ул гына аңлаячак, ул гына миңа берәр киңәш бирә алачак», диде ул. Кульяулыгы белән битен-күзен сөрткәләде дә, машина заготзерно тавына житкәч, төшеп калды. Аның артыннан шофер:

— Нух өендә булса, мин килгәнне әйт әле! — дип кычкырды.

Төш вакыты иде. Чынлап та Нухның өйдә булуы мөмкин, дип уйлады Халидә һәм, яңа өй янында кеше-мазар күренмәсә дә, туры шунда китте. Бәхетенә, Гаязлар анда иде әле, ашарга керергә жыенып кына торалар иде.

— Мин соңыннанрак керермен, — диде Гаяз Локманга.

— Соңыннан синең өчен генә аш әзерләмәсләр бит.

— Әллә башта ашап чыгасыңмы, Гаяз? — диде Халидә. — Мин көтеп торам.

— Юк, кермим инде, — диде Гаяз. — Мондый эсседә ашыйсы да килми.



— Үзең кара инде, — дип, Локман ашарга кереп китте.

— Карале, Локман бабай, — дип кычкырды аңа Халидә. — Нух абзый кайткан булса, әйт әле: райсоюздан машина килде.

— Ярар, әйтермен...

— Минем сүзем бик озын, Гаяз, — диде Халидә, Локман киткәч. — Монда ничек, сөйләшеп булырмы?

— Юк, — диде Гаяз. — Ашагач та, төпчек абзый чыгып ята. Эшкә китешли Нухы да сугылып китә. Әнә чыгып та килә инде. Әллә синдә берәр йомышы бар микән?

— Әйдә тизрәк! — диде Халидә. — Күрәсем дә килми.

Алар имәнлеккә кереп киттеләр.

Гаяз картлар сөйләве буенча белә: монда сугышка чаклы йөз еллык имәннәр үсеп утырган булган. Тегеләйрәк аю яктылыгы да булган. Ләкин сугыш елларында — ирсез семьялар ерактан утын әзерли алмый башлагач — кисәргә рөхсәт иткәннәр. Өч ел эчендә йөз илле гектар урманнан туера гына торып калган. Хәзер шул туера белән тамырдан яшь имәнлек калкып үскән иде.

Алар, имәнлекне үтеп, Агыйдел буендагы ачык тау түбәсенә барып чыктылар. Бу түбә биек иде, моннан — өч яктан да — егерме-утыз чакрымнар җир күренә иде.

Халидә аркасы белән имәнгә сөялде. Икесе дә озак итеп Агыйдел өстенә карап тордылар. Күңелне башка уй биләп, күз инде караган нәрсәсен күрми башлагач, Халидә Гаязга сүз салмыйча гына:

— Серемне сыйдырырлык кешем дә юк бит минем, Гаяз. Ярый әле син кайттың... — диде һәм әкрен генә кайгысын сөйләп китте...

Халидә, кияүдән кайткач, башта бер ел чамасы заготзернода сельпо ашханәсендә эшләгән. Аннары аны Чакмагышка алты айлык поварлар курсына җибәргәннәр. Аннан ул район үзәгенә кайткан. Башта өлкән повар ярдәмчесе булган. Шуннан кинәт кенә Зәкиев аның үзен өлкән повар итеп куйган. Халидә үзе моңа каршы килгән: мин әле бу эштә яңа кеше, ун ел буе ашның эчендә кайнаган Дания ападан мин ничек өстен булыйм, аны куегызчы, аны булмаса, Нәҗипәне куегыз дип

карышкан. Ләкин, руслар әйтмешли, приказ есть приказ — ул эшләп киткән, эшләргә мәҗбүр булган. Дөрес, эштә үзен сынатмаган, ләкин Зәкиевнең бар исәбе Халидәне үзенә аудару, үзенең сөяркәсе итү булган икән...

Халидә сөйли торган җиреннән елап җибәрде.

— Кем дип уйлый микән ул мине?.. «Бер кияүдән кайткач, боргаланлың ни, боргаланмадың ни — барыбер синең турыда әйбәт сөйләмиләр инде», ди. Нигә шундый дип уйлый ул мине? Кияүдән кайткан дигәч тә, шундый түгел бит мин. Гаяз, әйт әле, акыллым, әллә мин шундыйга ошаганмынмы?

— Юк, син андый түгел, Халидә,— диде Гаяз.— Андыйлар икенче төрле була. Андыйлар кияүгә бармыйча да, шундый булалар. Ә син андый түгел. Син — районда бер матур. Шуңа сиңа барысының да күзе төшә...

Халидә, башын күтәреп, Агыйдел аша аръяк болыннарга, ерак авылларга, олы таудай өелеп торган әүлия зиратына, аннан да арырак — Әңгәсәктән Никола-Березовка якларына сузылып киткән күгелҗем тауларга текәлде. Хәсрәтсез-кайгысыз үткән бала чаклары да, әнә шул зәңгәр таулар шикелле, еракта иде — сизелмичә генә офыгыннан югала бара иде.

Гаяз, күзен дә алмыйча, аңа карап торды. Халидәнең йөзе, кояшның бөтен нурларын җыйган кебек, тутлы-карасу, ләкин күзләрендә аяз күк төсе бар иде. Шул төс аның күзләрен тагын да зурайтып, тагын да төпсезләндереп күрсәтә иде. Бу күзләр һәрвакыт иртәнге чык төшкән шикелле дымланып, Агыйделдәй саф, Агыйделдәй садә иде.

«Юк, Халидә, син булганда, бүтәннәрне ярата алмам!..» диде Гаяз эченнән.

— Исеңдәме Җәмилә апаны озаткан көн? — диде шунда Халидә. — Алар бит «Тукай» пароходы белән киттеләр. Әниләр дебаркадерның уртасында, ә без борынында басып озаттык. Аннан соң без ярга чыктык та пароход артыннан йөгердек. Йөгерә-йөгерә, менә шушы тауга мендек. Пароход Шәяхмәт бакеныннан борылып, Күгәрчен болынына кереп югалганчы, менә шулай карап тордык. Исеңдәме?

— Исемдә,— диде Гаяз. — Анда да без нәкъ менә шушы төштә басып торган идек.

— Берләнбер апам да шулай китте. Шунда мин, Җәмилә апамны инде сагына башлап, жылап җибәрдем... Җәмилә апа мине бик ярата иде. Мин җылаганда, син башта аптырап, аннан нидер әйтергә итеп, миңа карап тордың. Нигәдер син шунда миңа: «Жылама, мин дә сине яратырмын», дип әйтер төсле идең. Мин җылаудан шундук туктадым, тик син — әйтмәдең. Аннан соң да әйтмәдең... Аннан инде син киттең...

— Менә кайттым бит...

— Бик соң кайттың шул... Бик соң!

Гаяз ике кулы белән дә Халидәнең яңагыннан тотты, яшьле күзләренә карап сөйли башлады:

— Бер дә соң түгел!.. Хәзер без күп нәрсә күрдек. Кешеләрне дә, үзебезне дә сынадык. Сине оныта алмавым миңа үзе бер сынау булды. Әлек әйтә алмаганнарның да үчен кайтарыйм ичмаса: сине генә яраттым Халидә! Ышанасыңмы?

Халидә аның күзләренә карады һәм әкрен генә:

— Ышанам... — диде.

— Ышансаң, иртәгә үк барып эшеңнән чык. Кайт үзебезнең авылга. Кайтасыңмы?

— Аһ, Гаяз,— диде Халидә. — Сөйләп бетермәдем бит әле. «Бетмәгән Зәкиев булды инде», дип уйлый күрмә тагын.

— Төкер шул Зәкиевның башына! Тагын бер бәйләнсә, чап та җибәр янагына — күзеннән утлар чәчрәп чыксын.

— Алай гына булса икән! Мине ул хәзер, болай җиңәлмәгәч, куркытып җиңәргә итә, — дип, Халидә ашханәдәге хәлләрне сөйләп алып китте: — Шулай икенче сменада эшләүче поварның биш көн эчендә ике йөз илле сумлык продукты житми чыкты. «Сдача-передача вакытында андый гына житмәүчелек була инде ул, аларны шулай бер-беребезгә язышырбыз, соныннан списайт ителә ул», ди. Без аның белән дус эшләдек, мин аңа ышандым. Алдым дип, ике йөз илле сумны да описька керттем. Ә бүген, аның үзенә тапшырырга чират житкәч, ул, бу сумманы описька алмыйм, ди. «Списаниегә общий акт төзелгән, Зәкиевта», ди. Мин Зәкиев янына кердем, ул миңа төрле число белән язылган биш-алты акт сузды. Аларда продуктларның кайсы бозылган, кайсы чүчкаларга ашатылган дип язылган иде. Барлыгы 1414 сум списаниегә кертелгән иде. Минем чәчләрем үрә торды. «Зәкиев абый, мин моңа кул куя алмыйм»,— дидем мин. «Уйла,— диде миңа Зәкиев.— аның ике йөз илле сумы синең өстә», — диде. «Минем өстә була алмый ул, — дидем мин. — Мин Факия апаның житмәүчелегенә кул куйдым. Әнә үзе монда, үзеннән сорыйк алай булгач», — дим. Факия апаны чакырып алып кердем. Ләкин ул Зәкиев алдында баш тартты. Мин ачуымнан икесен дә өзгәләп ташларга житешеп өстәлгә сuктым: «Барыбер куймыйм. Өскә чыксын — бергә түләрбез. Төрмәгә япсыннар — бергә утырырбыз, күңеллерәк булыр!..» — дидем дә чыгып йөгердем, Сабирҗан китмәгән иде — шуңа утырдым да кайтып киттем.

— Ул акчаны кайтарып бирергә буламы? — диде Гаяз.

— Кешеләрдән бурычка сорап торырмын димен инде.

— Кайгырма, Халидә. Үзем дә ярдәм итәрмен.

— Рәхмәт, Гаяз... — диде Халидә.

Аның өстеннән кинәт тау төшкәндәй булды. Ул үзенең бәладән генә түгел, Зәкиевтан да котылуын сизде. Моңа хәтле дә ул, Зәкиев бәйләнә башлагач: «Бу гарьлеккә түзә алмам, Зәкиев белән бергә эшли алмам, китәрмен», дип уйлаган иде. Ләкин бүгенге хәлләрдән соң эштән китү бөтенләй тормышка ашмас бер нәрсәгә әйләнде. «Пычраттылар болай булгач», диде ул. Юл буена, Сабирҗан машинасыдай, ярсып кайтты. «Ничек акча табарга! Ничек табарга?..» Кайтканда бөтен уе шул иде.

Ул, озак итеп, Гаязның күзенә карап торды. Бу күзләр алдамый иде, бу күзләргә ышанырга була иде. Һәм Халидә, эссе тыны белән бергә кайгысын да өреп чыгаргандай, көрсенеп:

— Аһ, Гаяз!.. — диде.

Имәнгә сөялеп торган килеш кенә кулларын сузып, Гаязны кочаклап алды...

Югарыдан пароход килә иде. Быел пароход та күргәнем юк дип, Халидә пристаньга төшәргә булды.

Алар, яр буеннан әз генә кире килеп, иске юлга чыктылар. Халидә шул юлдан пристаньга төшеп китте. Бу юлны жәй көне буеннан буена үлән баса: аннан хәзер ни атлы, ни жәяүле йөрми, йөрсә дә, шушылай, имәнлеккә чыккан кешеләр генә йөри иде. Быел әле аяк басучы да булмагандыр, дип уйлады Гаяз. Юл уртасына баскан килеш, Халидә артыннан карап торды. Халидә, бераз жир киткәч, артына әйләнеп, аңа кул болгады.

Гаяз имәнлек эченнән турылап Нухлар ягына таба китте. Көн сайлап алган кебек яхшы — жилсез, болытсыз иде. Имәннең котырып яфрак ярган чагы: күзәнәкләре буйлап аккан кайнар «канын» инде бернинди суык та туктата алмас — куе-яшел яфраклары лакка манган төсле ялтырый һәм күз алдында зурая баралар иде.

Якында гына шәүләгән сайрарга тотынды. Гаяз аңа җавап бирде: ул бәләкәй чакта ук әле анынча сайрарга өйрәнгән иде, лэкин аның

шушы вакытка хәтле шәүләгәннең үзен күргәне юк иде. Менә ул экрен генә тавыш килгән якка бара башлады. Ләкин тавышсыз бару мөмкин түгел: аяк астында коры чыбык-чабык сынып китә иде. Кош тынып калды һәм, Гаяз карапып торган арада, бөтенләй икенче яктан тавыш бирде. Тик инде Гаязның игътибары кошта түгел, үзеннән бер кырык-илле метрлар алда йөгереп баручы малайда иде. Малай, гүя ападан качкан кебек, артына әйләнеп карый-карый йөгерә иде. Гаяз аны башыннан таныды: ул — Нухның ун яшьлек, зур башлы малае иде. Гаяз адымын шәбәйтеп малай артыннан китте. Кайтып керү белән, төпчек абзыйсыннан:

— Нух малаен мине чакырырга җибәрмәгән идеңме? — дип сорады.

— Юк. Нишләп җибәрим, үзем дә тотынмаган көе? Уйнап йөргәндер, — диде Локман һәм, жае чыгудан файдаланып, кисәткәндәй әйтеп куйды: — Карале, Әбел-Гаяз улым, нигә инде син шул Галәү кызы белән иманлеккә кереп йөрисең? Көпә-көндез! Артыгыздан Нух көлеп карап калды. Йөри торган нәрсә икән ул. Аның белән данның чыга күрмәсен.

Локман үкенеп сүзеннән туктады. Ул инде Гаязда үзеннән өстен көч барлыгын танып, теле белән дә, гамәле белән дә аңа каршы бармаска дип карар кылган иде. «Тагын телемә баш була алмадым», диде ул. Ләкин Гаяз, аның гаҗәпләнүенә каршы, авыз ачып бер сүз әйтмәде. Аның кәефе шәп иде бүген, шуңа төпчек абзыйсы белән сүзгә керәсе килмәде: керсә — үзенең генә кәефе китәчәк иде. Аннары ул бүген кич Нух белән сөйләшергә җыена һәм күңеленнән шуңа әзерләнә иде. «Ярый, Нухка монысын да кисәтеп куярга кирәк булыр», диде ул.

Аларның сүзе кичке аш вакытында булды. Өстәлгә Нух, «проба» дип, бер графин бал утыртып куйган иде, үзе инде «пробасын тикшереп караган», ләкин бал аның ашказанына килешмәгән: колак яфрагына хәтле бурлаттай кызарып, битенә, муенына борчак-борчак тимгел типкән иде.

Гаяз балга авыз да тигезмәде. Аның каравы, бал Локманга бик килеште. Беренче стаканны эчү белән:

— Хәзерге аракыларың бер як читтә торсын, — диде.

— Онытып торам икән, — диде Нух. — Синең өчен, Гаяз апай, «столичный» бар.

Торып, гардеробтан «столичная» дигәнне алды. Ул Гаязны, кызы белән дуслашып киткәч, ничектер якын итә башлады. Инде ул аның Земфираны яратып китүен тели иде, бер алдына, бер артына төшеп, аңа ярарга тырыша иде.

Аш булгач, Фәгыйлә белән Земфира да килеп утырды. Гаяз аракыдан да баш тартуны килештермәде: «Кылана дип уйларлар я», диде һәм салган йөз граммны эчеп, артыннан яшь кыяр кабып җибәрде. Ләкин аның эчүне дә, ашауны да бик озакка сузасы килми иде, шуңа тизрәк йомышын әйтергә ашыкты.

— Өегезне салып бетереп килләбез инде, Нух абзый, — дип башлады ул. — Моңарчы, ни төпчек абзый, ни мин акчаны телгә дә алмадык, сорамадык. Бүген сорарга туры килә: миңа иртәгәгә ике йөз илле сум акча кирәк.

Нух, билгеле, моны көтмәгән иде, ул аптырабрак калды. «Ничек болай килеп чыкты соң әле бу?» дигәндәй, Локманга карады. Ләкин Локман үзе, ападан да болайрак, аптыраштa иде, шулай да ул, беренче кабат, теленә килгән сүзне әйтүдән тыелып калды. Сүзләре бердер болай булгач дип, Нух Гаяздан үзе сорады:

— Нишләп шулай бик тиз кирәк булды әле, апай, сиңа ул акча?

Гаяз аңа дөресен әйтә алмый иде, шул ук вакытта курәләтә, йөзгә бәреп, алдыйсы да килми иде.

— Абыйны санаторийга җибәрәбез, — диде ул.

— Шулхәтле акча беләнме? Нәрсәгә аңа ул хәтле акча? Путевкасы буш...

— Булса ни? Коры путевка тоттырып кына җибәреп булмый бит. Юлы бар, ние бар... Өстен дә рәтлисе бар.

Ләкин аның сүзенә Нух ышанмады, аның күңеле нәрсәдер сизенгән сыман иде, тик нәрсә икәнен әчкән башы эшләп житкерми иде.

— Бәлкем, апай, йөзе дә житәр? — диде ул. — Бетеп килә дисән дә, өйнең эше житәрлек әле.

Шунда Земфира түзмәде:

— Нигә сатулашып торасың инде, эткәй? — диде.

Фәгыйлә дә:

— Кая тотса да тотар, анысы безнең эш түгел. Бир, Хәсәншин, — диде.

— Бирмим дип әйтмим бит әле мин, — диде Нух. Торып түр яктагы сандык янына китте. Сандык өстенә өй биеклеге итеп түшәк-ястык өелгән иде. Нух, тезләнеп ачарга җыенгач:

— Алыгыз әле шушы мендәрләрегезне! — дип кычкырды.

Земфира зур-зур кочак белән мендәрләрне идәнгә алып куйды. Сандык бик борынгы иде, ләкин йозагы имгәнмәгән иде: ачылганда сәгать суккан тавышлар чыгарды. Нух, сандык авызына гәүдәсе белән капланып, эчке яктагы бүлемнән акча санап алды: йозагын бикләп, өстәл янына килде. Гаяз өстәлнең аңа каршы ягында утыра иде. Нух бармагын төкреклэп алды да, өстәл аша иелә биреп, Гаяз алдына таушалып беткән егерме биш унлык санап ташлады. Гаяз, бер сүз дә әйтмичә, унлыкларны җыеп кесәсенә салды. Локман, үз акчасын биргән кешедәй, ризасыз бер кыяфәт белән аңа карап тора иде.

— Син борчылма, төпчек абзый, — диде аңа Гаяз. — Төп оста син булдың, күбрәк тә эшләдең, сөйләшкән дүрт йөз илле сумның ике йөз илле сумның илле сумның илле сумның ике йөз иллесе сиңа тиеш. Шуна риза булсаң, иллесен соңыннан бирермен.

— Бирәм дип хафаланма, улым, — диде Локман. — Миннән Таһирҗанга булыр. Только әйтеп бир: монысын төпчек абзый бирде, диген.

Моннан соң инде Гаяз ашап та, эчеп тә тормады, ашка рәхмәт әйтеп, кайтырга кузгалды.

## Унҗиденче бүлек

Сал төнлә кайтты. Моннан егерме-егерме биш ел элек салларны заготзерно борылмасына гына китереп сылаталар иде; ул вакытта әле, имәнле таудан төшкәч тә, болындай тигез чирәмлек бар иде. Агачны башта шунда чыгаралар, аннан инде, заготзерно территориясенә кермичә, бу якка да, теге якка да ташып була иде. Хәзер инде түбән яр юк, кыядай киселеп-ашалып төшкән тау гына күкрәген ачып тора иде. Ә заготзерно үзләренә кайткан салдан башканы үз турына туктаттырмый иде. Шуңа күрә салны хәзер авыл астына бәйли башладылар, ләкин монысы үзе бер бәлагә әйләнде: башта салны беренче борылмага китереп бәрдермәс өчен, башыннан бер, койрыгыннан икенче катер болын ягына өстерн; ул арада Минеште тамагы үткән була инде, көянтәдәй бөгелеп, Агыйдел уртасына кергән салны катерлар ике очыннан, көчәнеп, бу якка этәрә башлыйлар; ул, авылдан әз генә китеп, икенче борылмага килеп төртелә иде. Бу юлы да шулай булды.

Әле көндез үк, аның Бишбүкән борылмасына житү хәбәрен алып кайту белән, колхозның бер тракторы, унбишләп балта остасы аны көтеп тора иде инде. Заготзернодан да бер бульдозер һәм биш кеше килде. Аларын, Мамлиев белән алдан сөйләшү буенча, Нух алып кил-

де: салны колхоз белән райсоюз бергә берләшеп алып төшкән иде. Анда, колхоз егетләреннән тыш, Караиделгә Нух үзе менеп яллаган ике профессионал салчы да бар иде. Асылда бөтен җитәкчелек шулар кулында булды.

Карацгы төшүгә салны ярга бәйләп-ныгытып куйдылар, иртә таңнан беренчен тоткарлыксыз чыгара башлау өчен, бульдозер һәр кушма турына сөзәкләп юл ярып төште. Ул көнне барысы бергә эшләде, ә иртәгә инде колхоз үзенекен, райсоюз үзенекен чыгара башлаячак иде.

Нух шул ук кичне кайтып өенә генә кагылды да туры килгән беренче машинага эләгеп, райүзәккә китеп барды.

Ашханә-ресторан ябылган иде инде. Ул туры Зәкиевләргә барып төште. Зәкиевләр ятмаган иде әле.

— Нәрсә бар? — диде Зәкиев.

Нух, башы белән генә, Хәдичә ягына ым ясады. Хәдичә колакка катырак иде. Кеше алдында белгертмәгән булып йөрсә дә, әкренрәк сөйләшкәнне бөтенләй ишетми иде. Шулай булса да Зәкиев аны кече якка чыгарып җибәрде. Түземсезләнеп:

— Әйдә, сөйлә инде, — диде.

Алар берсе Караиделдән, берсе Уфадан кайтканда очрашып, пароходта килешеп куйганнан бирле, борчылып сал кайтуын көтәләр иде. Ләкин Нух сүзне аннан башламады. Салны «кайтты» дип кенә әйтте дә, «сонынна»га калдырып, Халидәдән башлады, үзенең иртәне дә көтмичә чабып килүен «бигрәк тә шуның өчен» диде.

— Ничава! — диде Зәкиев.— Койрыгына бастым инде мин аның. Менә этисенекенә дә баса алсак, майлап җибәргәндәй булыр әле. Минем кешеләр әзер, якын абзый. Иртәгә үк синең белән бергә китәләр. Моннан, исәнәеп бара башлаганчы, озатырга кирәк. Салны алар да чыгарышсын. Сорасалар, райсоюз кешеләре диярсез. Ишетсен колагың: сорасалар гына!

— Анысын белермен лә!

— Бер рейс алып кайткач, калайны алып баралар. Калай кәгазен үзенә соңыннан бирермен. Кара аны, якын абзый: алай-болай итенә күрмә — кәгазе булмаса, өй түбәңнән куптарып алып китәчәкләр. Смотри!

— Белмим, нәрсә булып бетәр инде, Мәгънәви апай?

— Халидәнең этисе эчәме?

— Аракы эчми: ашказаны авырта. Спирт булса гына инде.

— Анлык кына спирт табарбыз. Ә райсоюз сал чыгартырга күпме акча бирә соң?

— Менә өч йөз сорап карыйм әле. Күпме бирер?

— Өч йөз үк бирмәс. Өч йөз күп.

— Ну, ике йөз бирсен ди.

— Күпме бирсәләр дә, шуның яртысын аракыга әйләндер. Только ведомостька аек чакларында кул куйдырып кал.

Иртән сәгать тугызда Нух райсоюзда иде инде. Председатель өч йөзгә якын да килмәде. Ике йөздән артык бирә алмыйбыз, диде. Нух ике йөз илле сорап карады. Ләкин җавап бер иде: «Ике йөз! — башка бирә алмыйбыз».

Өч йөзне болай гына сораган Нух ике йөзенә дә бик канәгать булып, контораддан чыкты.

Зәкиев егетләре аны машиналары янында көтеп торалар иде инде. Ике машина, дүрт кеше иде алар. Дүртесе дә яшькә утызлар тирәсендә, буйга бик озын булмасалар да, нык күренәләр иде. «Ничава, болар белән тәяп була!» диде Нух. Тәгәрмәчләренә басып, ике машинаның да кузовларын карады. Кузовлар буш, калай салмаганнар иде. «Калай-

ны Гаязлар киткәч китерү — бер караганда яхшы да», — диде Нух һәм кабинага төшеп утырды.

Ул, иртә таңнан уянып, бөтенесен дә уйлап куйган иде инде. Шулай да уйларын күңеленнән тагын бер кабат тикшереп чыгарга булды. Кайтыр юл озын, бүтән уй башка барыбер кермәячәк иде. «Салда биш кушма. Кушма саен икешәр кеше житә — ун кеше. Бер трактор. Бүрәнәләрне аерып бәйли торалар, трактор чиратлап чыгара тора. Унбишәр сумнан — йөз алтмыш биш сум. Калган утыз биш сумына, икеләнмичә, аракы алып куярга була. Көндез ике кешегә бер литр. Кичкә үзләреннән тагын тотасын... Көндез яшермичә-нитмичә бер рейс жибәрсәң... Кичсез урап килмәячәкләр. Галәү каравылга төнгә генә төшәргә тиеш: аңа спирт бар. Спирттан баш тартмас. Колхоздан каравылга убыр Сәлмән төшсә, ул инде аракы дигәндә кабереннән ләхетен күтәреп чыгачак...»

## Унсигезенче бүлек

Көн буе диярлек салкын суда эшләгәнлектән, салчыларга колхоз көндез икешәр йөз грамм аракы, ә кич судан чыгу беләи йөзәр грамм спирт бирде.

Флүс Гаязлар янына менгәндә ярыйсы ук кызарган иде.

— Менә салдан кайтып килəм әле, — диде ул сорамасалар да.

— Нишләп бик иртә? — диде Локман.

— Нишләп иртә булсын? Сәгать сигез туладыр бит инде.

— Рамазан абзыең кайттымы? — диде Локман.

— Кайтты.

— Колхоз эчердеме, үзегезме?

— Колхоз да эчерде... Йөзәр грамм спирт бирде.

— Ул да эчтеме?

— Рамазан бабаймы? — диде Флүс. — Спиртне тешкә йомшак нәрсә икән бу дип, йотып кына жибәрде.

Локман төпченүендә булды:

— Исереп-мазар китмәдеме?

— Юк. Кайткач кына тагын салмаса, исермәгән иде алай.

Размулла карт үлгәч, Рамазан муллалык итә башлаган иде. Анысы карт түгел иде әле, илле жиде беләи генә бара иде, ләкин колхоз эшендә дә эшли, муллалык та итә ала торган соңгы буын иде.

Көндез, Сәмигулла карт бик авыраеп киткәч, Фаягөл кортка аңа күрше малаен жибәргән иде, күрше малае: «Өйдә юк, сал чыгарырга киткән», дип кайтты. Әле инде Локман Рамазанның салдан кайтканлыгын әйтергә кереп китте. «Сәмигулла абзый жан биргәнче, чакыртсын, йөз грамм спирттан генә исереп китмәгәндер әле. Ќакрас, күңелләнеп ясин чыгарлык кына...»

Ул киткәч, Флүс Гаяз янына килде.

— Синең белән бер утырып сөйләшәсем килә, Гаяз абый, — диде ул. — Без икебез дә бер бригатта эшләячәк кешеләр инде. Әйтим әле мин сиңа бер сүз: теге көнне мин синең белән сугышырга ук уйлаган идем.

— Һе, — диде Гаяз. — Нәрсә өчен?

— Земфира өчен инде. Кайттың да тартып та алдың. Син юкта мин аның янына берәүне дә жибәрми идем.

— Көчең беләнме?

— Ә нигә? — диде Флүс. — Син дә көч белән алдың бит.

— Әй, Флүс, Флүс, — диде Гаяз. — Мәхәббәттә көчкә таяналармыни, ә?

— Ә син үзең нигә таяндың? — Ул кыза башлады.

— Без болай сөйләшә алмабыз, Флүс апай, — диде Гаяз коры гына.

— Нигә?

— Безнең градуслар туры килми: я син аек түгел, я мин исерек түгел.

— Бәй, Гаяз абый, градусларны туры китерергә була аны, — диде Флүс, йомшарып. — Менә. Сөйләшергә дип алдым.

Ул шапылдатып кесәсендәге шешәгә сукты.

— Бик иртә тотынгансың! — диде аңа Гаяз. — Минем белән аракысыз сөйләшә алмам дидеңмени?

Флүс әле эчкәннән коса торган гына егет иде, ул эчүнең начар икәнен үзе дә белә иде, аның әле башланмаган ояты да бар иде, ләкин үзен акларга итенүе чын эчкечеләрчә килеп чыкты:

— Барысы да эчә бит, — диде ул. — Әнә райсоюзныкылар жыйнаулашып сталавайда эчәргә калдылар.

— Башкалар эчсә дә, син эчмә, — диде Гаяз.

Локман да урап килде.

— Син монда нишләп торасың инде китмичә? — диде ул Флүскә. — Йомышың миндә булса, әйт тә тай әйдә! Кеше эшләгәндә эт шикелле карап торганны җенем сөйми. Син эчкәч тә, без эчмәгән бит.

Монысы Флүскә житә калды. Ул тиз генә кесәсеннән башланмаган яртыны тартып чыгарды.

— Мин моны Гаяз абый белән эчәргә дип алган идем. Ул эчмәде. Алай булгач — менә! — диде ул һәм шешәне, муеныннан гына тотып, ишек янагына китереп бәрде һәм, берни булмагандай, әкрен генә кайтып китте.

— Әрәм итте яртыны, селәгәй малай! — диде Локман. — Почмакка гына утыртып китсә ярамагандыр шул...

Рамазанны алырга киткән күрше малае, ике кулын селтәп, кайтып та житте.

Аның артыннан ук өйдән Фаягөл кортка килеп чыкты. Ул, капланып егылырга житешеп, Локманнарга таба килә иде. Локман, эшеннән туктап, аны көтеп алды.

— Нәстә дип кайткан? Килә диме?

— Исерек ди, чукынмыш мулла! Салдан исереп кайткан, ди. Мин аңа бер ясин чыктым инде, шул ярый дип әйтә ди, каплангыры! Әйдә инде, Локман, син булса да кер. Телдән калды.

— Әй, жингәй! Бер дога да белмим бит мин, — диде Локман.

— Карт башың белән бер дога да белми булмас.

— Ун яшемнән эшләдем мин, жингәй. Укуның искесе дә, янасы да тимәде.

Шулай да ул кермичә калуны килештермәде, «ла илаһе илла аллаһе»-сен булса да әйтермен дип. Фаягөл кортка белән өйгә кереп китте.

Ярты сәгатьтән кире чыкты.

— Менә: барие кеше — юк та булды, — диде. — Шулай авыр шул ул жан бирүләре! Иртәдән бирле жаны чыкмый интекте бит мескен. Котылды инде... Ярый, син бар, кайт, Әбел-Гаяз. Иртәгә килмәскә. Мин калам. Безнен дә үләсе бар бит. Тәки шулай эт хөкемендә үләрсең. Таракан ташлаганнармыни — берсе бер кайтып күренми. Син, кайтышлый ук, Нухны эзләп тап. Салдан кайтсалар, әллә кайда түгелләрдер әле — сталавайда утыралардыр. Аннары Сафиулла, Әсләх картларга әйт. Калганнарга алар әйтер.

Сельпо ашханәсе заготзерно ягында, конторадан ерак түгел иде. Сигездән алтыга кадәр эшләве сәбәпле, бу вакытта ул, билгеле, ябык булырга тиеш иде. Ләкин Нух көндез үк мөдир белән дә, буфеттагы хатын белән дә сөйләшеп, буфетны кич ачарга булдылар.

Һәм менә хәзер салдан чыланып кайткан кешеләр — өстен алыштырганы өстен алыштырып, алыштырмаганы борып кына киеп, ашханәдә утыралар иде. Нухныкылар: биш кеше — Кави бригадасыннан, авылдан һәм заготзернодан тагын биш кеше, бер тракторчы, Галәветдин карт, Сәлмән карт — Нухның үзе белән барысы унөч кеше иде. Ашханә ишеге ачык булгач, алардан башка тагын берничә кеше кергән, ләкин алары әле болар белән кушылып-буталышып бетмәгәннәр, үзле-үзенә бер читтәрәк утыралар иде.

Ашханәнең урамга караган дүрт тәрәзәсе дә ачык, һәм шуңа күрә Гаяз, әле килеп житмәс борын ук, ишетте: салчылар, салып алгач, күлдәге бакалар кебек бакылдашалар иде. Ләкин, Гаяз килеп житкәндә генә, кинәт тынып калдылар. Гаяз, аптырый төшеп, ашханәгә керде.

Кави белән Нухтан башка аңа игътибар бирүче булмады. Барысы да кызган, барысы да Сәлмән картка таба әйләнеп утырганнар. Ә Сәлмән, ялгызы бер өстәлдә, алдында таудай өелеп яткан килькаланы ашап тора иде.

Гаяз, Кави янына барып, нәрсә булганын сорады.

— Менә ярты литрга бәхәсләштеләр: Сәлмән абзый бер кило кильканы ашап бетерсә, Нух аңа, «ярты» бирә. Шушында ук эчеп бетерергә, — диде Кави.

Сәлмән карт кильканы авызына инде учлап тутыра башлады. Ул аның хәтта эчен дә алып тормый иде.

Гаяз Нухның колагына иелде.

— Әтиең үлде.

Нух, жиңел сулап, сикереп торды.

— Булды, Сәлмән абзый, — диде ул.

Сәлмән, авызын күтәреп, аңа карады, ләкин сүзен әйтә алмады: авызы тулы килька иде.

— Егетләр, эткәй үлгән, — диде Нух.

— Ай, мескен! — диде Галәветдин карт.— Җаны җәннәттә булсын.

Ул спиртны, ашказанына дару булмасмы дип, илле грамм чамасы гына эчкән дә, әле Нухның кан дошманына әйләнеп, ап-аек килеш утыра иде.

— Төпчек абзый картларга да әйтергә кушты. Үзе әле сездә калды, — диде Гаяз.

— Сәлмән абзый, Галәветдин абзый, — дип Нух бер-бер артлы икесенә дә карап алды. — Картлардан монда сез генә инде. Эткәй янына менеп утырмассыз микән?

Сәлмән беренче булып ризалык бирде:

— Мондый йоладан баш тартып булмый инде, апайлар. Үлем агач башыннан йөрми — адәм башыннан йөри.

— Шулай,— диде Галәветдин дә.— Үлмәктән калмак юк... Түлке без, Нух апай, Сәлмән белән икебез дә каравылга барасы кешеләр бит әле.

Нух ни дә булса уйлап җавап биргәнче, башкалар да телгә килде:

— Каравыл дип инде, мондый вакытта, Галәветдин абзый.

— Синең салыңа чуртым булырмы?..

— Кайтыр жиренә кайткан инде...

— Шулаен шулай да бит... — диде Галәветдин.

— Салны аллага тапшырдык, — диде Сәлмән карт.

— Ярый, хәерлегә булсын, — диде Галәветдин дә.

Нух Сәлмәнгә дип кулында тотып торган яртыны кесәсенә алып салды, чүллидә спирт иде, аныкын эчке кесәсенә тыкты.

— Әйбәт кенә утырыгыз инде, егетләр, — диде ул, һәм алар, өчесе бердәй кузгалып, чыгып киттеләр.

## Унтугызынчы бүлек

Төнлә ишек дөбердәттеләр. Гаяз аны ишетмәде: каты итеп төн йокысы белән йоклап кына киткән иде. Ачык яткан иңбашына әнисе кулы тигәч кенә, уянып китте. Куркып сикереп торды. «Әллә бәлкабзыйны?..» дигән уй эчен телеп төште. Ләкин Таһир яткан түр почмактан тигез генә сулыш алган тавыш килә иде. Шуннан соң гына күңеле тынычланып:

— Нәрсә? — дип сорый алды.

— Галәветдин бабаң сине чакыра, киенеп чыксын әле дип әйтә, — диде әнисе.

— Нәрсә булган тагы?

— Сорамадым. Җәтрәк бул. Көтеп тора.

Гаяз сәгатькә карады: сәгать унике тулып кына киткән иде.

Галәветдин карт, Минеште тамагын кичкәч, ындыр артлап кына менгән, шактый кызу килгән булырга тиеш: Гаяз киенеп чыкканда, болдырда хәл җыеп утыра иде.

— Карт сөяк белән бик чабып булмый икән — буыннарыма төште, — диде ул. — Ачуланма инде уятканга. Үзем генә барырга шикләндем.

— Нәрсә булды соң, чибәр бабай? — диде Гаяз.

— Әйдә, бара-бара сөйләрмен.

Алар олы урамга чыктылар, шунда гына Галәветдин, беразтынычланып, сөйли башлады:

— Безне Нух алып менеп китте бит? Без мендек. Өйләрендә Фаягөл корткадан башка беркем юк, семьяләре күршеләргә кереп беткән. Локман анда иде. Ул әле дә анда калды. Шулай утырабыз мәет саклап. Нух тышка чыга да керә, чыга да керә. Байтак кына эчкән иде бит, күңеле болганадыр инде, мин әйтәм. Сәгать унике китте. Бервакыт ишетәм: ишек төбенә генә машина килеп туктады. Нидер бушата башладылар. Локманны әйтәм, чос кеше бит: чыгып карап керде. Калай китергәннәр, ди. Ярый калайны бушаттылар да киттеләр. Шуннан Нух: мин әзрәк черем итеп алыйм инде, иртәгә исәңгерәп йөрү килешмәс дип чыгып китте. Ничектер шулай, утыра торгач, түзмәдем, чыктым, йомышым да бар иде. Чыгу белән баскыч өстеннән күрәм: ике машина утларын әз генә кабызганнар да туры юлдан гына Кырлачка төшеп баралар. Өйгә кердем, әле бер нәрсә уйламыйм. Шунда келт итеп исемә төште: бәй соң, мин әйтәм, нишләп алар икәү булдылар. Пышылдап кына Локманнан сорыйм: ничә машина килгәние, мин әйтәм. Бер генә, ди бу. Алай булгач, мин әйтәм, сез картлар, ачуланмагыз, мин сал яныннан әйләнеп кайтыйм әле. Сәлмән дә: бар әле, Галәветдин, минем дә әллә нәстәсенә эчем поша башлады, ди. Шуннан ни — менә чыктым инде. Күңелем тынычлана алмады. Башта үзем генә китәргә уйлаган идем дә — шикләндем.

— Синең монда киткәнеңне Нух белмәдеме?

— Нух юк ул! Чоланына да кереп карадым, яңа өенә дә — бер җирдә юк.

— Һе, кызык, — диде Гаяз. — Алай булгач, без башта зират янына чыгыйк. Чынлап та синең шикләнүең дөрес булса, алар кире кайтканда шуннан китәргә тиеш: юл бер генә.

Төн айсыз, ләкин аяз иде: бөтен йолдызлар да күренә иде. Аста җил юк, тып-тын, ләкин агач башларында йолдызлы төннең үз җиле уйный — зираттагы каеннар, сөйләшкәндәй, шыбырдашып утыралар иде.

— Әрвахларга тәсбих әйтәләр, — диде Галәветдин. Үзе дә авыз эченнән генә укынып алды.

Гаяз адымын тизләтте. Зират аңа төнлә түгел, көндезләрен дә, үзенең кабер тынлыгы белән мәгънәсез бушлык бирә, мәңге аңлашылмый торган үлемне уйландыра иде.

Зират сырт жирдә иде. Аны узкәч, юл, атлаганда сизелмичә генә, түбән төшә башлады. Бер унбиш минуттан Гаязлар Агыйдел тавына життеләр. Туктап, аска, сал булырга тиешле жиргә, карап тордылар. Ләкин аста бар нәрсә карага күмелгән — кайда яр, кайда су икәнлеге беленми иде. Түбәннән, ыңгыраша-ыңгыраша, авыр баржа таккан буксир менеп килә, бөтен Агыйдел буен аның шаулавы гына басып киткән, нинди дә булса бүтән тавыш ишетелерлек түгел иде.

— Бер килгәч, төшеп тә меник инде, — диде Галәветдин. — Күңел тынычлансын.

Ләкин шунда алар икесе берьюлы машина тавышы ишеттеләр һәм, икесе берьюлы туктап, аска текәлделәр. Башта бер нәрсә дә күренмәде, ләкин озакламый соргылт төн пәрдәсе аша кара силуэт күренде, аның артыннан икенчесе дә беленде. Берсе дә фарасын кабызмаган иде. Тау итәгенә житкәч, беренче тизлеккә күчерделәр, һәм икесе дә ярсып-гүләп менә башладылар. Гаяз тиз генә уйлап алды: машиналар авыр йөк белән менә, тауның яртысында туктатып булмаячак.

Гаязларны тау карасы яшереп тора иде, шуңа күрә машинадагылар, килеп житмичә, аларны күрмәделәр. Күргәндә — соң иде инде: Гаяз шофер ягыннан кабина басмасына сикереп менгән иде. Ул уң кулы белән кузов читенә, сулы белән ишек рамына тотынды. Аны ишек белән бәреп төшерергә итүләре бар иде, шуңа ул кузов ягынарак елышты. Ләкин ул курыккан нәрсә булмады: шофер үзе куркып каткан иде. Ул үс жыйганчы, Гаяз кабина эченә кычкырды:

— Нух, мондамы?

Нух теге як читтә утыра иде. Куркуыннан Гаяз тавышын танымый торды. Хәер, аның хәле тавыш бирерлек тә түгел иде.

— Нух! Монда булсаң, тавыш бир! — диде Гаяз тагын.

Ниһаять, Нух телгә килде, йөрәге купкан тавыш белән шоферга дәште:

— Менгәч тә туктат инде, апай...

...Гаяз, кеше уятыпмы, үзе уяныпмы, күзләрен ачып жибәрү белән, үзләрендә Нух утыруын күргәч, туймаган йокылары качты. Төш түгел иде бу: ишектән кергәч тә, почмакта кершәндәй ак мич тора, ә мич буенда, хәсрәттәй караеп, Нух утыра иде. Өн иде бу.

— Уяттым, ачуланма инде, апай, — диде ул болганчык тавыш белән.

— Икенче килүе инде, — диде Таһир. Ул торган иде инде.

— Менә әле кабер казырга әйтергә чыккан идем... — диде Нух.

Гаяз, кояшлы тышка караган килеш, киенә-киенә:

— Аның өчен ике кабат кермәсәң дә бара идем, — диде.

Башка вакытта сүзне көнбагыш урынына гына ярган Нух — утырган жирендә сеңгән тек сеңгән — нәрсә әйтергә белмичә тагын телсез калды.

— Аның өчен генә түгел иде шул, апай... — диде ул, ниһаять.— Үзең белән генә сөйләшәсе сүзем бар иде.

— Бәлки авыру бәлкабзыйга чыгып торырга кушарбыз?

— Юк. Нигә? — диде Нух. — Может, чыгып керергә биш кенә минут вакыт табарсың, апай, ә?

— Чыгып та торасы юк. Беләм мин нәрсә сөйләреңне.

— Гаяз,— диде ана Таһир.— Алай димә, апай. Чыгып кер. Кеше синә килгән икән, сүзен тыңлап жибәр.

— Нәрсәсен тыңлыйсың инде аның? Башта урлашалар да аннан арттан ияреп йөриләр.

— Эредән сөйләшмә, апай, — диде Нух үпкә белән.

— Ярый, — диде Гаяз. — Бер юлга тыңлыйм.

Алар өй алдына чыктылар. Нух үзе артыннан өй ишеген ныгытып ябып куйды.



— Хараплар итмә инде, апай, башымны...— дип башлады ул.— Әле генә Галәүләрдә булган идем. Ул, тишек авыз, кызына сайраган инде. Халидә уже, таң тишеге белән, Бишбүкәнгә киткән — участковойга инде. Хәзер менә анысы килеп житәр...

— Шулай булгач, сиңа ни кирәк соң?

— Бир ачкычларын, жибәр машиналарны.

— Шуннан.

— Шуннан... алар бүрәнәләрне аударалар да китәләр. Без — знайт та не знаем... Мин анда булмаганмын, өйдә булганмын. Әти үлгән — участковое да ышаначак... Синең Галәү белән генә сөйләшүең кирәк...

— Сорама да, нитмә дә. Берсе белән дә сөйләшмәячәкмен!

— Алай булгач, бир ачкычларын. Берәр жаен үзем табармын әле.

Гаяз аның күз төбенә йодрыгын китерде:

— Менә — ачкычлар! Агач урлаулары житмәгән — еще тегесе сугышырга итә. Ул карсак шоферга менә яңакны күгәрткәне өчен дә эләгә әле.

— Башымны бетермәң, апай! Нәрсә кирәк, әйт, акчамы? Бирәм! Менә. Кызым кирәкме? Өйләнгенә, ризамын. Ул сине ярата да...

Гаяз аның сүзләрен исе-акылы китеп тыңлап торды. Шунда кинәт аның күзен кара кан баскандай булды. Һәм ул, үзен-үзе тыя алмыйча, Нухның якасыннан борып алды.

— Жибәр, апай, нишләвең бу?.. Нишләвең бу? — диде Нух. Ләкин үзе тамчы да карышмый иде.

— Синдә эшләгәннән бирле кемнендер якасыннан менә шушылай тотып, жиргә орасым килеп йөри иде — үзең булгансың икән, — диде Гаяз.

Аның тавышына өйдән Таһир килеп чыкты.

— Суга күрмә, апай, суга күрмә берүк!

— Курыкма, бәлкабзый, — диде Гаяз. — Мин аңа сукмыйм: суксам, үтермәсәм дә, имгәтәм бит мин аны... — Ләкин шундук Нухны жибәрде. — Ычкын моннан!

Һәм Нух, төсе качкан хәлдә, чыгып китте.

## СОҢГЫ БҮЛЕК

Иртән сәгать тугызга Мамлиев конторага Кави бригадасын чакыртып алды. Уфада өч көн булып, кичә бик соң гына кайтып төшкән иде. Бүген аңа таң белән Кави бригадасының ике көн эшкә чыкмавын җиткерделәр. «Көп буе райсоюзга сал чыгарып, ике төн эчеп йөрделәр», диделәр.

Ләкин балта осталарының йөзендә алай «төн буе эчеп йөргән» эз юк иде; алар төн буе эчеп тә йөрмәгәннәр иде, эчкән кадәресе дә инде чыгып, күккә очкан иде. Шулай да алар бер-берсенә:

— Әйдәгез, егетләр, Мамлиев баш төзәтергә чакыра, — дип шаяртышып алдылар.

Мамлиевның Уфадан алып кайткан кызулыгы бетмәгән иде әле, аягүрә басып, каршында тезелешеп утырган балта осталарын тетеп алып китте. Тиргәде, тиргәде дә, үзе дә арып, урынына утырды. Анда да әле тынычлана алмыйча:

— Өч кенә көнгә киттем бит! Уже, минем киткәнне генә көтеп торган кебек, кайсы кайда чумыра да башлаганнар!..

Баядан бирле сүз әйтә алмый утырган Кави, ул туктагач:

— Сезне Уфадан тиргәп кайтарганнар икән, аңа без виноват түгел, — диде. — Болай тиргәр булгач, рөхсәт биреп китмиләр аны. Безгә нәрсә, рөхсәт бар диделәр — эшләдек.

— Мин рөхсәтне сезгә түгел — төрле эштә йөрүчеләргә бирдем. Сезнең самый сезон вакыты, кыл да сыймый торган вакытыгыз. Шуны үз башыгыз белән уйлый алмадыгызмыни? Менә мин сезгә бик әйбәтләп кенә прогул язам да акчагызны да бик әйбәтләп кенә кисеп алып калам.

Барысы да шаулаша башлады:

— Кайсы җиреннән кисәрсең икән соң ул акчаны? Болай да кискәләнеп бетте бит инде.

— Табарлар әле киселми калган җирен.

— Дәүләт сезгә бушка акча түләр дип уйладыгызмы? — диде Мамлиев.

— Акчаны, пожалуйста, кис, — диде аңа Кави. — Тик безне атлаган саен дәүләт белән куркытма: дәүләт ул — папай түгел. Дәүләт ул — менә мин, менә Шакир, Бари, Котдус...

— Син монда теория разводить итмә, — диде аңа Мамлиев. — Теленне дә, кулыңны да тыя алмый башлагансың. Синең өстән әле жалоба да бар...

— Кемнән?

— Кемнән булсын? Әсләмнән. Тик анысы үзенә башка сүз. Әлегә бригадаңда оешкан төстә эш таркаткан өчен мин сиңа выговор бирәм.

— Это ерунда по сравнению с мировой революцией, — диде Кави. — Кешеләргә ике төрле күз белән каравың бер бүген генә түгел инде, Мамлиев агай.

Шунда күршесендә утырган Шакир аның аягына басты. Мамлиевның сипкелле йөзе кызарып-бүртенеп чыкты, сипкелләре дә күренмәс булды.

— Ә син, Акманов, — диде ул, — кешенең физический недостатогыннан көлмә.

— Нинди недостатканнан көләм әле мин?

Шакир тагын аның аягына басты, ләкин Кави аягын гына тартып алды.

— Мин синең күзеңне генә әйтәм, — диде Кави.

Директор янынннан чыккач, Шакир:

— Мин аның аягына басам, ә ул һаман күз сөйли! — диде.

— Ә син нигә басасың минем аякка? Басмаслар!

— Мамлиевның күзе чынлап та ике төрле бит! Берсе — соргылт, берсе — яшькелт. Белми идеңмени?

— Ә мин каян белим? Мина дигәндә өч төрле булсын! Минем аның күзлегеннән башка нәрсәсен күргәнем дә юк, — диде Кави һәм бухгалтерия бүлмәсенә кереп китте. Кергәч тә ишек янында утырган учетчик кыз каршына туктады. — Сеңелем, бир әле бер бит чиста кәгазь. Ручканны да бир.

Ул утырып гариза яза башлады. Ләкин «Мамлиев» дип авырлык белән генә язып куйгач, ручкасын-кәгазен учетчик кызга таба этәрде.

— Язып кына бир инде, апай, шушы гаризаны. Ручка тотарга кулымның бер солы да юк.

— Ручка тотарга да солы булмагач, балтаны ничек тотасың соң, Кави абый?

— И, балтаны без аны өзеп тотабыз, менә ручка гына тота алмыйбыз.

— Нәрсә дип языйм?

— Үзем теләп килдем, үзем теләп кире китәм дип яз. Килгәнемә бик үкенәм, диген... Тукта, үкенәм дигәнен Сәйдәшев абыйга язганда язарбыз...

Таһирга июньнең унбишеннән путевка бирделәр. Чехово санаторие Бәләбәй янында гына иде, ә Бәләбәй үзе Туймазы аша да, Бүздәк аша да машина белән дүрт сәгатьлек юл иде. Шуңа күрә юлга иртә белән унбишендә генә чыгарга булдылар. Сәйдәшев алдан ук машина вәгъдә итеп куйды: көн начар булса — газик, яхшы булса, «Победа» бирермен, диде. Көн яхшы иде, — көннең инде начар булганы да юк иде, — сәгать җидедә капка төбенә «Победа» килеп туктады.

Кифая әби шоферны, төче коймак ашарга кер, дип чакырса да, шофер кермәде, ашыктыра башлады.

— Әл дә соңлап килдем. Кире кайтканда Бүздәккә кагыласы бар. Әзер булсагыз, әйдәгез, чыгып утыра башлагыз.

Гаязлар әзер иде: алар инде сәгать алтыдан ук әзер иде, әле машинаны гына көтеп торалар иде.

Туган-тумача килгән, күршеләр килгән — барысы да җыелган, тик туфлиен алмаштырырга дип кайтып киткән Тамара гына килеп җитмәгән иде. Таһирлар кутәренеп чыгуга ул да капкадан йөгереп килеп керде. Таһирны Чеховога кадәр ул озата бара иде.

Кифая әби, ничектер, үз баласыдай якын күреп, яратып, аның аркасыннан сөеп торды, машина янына җыелган кешеләр ишетмәслек итеп кенә:

— Синең бәхетләреңә генә терелеп кайтса ярар иде инде, кызым...— диде.

Тамара артка — Таһир янына кереп утырды. «Победа», аяк астына газлы төтен бөркеп, ишек алдыннан чыгып китте, минут эчендә олы урамга борылып, күздән югалды. Газа йөрәктәй тигез типкән мотор тавышы гына, күңелләргә өмет салып, колактан китми торды. Аннары ул да югалды. Әйләнә-тирәне моңсу тынлык басып киткәндәй булды, әйтерсең лә, инде уянган, җан кергән иртә дә, бер генә минуткатын калып, Таһирны озата, аның авыл һавасыдай сәламәтләнеп кайтуын тели сыман иде.


Ләкин бу минут үтте. Колакка, берьюлы гөжләп, олуг хезмәт башлаган көн тавышы килеп керде. Әнә заготзерно ягында җиде авылга көнтөн ут биреп торучы электр станциясе гуләп утыра, әнә түбән очта дизель моторы тыкылдый, әнә Агыйдел өстендә буксир пароходы пошкы-

ра... Шулар арасыннан, аерылып, Гаязның колагына икенче тавыш та килеп керде: тук! тук! тук!.. Бер арада ешаеп, бер арада сирәгәеп яки бөтенләй сүнеп-тынып киткәндәй була — болары инде балта тавышы иде. Бу тавышның да, гайрәтле машиналар кебек үк, үз көе, үз моңы бар иде.

— Әйдә, апай, безнекеләр эшкә тотынды...

Гаяз, шушы мәңгелек моннан күңелен алмыйча, әйләнеп карады. Аның янына, балтасын иңбашына салып, Кави килеп баскан иде.

1965



## *Халык мәзәкләре*

### НИК ӨСТЕРӘП ЙӨРЕРГӘ

Элекке заманда бер картның улы читтән кайткан. Чәй эчкән вакытта хәл-әхвалләрне сорашып бетергәннән соң, әтисе:

— Я, улым, акча ягы ничегрәк соң? Бераз алып кайта алдыңмы? — дип сораган.

— Алып кайткан да булыр идем, ләкин файдасы юк бит,— дигән малае.

— Ничек инде файдасы юк?

— Монда бер сум күпмегә йөри?

— Бер сум күпмегә йөрсен, бер сумга йөри инде ул.

— Шулай булгач, андагы бер сумны монда кадәр ник өстерәп йөрергә! — дип җавап биргән ди малае.

### УЙЛАУ

Бер бай ялчысы белән ярминкәгә бара икән. Юлда боларга кунарга туры килә.

— Хезмәтеңне онытма! Атларны онытып бетермә, урлап китмәсеннәр,— ди бай ялчыга

Беркадәр ятканнан соң, бай ялчыга дәшә:

— Йокламыйсыңмы?

— Юк, бай, уйлап ятам.

— Нәрсә турында уйлыйсың?

— Җир ничек су өстендә батмый йөзә ала икән? Алай-болай батып куйса, атларыбыз һәлак булмас микән,— дип уйлыйм.

Ярты төннәр җиткәч, тагы сорый бай:

— Әй, син, йокламыйсыңмы?

— Юк, бай.

— Һаман уйланасыңмы?

— Уйлыйм. Менә җирне күк белән каплап куйганнар бит инде. Берниндн багана-мазары юк. Әгәр шул атлар өстенә төшә калса, харап булмаслар микән мескеннәр?

Бай тынычлап йокыга китә. Атларны караклар урлый.

— Я, хәзер нәрсә турында уйлыйсың? — дип сорый бай, уянып.

— Йөк төягән арба шактый авыр була бит инде ул, атлар булмагач, аны алмаш-тилмәш тартырбыз микән, дип җавап биргән ялчы.

*Гали Хуҗиев*

## Таныш күзләр, таныш карашлар

Бу дастанда күпме язмыш бар;
Язмыштан да ләкин узмыш бар:
Уйламый да «ходай язганны»
Алар утка башлап кергәннәр;
Гашыйклары туар язларның
Гомерләрен шулай биргәннәр.
Юк, исәннәр алар, исәннәр.
Шуны тоям һәрбер сулышта:
Дөнья күргән ике күземдәй,
Гел янәшә алар тормышта.

Дәвамы бар алар эшенең.
Юк, югалмый батыр ир заты;
Илгә биргән хезмәт — иҗаты
Гел яңарта, диләр, кешене.

●

Моабитның каерып ишеген,
Илебезнең Юлиус Фучигы —
Җәлил баса килеп алдыма:
— Кайгырма, дус, бер дә кайгырма,
Күзләреңдә нигә яшьләр бар?
Үлгәч тә бит халык анында —
Ил күңелендә кабат яшәү бар!

●

Тагын ачам «Алар сафта»ны,
Солдат дуслар бар да сактамы?
Алиш килә Җәлил артыннан,
Бергә узып чорлар чатыннан.
Имгәткәннәр каерып сул кулын,
Сизәм, күңеле әрнеп сулкылдый:
— Әйтегез,— ди,— шуны дусларга:
Уң кулым бар корал кысарга,
Уң кулым бар корал кысарга!

Авыр еллар ерак авышты...
Ул көрәштән читтә калмады;
Вөҗдан тавышын безнең Алишның
Моабит та йота алмады,
Моабит та йота алмады!

Күтәрешә анын жырлары
Яна мактап, яна йортларны:
Кабызыша анын жырлары
Туган ягы — Кама утларын.

●

Еллар миннән кискен сорауларын
Баганага терәп сорады,— дип.
Еллар минем күңел сафлыгымны
Утка-суга салып сынады,— дип,
Фатих чыга мина кырыннан.
Йөзе бөйлап кайнар тир ага.
Нинди генә авыр булса да,
Нинди хәтәр жиргә куйса да,
Йөз чытмый ул якты дөньяга;
Чөнки ихлас гашыйк ул ана,
Гомере буе гашыйк ул ана!..

Әйе, шулай булып калды ул,
Ил күңелендә урын алды ул.
Гражданин, шагыйрь, солдат
һәрчакта
Безнең белән
һаман бер сафта!

●

Менә Мөжәй... Нигә янда юк,
Бушамыймы хәрби эшеннән?
Гел ажгырып, үкереп янган ут —
Крематорий уты эченнән
Күтәрелеп баса каршыма;
— Подполковник иптәш, саумы! — дим,—
Жырларыбыз исән барысы да;
Әйтер сүзегез тагын бармы? — дим.
— Бар,— ди шагыйрь.— Истә, якташ,— ди,—
Әле безнең туган якларда
Маневрлар барган чакларда,
Тыңлый-тыңлый шагыйрь Такташны,
«Жыр» дип янып йөргән идек бит,
Ашап юлда бер үк котелоктан,
Бергә дөнья күргән идек бит.
Сөйли шагыйрь: — Гәүдәм янса да,
Сөякләрем көлгә калса да,
Әйтмәгез сез: «Мөжәй янда юк,
Бушамыйдыр хәрби эшеннән».
Гел ажгырып, үкереп янган ут —
Крематорий уты эченнән
Кайттым, дуслар, сезнең арага,
Кайттым, дуслар, туган илемә,
Жырларымда
һәркем күңеленә
Нурларымны өстәп янарга...

●

Атыш тынган сугыш кырында;
Инде калэм солдат кулында.
Бер кайгысы аның юк сыман,
Ул хат яза Казан халкына.
Язын килгэн очар кош сыман,
Күңеле аның ерак талпына...
Хат бүленэ... Атыш кыза тагын.
«Куллар тагын минометка ябыша.
Хат бүленми! Юллар дэвам итэ
Шаулап киткэн мина тавышында».
Бу — Демьян дус безнең, шагыйрь дус.
Минем өчен, жырым, кулын кыс.
Укып белэм бала чаклардан,
Туган Идел улы иде ул.
Ильич туып-үскэн яклардан
Тальян моңын жырлап килде ул,
Авыл моңын жырлап килде ул.
Шаулап киткэн мина тавышында
Һэм тормышның тынмас агышында
Дэвам итэ аның жырлары;
Минометта, гүя, куллары...

●

Салкын көзе кырык икенең;
Сарган жирне туплар төтене.
Ут һэм металл бергэ кушылган,
Каткан туфрак белэн укмашып,
Алгы сызык уза шушыннан,
Йөрэклэргэ безнең тоташып.
Сугыш бара Мэскэү янында,
Атыш кыза бөтен көченэ.
Кем ул оча полкы алдында?
Кем ул оча утның эченэ?
Бу — комсорг, кече политрук,
Партбилеты — йөрэк турында.
Үбэ-үбэ полкы байрагын,
Алды аны сугыш кырында.
Парторг кыскач кулын, ул тагын
Китте кереп утка-төтенгэ.
Егылды да солдат, тормады...
Очраштык тик китап битендэ.
Саумы, Вэдут! Саумы, кара малай!
Африкада йөреп каралгандай,
Йөзең кергэн бронза төсенэ.
Туган ягың — Сарман яклары,
«Жыр» дип бергэ янган чакларны
Төшер эле, дускай, исеңэ.

Буразнада — безнең жыр башы,
Буразнадан — жырга юлыбыз.
Һэм эйттек без: «Корал кысканда
Калтырану белмэс кулыбыз!».

●

Саумы, Хабра! Саумы, җан дустым!
Мин хәтерлим егет чагыңны,—
Китмәдең син безнең арадан.
Холхин-Голда тамган каныңны
Үз тәнемдә булган ярадан
Тамган кебек итеп хис иттем...
Әйтә идең: «Хезмәт иҗаты
Гел яңарта икән кешене».
Юк, югалмас батыр ир заты,—
Дәвамы бу синең эшеңнең.
Мәскәү өчен сугыш барганда,
Үткәрмичә тимер тауларын,
Панфиловлар сугышып ауганда,
Тавышы белән бергә аларның
Йөрәгеңнең тавышын ишеттем.
Йөрәгеңнең тавышын ишеттем;
Син яралы идең яңадан.
Бу юлы да синең каныңны
Үз тәнемдә булган ярадан
Аккан кебек итеп хис иттем.
Һәм эндәштем, сөртеп яшьләрем:
— Җырларыңа күчәр яшәвең!..

●

Күбәү алар — ут-су кичкәннәр;
Ил күңелендә бар да исәннәр;—

Шулай төшә алар исемә,
Шулай яши алар аңымда:
Гүя, һаман гаскәр алдында,
Алга әйдәп солдат ирләрне,
Сөртә-сөртә тозлы тирләрен,
Оча алар утның эченә,
Оча алар утның эченә...

*1966*

—●●—

*Шәриф Хөсәенов*

*Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Габдулла абый Юсуповка.*

# ЗӨБӘЙДӘ—АДӘМ БАЛАСЫ

## Өч пәрдәле трагикомедия

**КАТНАШАЛАР:**

Зөбәйдә
Габдрахман
Җәүһәрия
Фәрит
Булат
Әсхәт
Сөендек
Зөфәр
Сәрия
Мәрвәр Сафина
Кәримә
Сәмигулла
Славик.

### БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сабитовлар өендә зал. Каршыда һәм як-якта берничә ишек. Сулда зур тәрәзә, ул ачык. Зөбәйдә тәрәзә төбенә утырып имтиханга әзерләнә. Тирә-ягында китап-дәфтәрләр. Зал уртасындагы түгәрәк өсталдә Җәүһәрия күлмәк үтүкли. Келәм эленгән уң стена буенда тахта. Анда битен сөлге белән ураган Фәрит утыра. Ачык тәрәзәдән шау килеп уйнаган бала-чага тавышы ишетелә. Тавыш көчәйгән арада Зөбәйдә канәгатьсезләнеп тышка карап ала. Ниһаять, тәрәзәдән туп атылып керә. Зөбәйдәнең кулындагы китабын бәреп төшерә.

Зөбәйдә *(кулларын биленә таянып тәрәзә төбенә менеп баса).* Туктыйсызмы сез, юкмы, шайтан чабаталары?! Өстегезгә бер чиләк су сибәм! Барыгыз, урамга чыгып уйнагыз! *(Ялварып.)* Үзенә этикетка бирермен, Рөстәмкәем, барыгыз инде! *(Тавыш азрак басылган кебек була. Зөбәйдә идәндәге тупны алып берничә мәртәбә сикертеп уйный да элекке урынына утырып укый башлый. Ләкин укый алмый, шап иттереп китабын яба.)* Уф, минем газиз башкайларым өчен түгел бу математика!.. *(Көйләп.)*

А у нас во дворе
Есть девчонка одна...

Җәүһәрия. Җинел булса, һәркем инженер булыр иде. Шуна бит инде әйткәннәр, белем алу энә белән кое казу дигәннәр.

Зөбәйдә.

Я гляжу ей в след —
Ничего в ней нет,
Я гляжу ей в след —
Ни черта в ней нет...

*(Теш арасыннан төкереп.)* Нәрсәгә миңа кое — водопровод бар ич! *(Тышка карап.)* Яле, Магеллан, тубыңны монда җибәр әле. *(Тыштан туп ыргыталар. Зөбәйдә балалар белән туп атышып уйный башлый.)*

Җәүһәрия. Кайтсын әле әтиең. Уйнатыр әле ул сиңа туп.

Телефон шалтырый. Зөбәйдә тубын кочаклап телефонга килә, трубканы ала.

Зөбәйдә *(трубкага)*. Хелло! Ә, бу әле тагын сезмени? Исәнмесез! Тагын номерны ялгыш җыйдыгызмы? Бик ягымлымыни тавышым? Мин үзем дә ягымлы. Әйе... Чакырыгыз мине кинога — танышырбыз. Яхшы. Ә мин сезне ничек танырмын? Яхшы... Минеке — сары. Сап-сары чәчле, озын толымлы бер кыз булырмын мин. Исемем... Бибибикәбисәгыйдәбанусылугөлҗамал...

Җәүһәрия *(җилтерәп килеп трубканы тартып ала да рычагка куя)*. Кит телефон кырыннан! *(Зөбәйдә әйләнә-тулгана өстәл янына килә, Җәүһәриянең күлмәген үтүкләмәкче була. Җәүһәрия үтүкне тартып ала.)* Утыр урыныңа!

Зөбәйдә. Шуны гына үтүкләп бетерим инде, туган апам!

Җәүһәрия. Бетермә, укы сабагыңны! *(Зөбәйдә һич исе китмичә тәрәзә төбенә менеп утыра.)* Күрмәгән-белмәгән кеше белән кинога барырга җыена, җүләр!

Зөбәйдә. Җүләр шул. Җүләр, җүләр, җүләр! Мин бит бәхәсләшмим.

Җәүһәрия. Акыл керә башларга вакыт.

Зөбәйдә. Нәрсәгә миңа акыл! Егетләр ярата — миңа җитә. Ә егетләр җүләр кызларны ярата төшәләр, ди. *(Тышта бала-чага тавышы көчәя.)* Ну, малайлар, төшсәм — кирәгегезне бирәм!.. О, Славик, привет! Ты на Авеню, да?.. Славка да гуляньга китте — рәхәт кешеләрнең... Әй, Фәридә, кая бардың? *(Арттан тавыш: «Пляжга!»)* Ә... Ә мин математика өйрәнәм. *(Китабын кулына алып өлгерми, күрше бүлмәдә нәрсәнеңдер гөрселдәп ауганы ишетелә. Зөбәйдә йөгереп шунда кереп китә. Анда аның тавышы: «Туган апам, Акмыек тычкан тоткан!»)*

Җәүһәрия *(дулкынланып)*. Кит ичмаса! *(Зөбәйдә янына чыга.)* Тимә! Тимә дим, җүләр, уйнасын!

Зөбәйдә. Качыра бит ул аны, туган апам! Качыра бит ул аны!

Җәүһәрия *(Зөбәйдәне тарткалап чыгарып)*. Качырмас, качырмас. Уйнасын рәхәтләнеп. Кермә монда! *(Ишек төбендә тарткалашалар.)* Керфегемне күземә керттең, шашкан! Кит әле! *(Шап иттереп Зөбәйдәнең аркасына суга.)*

Зөбәйдә *(аркасын угалап ала да Фәрит янына килә, битенә урагган сөлгесен тартып ала)*. Унбиш минут булды! Акмыегым тычкан тотты, ишеттеңме? *(Фәрит көзге алдына утырып битен сөртергә керешә. Телефон шалтырый. Зөбәйдә трубканы ала.)* Хелло!.. Ә минем сине — юк. *(Трубканы куя.)*

Җәүһәрия. Кем әле ул?

Зөбәйдә. Зөфәр. Сагындым, күрәсем килә, ди.

Җәүһәрия. Үзеңне яратып йөргән егет белән шулай тупас сөйләшмиләр инде. Әйбәт кенә иттереп әйтергә дә була бит.

Зөбәйдә. Әй! *(Телефон шалтырый. Зөбәйдә трубканы алып тыңлап тора да.)* Ә минем сине күрәсем килми! *(Трубканы ташлый, ләкин шунда ук телефон яңадан шалтырый.)* Ал әнә! Әйбәт кенә иттереп әйт үзеңә.

Җәүһәрия *(телефонда)*. Әйе, квартира. Исәнмесез! Кем әле бу? Ә, исәнмесез, Сөендек!.. *(Зөбәйдә кул селтәп китаплары янына бара башлый.)* Зөбәйдә өйдә юк шул. Ни йомыш иде соң? Кинога барырга булган идегезмени?..

Зөбәйдә *(йөгереп килә дә трубканы тартып ала)*. Хелло! Ха, ха, кайтмадым, өйдә утырам мин. Математика өйрәнәм.

Җәүһәрия. Иртәдән бирле математика өйрәнәм дип дыңгырдый — өйрәнә башлаганы юк әле. *(Чыга.)*



«Зөбәйдә — адәм баласы» ТДАТ сәхнәсендә. Зөбәйдә — Наилә Гәрәева.

Зөбәйдә *(телефонда)*. Ә имтиханны кем бирер иртәгә? Нинди картина? Юк, бармыйм. Харап булгансың икән — билетларыңны миңа бүләк итәрсең, истәлеккә... Машинада йөреп кайтырга? Ярый. *(Трубканы куеп яңа номер җыя.)* Роза, сәгать җидедә киного барабызмы? Жан Маре катнашы белән! Беләсеңме, миңа ике билет чиртеп тора. Ха-ха-ха! Тиздән мин машина белән килеп җитәрмен, беркөнгечә. Ха-ха-ха! *(Трубканы куя. Радиола кабызып пластинка уйнатып җибәрә, бөгелә-сыгыла твист өйрәнә башлый.)*

Җәүһәрия керә.

Җәүһәрия. Күр әле моның килешләрен! Аздырма дим кыяфәтеңне, тукта! Тукта диләр сиңа! Туктыйсыңмы, юкмы яхшылык белән?

Зөбәйдә *(бии-бии)*. Туктамасам?

Җәүһәрия. Туктамасаңмы? Күлмәгеңне күтәреп, менә шушы каеш белән...

Зөбәйдә *(шаяруга юрап күлмәген күтәрә)*. Мә, мә, мә...

Җәүһәрия. Күр әле! *(Урындык аркасына эленгән каешны алып Зөбәйдәгә сыпыра.)*

Зөбәйдә. Ни хакың бар синең миңа сугарга?

Җәүһәрия. Мин синең әниең урынына калган туган апаң.

Зөбәйдә. Әни мине кыйнамый иде! Ни хакың бар синең мине кыйнарга? Менә кияүгә чык та үз балаларыңны кыйна!

Җәүһәрия. Алла сакласын! Синең шикелле балаң булса...

Зөбәйдә. Шуңа күрә аллаһы тәгалә үзеңә кияү бирмәгән дә инде!

Җәүһәрия *(ике арадагы тавышка һичбер игътибар итмәгән Фәриттән ярдәм көтеп)*. Фәрит! Ичмаса, син азрак куркытыр идең шуны. Тәмам чылбырдан ычкынды бит!

Фәрит. Ә син аны чылбырлама. Ул бит эт түгел.

Зөбәйдә. Әйе!

Җәүһәрия. Син кыяфәтеңне әнә көзгедән кара әле!

Зөбәйдә *(карап)*. Ни булган? Матур бит.

Җәүһәрия. Искиткеч! Син пумала башны яратып йөргән егетләренә ни әйтим. Шушы да булдымы инде кыз бала! Татар кызы бит әле, җитмәсә.

Зөбәйдә. Синеңчә татар кызлары бил тиңентен чәч үстереп чаршау артында сагыз чәйнәп кенә утырырга тиешме?

Җәүһәрия *(тынычлана төшеп, сукрануга күчә)*. Сугыштан соң китте мондый яшьләр. Без яшь вакытта, сугышка кадәр...

Зөбәйдә. Син яшь вакытта? Кайчан иде ул — япон сугышы алдыннанмы?

Җәүһәрия. Онытма шушы сүземне: менә күрерсең, син җүләрне бер кызык итәләр әле. Әй туган апам, синең акылың белән йөргән булсам — ак сакаллы карт буласы икәнмен, диярсең әле бер.

Зөбәйдә. Әйтмим! *(Китаплары янына утыра.)*

Җәүһәрия. Әйтерсең!

Фәрит. Калдыр син аны! Ул бит инде кечкенә бала түгел.

Җәүһәрия. Мин дә шуны әйтәм ләбаса! Син инде бала түгел, бер көтү егет белән хихылдап йөрмә, берсе белән генә йөр, дим.

Зөбәйдә. Минем кияүгә чыгарга җыенганым юк ич әле!

Җәүһәрия. Җыенгач кына соң була шул ул.

Зөбәйдә. Ми-на ки-яү ки-рәк-ми! Миңа егетләр кирәк — күңел ачу өчен — аңлашылдымы? Ә кияүгә чыгарга җыенгач, кайберәүләр кебек озын толымнар үстерермен һәм ханжа булырмын. *(Фәритнең йөзен карап.)* Менә бит нинди яшәреп киттең! О! *(Фәритнең башыннан ак чәч йолкып ала.)* Никадәр ак чәч!

Фәрит. Йолкы!

Зөбәйдә. Вакытым юк — математика өйрәнәм. Туган апам йолкысын.

Җәүһәрия. Йолкыр туган апаң — йолдызларга карый торган нәрсәне бирсәләр.

Фәрит. Зөбәйдә!

Зөбәйдә. Бер ак чәч — биш тиен.

Фәрит. Яхшы.

Зөбәйдә аякларын салындырып тәрәзә төбенә менеп утыра да Фәритнең ак чәчләрен йолкый башлый.

Кәримә керә.

Кәримә. Исәнмесез!

Зөбәйдә. О, Кәримә, салют!

Җәүһәрия. Әле авылдан кайттың дамы, Кәримә?

Кәримә. Отпускым бетте ич. *(Түенчек бирә.)* Әби җибәрде. Корт белән сөзмә.

Җәүһәрия. Рәхмәт инде. Исән-саулармы? Бик картаймаганнармы?

Кәримә. Яшәрмәгәннәр. Сәлам әйттеләр. Кунакка чакырдылар.

Зөбәйдә. Мине дә чакырдылармы?

Кәримә. Һәммәгезне дә.

Зөбәйдә *(чәч йолкып)*. Биш!.. Язып җибәр үзләренә, Кәримә. Зөбәйдә кайтмый, диген. Ләкин, берүк, һуштан язып егылмасыннар.

Җәүһәрия. Күр әле бу җүләрне!

Зөбәйдә *(Фәриткә төртеп)*. Менә кемгә кирәк ул авылга кайту. Бар, кайт! Яхшылап татарча өйрәнеп килерсең.

Фәрит. Бер телдә сөйләшергә дә сүз юк әле монда.

Кәримә. Доцент булачак кеше авыл картлары янына кайтып йөрмәс шул инде.

Зөбәйдә *(кисәтеп)*. Кәримә!

Кәримә. Әллә дөрес түгелме? Сез бит шушында бер шәһәрдә яшәп, безгә дә килеп чыкмыйсыз. Кеше туганнары юкка аптырый, ә сез бар туганнарыгыздан качасыз. Зураеп киттегез. Әби белән бабай рәнҗиләр. Без үлгәч, кайтам дисәләр дә кайта алмаслар әле, диләр.

Җәүһәрия. И алла, кайтыр идем, Кәримә, бик кайтыр идем. Әтиләрне дә бик сагындым. Менә бушап булмый. Эшләгән кешенең рәхәт ул — ял аласыз да теләсәгез кая барасыз. Учыгыз тулы акча.

Фәрит. Кайчан син мине, Кәримә, бер матур кыз белән таныштырасың?

Кәримә. Синең шикелле картаеп беткән егетләргә кыз тагын! Әнә Фәйрүзә апа да иргә чыкты. Нинди әйбәт кызны очырдың.

Фәрит. Теге зур колаклы Фәйрүзәме?

Кәримә. Сиңа ярамассың. Әле колагы зур, әле окладды кечкенә... Чынлап әйтәм, Зөбәйдә, кайтып кил каникулында авылга. Әби бик картайган. Бер чиләк су китерсәң дә файда булыр.

Зөбәйдә *(чәч йолкып)*. Уң! Яратмыйм авылны! Кайткан көнне кемнәрне очратсаң, киткәнче шуларны күреп торасың. Шәһәрдә ичмаса күңелле: иртәгә нинди егет белән танышасыңны кичен йокларга ятканда белмисең.

Кәримә. Хәсрәтең шул гына булса, егетләр авылда да күп.

Зөбәйдә. Өченче ел күрдем инде. Бөтен авылга дистә ярым егетләре бар, аның да берсе хатын алган. *(Чәч йолкып.)* Кияү табып кайтмадыңмы соң?

Кәримә. Эзләмәдем.

Зөбәйдә. Картаясың бит инде, Кәримә! *(Чәч йолкып)*. Үнбиш! Телисеңме, бер егет белән таныштырам?

Кәримә. Кеше аркылы таныша-таныша егет эзләргә яшем кырыкка житмәгән әле.

Зөбәйдә *(баш бармагын күрсәтеп)*. Менә! Өч бүлмәле квартирасы, личный «Волга»сы һәм Васильевода салынып бетмәгән дачасы. Дөрес, әлегә болар барысы да әтисенеке. Ләкин әтисе картайган инде, борынгы бабалары янына китәр вакыты житкән.

Кәримә. Шулкадәр яхшы егет булгач, үзең чык.

Зөбәйдә. Миңа бит әле кияүгә чыгарга иртә. Менә университетка керәм, инженер булам. Укыган кызларга картайгач та кияү табыла.

Кәримә. Мин дә техникумга керәм, читтән торып укыйм.

Зөбәйдә. Әй, эшләп укуны әйтмә инде син аны — халтура! *(Чәч йолкып.)* Егерме.. Таныштырыйммы?

Кәримә. Кирәкми.

Зөбәйдә. Турысын гына әйткәндә, минем үземнән дә артмас иде әле ул. Белеме аз.

Кәримә. Яратсаң — белемен тикшереп тормассың әле. Яраткан кеше белән алачыкта да жәннәт, диләр.

Зөбәйдә. Булса булыр инде. Ләкин мин үзем теләп алачык жәннәткә кермәячәкмен. *(Чәч йолкып.)* Егерме ике! *(Фәриткә.)* Башка күренми. Бер сум ун тиенне гони сюда! *(Тәрәзәдән карап.)* Ниндидер бер кыз безнең квартирны сорый.

Фәрит *(карап)*. Сәрия бит бу!

Зөбәйдә *(куркуыннан тәрәзә төбеннән шуып төшә)*. Сәрия?!

Фәрит. Теге, Буа кызы. Исеңдәме, миңа хат язган иде. Хатын син дә укыдың.

Зөбәйдә *(куркудан нишләргә белмичә зал буйлап йөгереп китә)*. Вай-вай-вай-вай!..

Фәрит. Син нәрсә?

Зөбәйдә. Бетте башым!.. Мин бит аның белән син булып хат алыштым. Ой!

Фәрит. Ничек мин булып?

Зөбәйдә. Син жавап язмагач, мин аңа үзем язган идем. Син булып.

Фәрит. Шуннан?

Зөбәйдә. Шуннан ул миңа тагын язды. Дөресрәге, ул сиңа дип яза, ә хатны мин алам. Алам да синең исемнән жавап язам.

Фәрит. Нәрсә дип язасың?

Зөбәйдә. Яратам дип. *(Звонок.)* Ой!

Фәрит. Ну, Зөбәйдә!

Зөбәйдә. Мин бит кызык өчен генә шулай эшләгән идем. *(Звонок.)* Ой!

Фәрит. Үзең ботканы пешергәнсең — теләсәң нишлә. Мин өйдә юк! *(Бүлмәсенә кереп бикләнә.)*

Зөбәйдә. Туган апам!

Җәүһәрия. Менә! Үзеңнең җүләр икәнлегеңне белдеңме инде? Сөйләш үзең! *(Күрше бүлмәгә китә. Звонок кабатлана.)*

Зөбәйдә *(кинәт батыраеп).* Әллә сөйләшмәмме! Кәримә, ишекне генә ач та, туган апам ягына кер! *(Кәримә ишек ачарга чыга. Зөбәйдә Җәүһәриянең купшы халатын һәм күзлек киеп тахтага сузылып ята. Кулына журнал ала.)*

Сәрия *(ишектә).* Мөмкинме?

Зөбәйдә *(Сәрияне башыннан аягына кадәр карап чыга да).* Мөмкин.

Сәрия *(кыюсыз гына, оялып).* Фәрит Сабитов шушында торамы?

Зөбәйдә *(кыюлана төшеп).* Тора.

Сәрия. Өйдәме ул?

Зөбәйдә. Фәрит Сабитов өйдә юк.

Сәрия *(беравык нәрсә әйтергә белми торганнан соң).* Сез аның кеме буласыз?

Зөбәйдә. Мин аның сеңелесе.

Сәрия. Таныш булыйк: мин — Сәрия. Районнан килдем.

Зөбәйдә. Анысын әйтмәсәгез дә күреп торам.

Сәрия. Нәрсәне күреп торасыз?

Зөбәйдә. Районнан икәнлегегезне.

Уңайсыз пауза.

Сәрия. Фәрит тиз кайтырмы икән?

Зөбәйдә. Ул тиз кайтмаячак. Йомышыгызны миңа әйтергә мөмкин, акыллым. Мин Фәритнең әнисе урынына калган сеңелесе.

Сәрия. Әнисе урынына калган?

Зөбәйдә. Әйе.

Сәрия *(гаҗәпләнеп).* Сезгә ничә яшь соң?!

Зөбәйдә. О, мин шактый олы инде. Сез минем битемә карамагыз — шәһәр кызлары тиз картаймыйлар.

Сәрия. Гаҗәп!

Зөбәйдә. Гаҗәп түгел, акыллым. Әни үлгәндә абый бик яшь иде әле... Һәм миңа аңа әни булып калырга туры килде. Ир кеше хатын-кыз тәрбиясеннән башка яши алмый бит... Мин сезне тыңлыйм, акыллым. Ләкин баштан ук кисәтеп куям: мин бик гаҗәпләнәм.

Сәрия. Нәрсәгә?

Зөбәйдә. Әрсезләнүегезгә. Кызларның авторитетын төшереп егетләр куып йөрисез. *(Сәрия нидер әйтмәкче була, ләкин Зөбәйдә кул күтәреп аны бүлә.)* Сабыр итегез! Мин сезнең абыйга язган хатларыгызны укып барам — кичерерсез, шаять. Үлеп яратам мәхәббәт хатларын укырга. Ялгышмасам, сез икмәк пешерүче булып эшлисез?

Сәрия. Әйе.

Зөбәйдә. Сезнең шул хакта уйлаганыгыз юкмыни, акыллым: әгәр минем абый — доцент булачак кеше — икмәк пешерүче кызга өйләнергә уйласа, аларны Буадан төяп китерүнең ни хаҗәте булыр икән? Икмәк пешерүче кызлар Казанда да күп бит. Өстәвенә, Казан икмәге Буаныкыннан тәмлерәк.

Сәрия. Күрәсең, абыегызга мин пешергән икмәк ошый төшкән.

Зөбәйдә. Уйламыйм.

Сәрия. Уйламасагыз бигрәк тә яхшы. Фәритнең үз башы бар.

Зөбәйдә. Бер баш яхшы, ике баш — тагын да яхшырак.

Сәрия. И, сеңелем, син бит әле...

Зөбәйдә. Беренчедән, акыллым, «син» түгел, «сез». Авылда яшәсәгез дә азрак культурага өйрәнергә вакыттыр лабаса. Икенчедән, мин сезнең сеңелегез булырга җыенмыйм.
Сәрия. Каенсеңелем булырсыз.
Зөбәйдә. О!
Сәрия. Фәрит кайчан кайта? Миңа ул кирәк.
Зөбәйдә. Ә сез аңа кирәкмисез.
Сәрия. Күрәсең, әнисе урынына калган сеңел белми. Сезнең абыегыз мине ярата. Без аның белән хат алышабыз.
Зөбәйдә. Аһ хат! Оныта язганмын. Сезнең белән абый булып хат язышучы мин ул. Һәртөрле авантюралар эшләргә үлеп яратам! Гафу итәрсез дип уйлыйм.
Сәрия. Андый хатлар язу өчен башыгыз яшьрәк әле сезнең.
Зөбәйдә *(пафос белән)*. «О сөеклем Сәрия! Айлы төннәрдә тын бакчага кереп, йолдызларга карап сине уйлыйм...»
Сәрия *(сагая төшеп)*. Күрәсең, чыннан да сез безнең хатларны укып барасыз.
Зөбәйдә. Ә сезнеңчә ничек, акыллым? Мин — абыйның әнисе урынына калган сеңелесе — аның кемнәр белән хат алышуын тикшерергә тиешме, юкмы?
Сәрия. Фәрит бала түгел, аңа утыз яшь.
Зөбәйдә. Егет кешегә утыз күп түгел. Яшьли өйләнергә минем рөхсәтем юк!
Сәрия. Абау җаным, бу Казан кызларының һәммәсе дә шулаймы?
Зөбәйдә. Шулайрак.
Сәрия. Сезнең белән сөйләшеп файда булмас. Иртәгә килермен. *(Чыга.)*

Фәрит керә.

Фәрит. Ну сине, Зөбәйдә!
Зөбәйдә. Ярар, ярар. Ап-аек көенчә доцент булачак кешегә кияүгә чыгам дип йөрмәсен. Күр әле җуләрне — тәмам ышанган!

Телефон шалтырый. Җәүһәрия керә.

Җәүһәрия *(телефонда)*. Әйе. Мин бу, абый... Нинди егет?.. Ярый. *(Трубканы куя.)* Әтиең шалтырата. Бер егет алып кайтам, берничә көн бездә торачак, ди. Синең бүлмәне әзерләргә куша.
Зөбәйдә. Нинди егет?
Җәүһәрия. Белмим.
Зөбәйдә *(телефонда номер җыя)*. Ало, начальник! Син кемне алып кайтасың? Нишләп ул минем бүлмәдә торачак? Кем ул? *(Ачуланып трубканы куя.)*
Җәүһәрия. Нәрсә ди?
Зөбәйдә. Әйтмәде. Килгәч күрерсез, ди.
Җәүһәрия. Әзерләргә туры килә инде бүлмәнне.
Зөбәйдә. Һы, билгеле, әзерлисен. Начальник сүзе — приказ.

Кәримә керә.

Кая мыштым гына чыгып барасың. Гони бер сум ун тиенне! *(Фәрит Зөбәйдәгә акча биреп чыгып китә.)*
Җәүһәрия. Килде-китте генә кеше түгелдер инде ул, кирәкле кешедер. Пәрәмәч пешерергә кирәк.
Зөбәйдә *(сикеренеп)*. Мин дә пәрәмәч ясыйм!
Җәүһәрия. Ясамый гына тор әле. Укы әнә сабагыңны. Кәримә, ун күзем, син пәрәмәчне бик оста ясыйсың, булыш әле миңа! *(Чыга.)*
Зөбәйдә. Кәримә, ишеттеңме, начальник бер егет алып кайта. Кем булыр икән?

Кәримә. Мин кайдан белим!
Зөбәйдә. Соң, син бит шунда эшлисең!
Кәримә. Исеме ничек?
Зөбәйдә. Белмим.
Кәримә. Ярар, килгәч күрербез. Таныган кеше булса — әйтермен. *(Җәүһәрия янына чыга. Зөбәйдә китаплары янына барып утыра. Әсхәт керә.)*
Әсхәт. Исәнме, Зөбәйдә! Әзерләнәсеңме?
Зөбәйдә. Әһе. Кулыңда нәрсә ул, Әхсәт, картинкалармы?
Әсхәт *(бирел)*. Үнөч.
Зөбәйдә *(картинкаларны карый-карый)*. Рәхмәт, Әсхәт... Әсхәтчек, нигә шундый киң балаклы чалбар киясең? Үзең чибәр генә егет булып киләсең, ә үзеңнең чалбар балагың Тарас Бульбаныкы кебек.
Әсхәт *(сүзне икенчегә борып)*. Нәрсә өйрәнәсең?
Зөбәйдә. Шул инде, математика.
Әсхәт. Иртәгә стадионда футбол. Ишектә әни торачак.
Зөбәйдә. Әниең стадионда контролер булгач — эшләр рәхәт синең.
Әсхәт. Ә мин тагын бер кеше алып керә алам!.. Кемне дә булса алып керәм әле иртәгә... Беләсеңме нинди матч булачак! Мәскәү «Динамо»сы белән! Билетлар әллә кайчан сатылып беткән.
Зөбәйдә. Ой, Әсхәт, Мәскәү түгел, Бразилиядән Пеле килсә дә барыр хәлем юк. *(Пауза.)*
Әсхәт *(тәрәзәдән карап)*. Ә мин Бүрекле белән Күреклегә яңа оя ясадым. Күрдеңме?
Зөбәйдә. Әһе.
Әсхәт. Матур булган бит?
Зөбәйдә. Әй, күгәрченнәргә матур ни дә, ямьсез ни! Аларның аннары юк ич.
Әсхәт. Булмас сиңа! Ишек алдына чыксам — хәзер танып алалар. Гөл-гөл, гөл-гөл килә башлыйлар... Күрше ишек алдындагы Василий Степановичны беләсеңме? Беләсеңме? Миңа шул Бүрекле белән Күреклегә ун сум бирә!
Зөбәйдә. Нигә сатмыйсың, җүләр?
Әсхәт. Сата ди — көтеп торсын. Беләсең килсә, мин аларны йөз сумга да сатмыйм әле. Бер капчык алтын бирсәләр дә сатмыйм... Алар минем бөтен сүземне аңлыйлар. Сөйләшергә телләре генә юк... *(Пауза.)* Ә мин училищега керергә булдым.
Зөбәйдә. Училищега?
Әсхәт. Электротехник булам. Анда форма бирәләр — шинель, фуражка, ремень... *(Зөбәйдәнең елмаюын күреп.)* Сиңа ошамыймыни?
Зөбәйдә. Ошый, Әсхәт, ошый. Ләкин безнең университет — училище түгел, имтихан белән алалар. Өйрәнәсе бар.
Әсхәт. Мин чыгам. Син өйрән. Өйрән син, Зөбәйдә.

Әсхәт чыга. Зөбәйдә укуын дәвам итә. Сәмигулла керә. Кулында зур кәрзин.

Сәмигулла. Өйдәме хуҗалар? Ниһал, кызым!
Зөбәйдә. Сезгә кем кирәк, бабай?
Сәмигулла. Миңа Җәүһәрия апаң кирәк иде. Син аның кеме буласың?
Зөбәйдә. Мин аның абыйсының кызы. Исемем Зөбәйдә. Ә сез кем, бабай?
Сәмигулла. Бер бик чая сеңелем бар дип сөйләгән иде, син буласыңдыр инде алайса. Мин Сәмигулла Искин булам. Матур апаң өйдәме?
Зөбәйдә *(хәзер бер кызык буласын сизенгәндәй күзләрен уйнатып)*. Туган апам! Искин килгән!

*Җәүһәрия керә. Сәмигулланы күреп каушап кала. Кулларын алъяпкычына сөртеп, ике куллап күрешә. Зөбәйдә тәрәзә төбендә укып утырган килеш, каш астыннан гына аларны күзәтә.*

Җәүһәрия. Исәнме, Сәмигулла абый! Әйдә, түрдән уз.

Сәмигулла. Ярый. *(Кәрзинен ишек төбенә куеп уза, утыра.)* Ниһәл, сау гына торасыңмы?

Җәүһәрия. Аллага шөкер, Сәмигулла абый.

Сәмигулла. Ничек соң, хәзерлисе-итәсе нәрсәләреңне карап бетерәсеңме инде? Мәрхүмә карчыгымның кырыгы җитә бит. Кырыгы тула!

Җәүһәрия *(Зөбәйдә ягына ымлап, акрын гына)*. Туй күлмәге тегелде инде, Сәмигулла абый! *(Әле генә үтүкләп бетергән күлмәген алдына куеп күрсәтә. Зөбәйдә астан гына карап елмаеп утыра.)*



Сәмигулла — РСФСРның атказанган, ТАССРның халык артисты Х. Уразиков. Җәүһәрия — ТАССРның атказанган артисткасы В. Минкина.

Сәмигулла. Кара, кыска җиңле итеп теккәнсең ләбаса! Изүләре дә бик ачык төсле.

Җәүһәрия. Туй күлмәге озын җиңле булмый инде ул, Сәмигулла абый. Аның модасы шул.

Сәмигулла. Соң, әкәмәт, мода дип бит инде... Кыскарак та кебек күренә. Мин бит сиңа дүрт метр ефәк алдым. Әрәм иткәнсең ефәкне...

Җәүһәрия. Хәзер күлмәкне озын кимиләр инде, Сәмигулла абый. Модасы шундый.

Сәмигулла. Соң бит инде...

Җәүһәрия *(Зөбәйдәгә ымлап)*. Хәзер эшемнең тыгыз чагы, Сәмигулла абый. Рәнҗемәсәң, кичкә таба үзем сугылыр идем.

Сәмигулла. Ярый. Әле үземнең дә базардан карлыган сатып кайтышым гына, өйгә ашыгам. Сәгать ничәләрдә килерсең?

Җәүһәрия. Сигезләр тирәсендә.

Сәмигулла. Иртәрәк килсәң, карлыган җыешыр идең. Коела башлады югыйсә.

Җәүһәрия. Анысына иртәгә, Сәмигулла абый. Иртәгә, алла теләсә.

Сәмигулла. Әнә теге матур кызны да ияртеп кил. *(Зөбәйдәгә.)* Матур апаң белән карлыган җыешырга килерсеңме, кызым?

Зөбәйдә. Имтиханымны бирсәм — килермен, бабай.

Сәмигулла. Бирерсең, ходай боерган булса, бирерсең. Кил! Җизнәң булачак кешегә бер файдан тияр. Сытылганнарын үзең дә ашарсың.

Зөбәйдә. Ә сытылмаса?

Сәмигулла. Сытыла! *(Әрнеп. Җәүһәриягә.)* Сытыла шул, җыеп өлгереп булмый. Әле егерме биш төпкә кул да тимәгән — мимылдап торалар. Ярый, киттем мин. *(Кәрзинен алып чыга. Җәүһәрия аны озатып керә.)*

Зөбәйдә. Шушымыни инде синең Сәмигуллаң?

Җәүһәрия. Шушы инде!

Зөбәйдә. Плюшкин несчастный! Имтиханымны бирсәм — барып, юри бөтен карлыганын сытып кайтам әле.

Җәүһәрия чыга. Пауза. Зөфәр керә.

Зөфәр. Мөмкинме? Исәнмесез!

Зөбәйдә. Исән әле. Мин бит сиңа килмәскә куштым. Ник килдең?

Зөфәр. Сагындым, күрәсем килде.

Зөбәйдә. Ә минем сине — юк.

Зөфәр. Имтихан алдыннан азрак башны ял иттерергә кирәк. Әйдә Кабан күленә чыгабыз.

Зөбәйдә. Ни калган анда!

Зөфәр. Азрак көймәдә йөрербез.

Зөбәйдә. Батып үләсем килеп тормый әле.

Зөфәр. Син йөзә белмисеңме?

Зөбәйдә. Безнең ишек алдында бер генә кыз йөзә белә иде, анысы да батып үлде.

Зөфәр. Үзем коткарырмын.

Зөбәйдә. Ха!

Пауза.

Зөфәр. Бүген көне матур. Җил дә басылган...

Зөбәйдә. Басылса ни!

Зөфәр. Көймәдә йөрергә әйбәт.

Зөбәйдә. Булса ни!

Зөфәр. Кабан күленә ике аккош җибәргәннәр.

Зөбәйдә. Җибәрсәләр ни!

Зөфәр. Зөбәйдә!

Зөбәйдә. Мин инде унҗиде ел Зөбәйдә. Зинһар өчен, тирән сулама! Тирән сулап йөрү буенча стажың шактый инде. Пенсиягә китсәң дә ярар.

Зөфәр. Син ярату ның нәрсә икәнен белмисең шул.

Зөбәйдә. Аллага шөкер! Җүләр булсам да, кемне дә булса яратып, айга карап, тирән сулап утырырлык дәрәҗәдә түгел.

Зөфәр. Сине шайтан да аңламас!

Зөбәйдә. Ә син аңларга тырыш. Син бит акылы кеше — биш елдан врач булачаксың. Учыңны тутырып аена туксан сум акча алачаксың.

Зөфәр. Эш акчада гына түгел бит, Зөбәйдә. Бер-береңне яратып яшәсәң — алачыкта да җәннәт. *(Зөбәйдәнең кулына сузыла.)* Зөбәйдә...

Зөбәйдә *(кулын тартып ала)*. Кагылма миңа! Мин сине яратмыйм. Яратмыйм! Яратмаячакмын да! Беләсеңме, мин нинди кешене генә яратачакмын? Кимендә ике бүлмәле квартирасы, «Москвич» кына

булса да машинасы һәм аз дигәндә ике йөз сум хезмәт хакы булган кешене. Шуларга өстәп дипломы, дәрәҗәсе һәм перспективасы. Бармы синең шулар?

З ө ф ә р. Циник, циник! Мещанка! Син — совет мәктәбен бетергән кыз, комсомолка...

З ө б ә й д ә. Комсомолка булгач та тишек түбәле өйдә торып, алама киенеп йөрергә, тәмле ашау турында хыялланмаска дип уставка язылмаган. Син миңа Кытай теорияләрен өйрәтмә.

З ө ф ә р. Коммунизм, коммунизм дибез, ә үзебез...

З ө б ә й д ә. Коммунизм, коммунизм! Нәрсә соң ул коммунизм? Коммунизм ул һәр кешенең рухи һәм материаль ихтыяҗларын максималь тәэмин итү. Ә минем ихтыяҗларым әнә шундый. Әгәр инде минем ирем бар икән — миңе машинага утыртсын да очыртып кына алып керсен коммунизмга. Аңлашылдымы?

З ө ф ә р. Эшли башлагач, боларның барысы да булачак бит, Зөбәйдә. Мин врач, син инженер булсаң, икебез дә эшләсәк...

З ө б ә й д ә. Ә минем коммунизм булгач эшлисем килмәсә? Балалар үстереп өйдә генә утырасым килсә?

З ө ф ә р. Ничек инде өйдә генә, эшләмичә?

З ө б ә й д ә. Шулай. Без хатын-кызлар социализмда җитәрлек эшләдек инде. Коммунизм килгәч, азрак ял итсәк тә хәрам булмас.

З ө ф ә р *(уйлап)*. Син миңа срок бир. Ну, җиде-сигез ел срок бир. Мин ышанам, минем квартирам да, машинам да, башкалары да булачак.

З ө б ә й д ә. Ә мин җиде-сигез ел буе нишлим? Синең лотереяга машина откаңны көтеп мич башында утырыйммы? Юк инде, минем бүген машинада йөрисем килә. Менә хәзер! Шуңа күрә Кәримәне көймәдә йөрергә чакыр. Кәримә! *(Кәримә керә.)* Таныш булыгыз: бу — әтинең сеңелесенең кызы. Ә бу — Зөфәр, биш елдан врач булачак. Кәримә, сине Зөфәр көймәдә йөрергә чакыра.

К ә р и м ә. Ничек инде?!

З ө ф ә р. Гафу итегез, Кәримә. Шаяра ул. Сау булыгыз! *(Чыга.)*

З ө б ә й д ә. Нигә син мине уңайсыз хәлдә калдырасың?

К ә р и м ә. Күр әле, син үзең мине уңайсыз хәлдә калдырасың.

З ө б ә й д ә. Характерыңны үзгәртмәсәң син гомердә кияү тапмассың, Кәримә.

К ә р и м ә. Үземә насыйбы табылыр әле.

З ө б ә й д ә. Табылыр — авызыңны ачып торсаң. Әнә туган апам — насыйбы дип утырган да кырык сигезне тутырган.

К ә р и м ә. Күп сайламасын иде. Турысын гына әйткәндә, танышырга теләгән егетләрдән дә качам әле мин.

З ө б ә й д ә. Кач, кач. Шуннан килеп җитәр бер вакыт — егетләр сине күргәч үзләре кача башларлар.

Сөендек керә.

С ө е н д е к. Рөхсәттер бит? Сәлам кызларга!

Җәүһәрия керә. Кәримә чыга.

Җ ә ү һ ә р и я. Исәнмесез, Сөендек! *(Сөендек Зөбәйдәгә шоколад бирә.)* Үзегез тагын бер дә буш кул белән йөрмисез.

С ө е н д е к. Сезгә дә бүләгем бар, Җәүһәрия туташ. Менә бусы сезгә. Бусы — Зөбәйдәгә. Машина отыгыз! *(Икесенә дә лотерея билетлары бирә.)*

Җ ә ү һ ә р и я. Нишләрмен икән соң ул машина белән?

С ө е н д е к. Утырып йөрерсез.

Җ ә ү һ ә р и я. Йөртә белмәсәм дәме?

Сөендек. Сатарсыз. Биш йөз сум өстәү белән кулга да тидермәячәкләр. Үзем хужа табып бирермен.

Җәүһәрия. Миңа калса, берәр шофер отсаң әйбәтрәк кебек.

Сөендек. Ягъни?

Җәүһәрия. Машина отсам — йөртә белмәгәч, барыбер эшсез торачак. Ә менә шофер отсам — мин аңа шул көнне үк эш табам. Ха-ха-ха!

Зөбәйдә. Туган апам!

Җәүһәрия. Сезне күргәч, Сафа исемә төшә. Бер егетем бар иде минем сугышка хәтле. Сезнең кебек инженер үк булмаса да, шулай укыган нәрсә иде. Яратып та карады соң инде үземне мескенкәй. Ике ел буенча бер олау прәннек ашаткандыр...

Зөбәйдә. Туган апам, кунак килеп җитәр. Пәрәмәчләреңне кара!

Җәүһәрия чыга.

Сөендек *(Зөбәйдә янына утырып)*. Нишләп утырасың?

Зөбәйдә. Математика өйрәнәм. Кайда билетларың?

Сөендек. Саттым мин аларны.

Зөбәйдә *(шоколадын шап иттереп куя да)*. Бер сум акчам әрәм китә дип курыктың инде, ә?

Сөендек. Син бит кинога бармыйм, диден. Азрак машинада йөреп килербез, дигәч, риза булдың. Әйдә, машина капка төбендә.

Зөбәйдә. Бәлки ул билетларны мин истәлеккә калдырырга телимдер. Тизрәк илтеп саткан!

Сөендек. Инде ничә билетны әрәм калдырдың. Әллә син алардан коллекция җыясыңмы? Да, коллекция дигәннән, мин сиңа маркалар китердем. *(Кесәсеннән маркалар чыгара.)*

Зөбәйдә. Мин марка җыймыйм. Мин конверт картиналары гына җыям. *(Шоколад ашый-ашый.)* Бар инде, кинога билетлар алып кил инде!

Сөендек. Димәк, барабыз?

Зөбәйдә. Бармыйбыз! Мине машинаңа утыртасың да иптәш кызыма илтәсең. Без аның белән математика өйрәнәбез.

Сөендек. Математика өйрәнү өчен кино билеты кирәкме?

Зөбәйдә. Нинди тәмле шоколад! Ач әле авызыңны! *(Сөендекнең авызына бер кисәк шоколад сала.)* Тәмлеме? Бар инде, кинога билет алып кил инде!

Сөендек. Ну кәҗәләнеп тә карыйсың син, Зөбәйдә!

Зөбәйдә *(шоколадны ашап бетереп, кәгазен тышка ыргыта)*. Алайса шоколадың да кирәкми, машинада йөрергә дә чыкмыйм. Бар, кит!

Сөендек. Ярый-ярый, синеңчә булыр. *(Ишек төбенә җиткәч.)* Мин өйгә кереп тормам, гудок кына бирермен. Ишеткәч чыгарсың. *(Чыга. Зөбәйдә тәрәзәдән кул болгап кала.)*

Зөбәйдә *(телефонда номер җыя)*. Роза, син мине көтәсеңме? Беләсеңме, монда эшләр саташып тора бит әле. Беренчедән, теге хайван билетларын сатып килгән. Икенчедән, безгә кунак килә, пәрәмәч пешерәсе бар. Кабатлап бетердеңме әле? Ой, мин бернәрсә белмим, бөтен ышанычым кылый күздә. Ярый, сау бул! *(Трубканы куя. Җәүһәрия керә.)* Туган апам, нинди егет алып килә икән ул?

Җәүһәрия. Әле кем белән сөйләштең?

Зөбәйдә. Бер бик чибәр егет белән, ресторанга барырга булдык.

Җәүһәрия. Шул гына җитмәгән иде, унҗиде яшьтән рестораннарга сөйрәлеп йөрисең генә калган!

Зөбәйдә. Әгәр бер егетнең минем кырыма утырып ризык кабул итәсе килә икән — аның ни гаебе бар?!

Җ ә ү һ ә р и я. Иттерермен әле мин сиңа! Сөендек киттемени?

З ө б ә й д ә *(китаплары янына утырып)*. Китсә инде!

Җ ә ү һ ә р и я. Шулай итеп очырырсың әле минә егетне. Икенче андыйны шәм тотып эзләсәң дә таба алмассың.

З ө б ә й д ә. Табам!

Җ ә ү һ ә р и я. Табарсың, пычагым! Кай җирә килмәгән Сөендекнең! Үзе инженер, үзе бай, үзе шундый культурный. Яшькә дә карт түгел.

З ө б ә й д ә. Иллегә җиткән кызлар өчен түгел, билгеле.

Җ ә ү һ ә р и я. Син минем белән авыз чайкама! Яшем кырык сигездә булса да, кайбер яшь кызларга торам әле мин. Әнә Сәмигулла абыең — хатынының кырыгы тулганны көтеп җиткерә алмый.

Г а б д р а х м а н белән Б у л а т керә.

Б у л а т. Исәнмесез!

З ө б ә й д ә *(кинәт җанланып алгарак чыга)*. Исәнмесез!

Г а б д р а х м а н. Әйдә, чишен. Плащыңны чөйгә эл. Уз. Таныш бул: менә бу минем сеңел. Бусы — кызым.

З ө б ә й д ә *(кул биреп)*. Зөбәйдә.

Б у л а т. Булат.

З ө б ә й д ә. Очень приятно!

Г а б д р а х м а н. Ашарга бирәр нәрсә бармы, Җәүһәрия?

Җ ә ү һ ә р и я. Пәрәмәч пешерәбез.

Г а б д р а х м а н. Син безгә минем бүлмәгә генә керт. Әйдә, Булат.

Г а б д р а х м а н белән Б у л а т чыгалар.

З ө б ә й д ә. Симпатяга! Нинди кош икән бу?

Җ ә ү һ ә р и я. Я берәр яңа инженер килгәндер. Гостиницада урын юктыр.

Җ ә ү һ ә р и я кухнядан пәрәмәчләр алып керә. З ө б ә й д ә аның кулыннан тәлинкәне алып, әтисе бүлмәсенә үзе кереп китә. Әйләнеп чыга.

З ө б ә й д ә. Симпатяга! Хатыны бармы икән?

Җ ә ү һ ә р и я. Бик яшь күренә ич.

З ө б ә й д ә. Бар әле, берәр сәбәп табып шунда йөр. *(Көзге алдына килеп чәчләрен рәтли башлый.)*

Җ ә ү һ ә р и я *(ишек төбенә килеп)*. Кирәксә тагын китерәм. Яна пешкәлләре була.

Г а б д р а х м а н *(арттан)*. Китер, китер!

З ө б ә й д ә. Пешкәлләре, пешкәлләре! Ничә ел Казанда яшәп сөйләшә дә белмисең.

Кәримә пәрәмәчләр күтәреп чыга. Җәүһәрия аларны алып Габдрахман бүлмәсенә кереп китә.

З ө б ә й д ә *(Кәриманә ымлап үз янына чакыра)*. Тәзелешкә яңа инженер килгән. Гостиницада урын булмаган. Симпатичный! Телисеңме, яңа инженерыгызны үземә гашыйк итәм? Ике көндә! *(Чәчләрен төзәтә-төзәтә.)* Синең чәчең матур, Кәримә. Толымнарың гына ямьсез — авыл кызына охшыйсың. Әйдә кисәбез!

К ә р и м ә. Кис үзеңнекен.

З ө б ә й д ә. Минекен кисәсе калмаган ич инде! *(Чәчләрен күперткәләп.)* Ошыйммы сиңа минем прическа?

К ә р и м ә. Ярый инде. Алып мактарлык түгел, салып таптарлык түгел.

З ө б ә й д ә. Ә беләсеңме ничек дип атала бу прическа? «Пөгереп кил дә суырып үп», дип атала. Әйдә, карыйк әле тегене. *(Кәримәне иңртеп әтисе бүлмәсе янына килә, ярыктан карый. Аннары ярыкка Кәримәнең борынын төртә.)* Матур бит?

Кәримә (*кинәт читкә йөгерә. Дулкынланып*). Булат ич ул!
Зөбәйдә. Син аны беләсеңмени?
Кәримә. Камалов Булат ич ул. Бездә шофер булып эшли.
Зөбәйдә (*күңеле төшеп*). Точно?
Кәримә. Үзебезнең эшчеләрне беләм ич инде мин. Бездә шофер булып эшли. Самосвалда.

Фәрит керә.

Зөбәйдә. Теге егет килде. Шофер гына.
Фәрит. Ну и что же!
Зөбәйдә. Нигә борыныңны салындырып кайттың? Әллә капка төбеннән үк борып җибәрдеме?
Фәрит. Ашарга бармы? (*Кухняга чыга.*)

Җәүһәрия керә.

Җәүһәрия. Егетне кичә генә комсомолдан чыгарганнар.
Кәримә. Комсомолдан?
Зөбәйдә. О, оригинально!

Габдрахман белән Булатның керүен күреп, Җәүһәрия белән Кәримә тиз-тиз кухняга чыгалар. Зөбәйдә өстәл астына кача. Габдрахман белән Булат керә.

Булат. Калсам, сезнең хакка гына калдым инде, Габдрахман абый.
Габдрахман. Кабатлап әйтәм, тормышыңның ул ягында минем эшем юк. В конце-концов, сиңа инде егерме өч яшь. Мин бит үзем дә ир кеше. Минем дә булды яшь чагым...
Булат. Менә бит, сез дә ышанмыйсыз.
Габдрахман. Ярый, ярый, ышанам. Әмма эштән китәм дигән уеңны бүген үк башыңнан чыгарып ташла. Бер кая да китмисең. Мин сине үзем — тәзелеш идарәсе начальнигы — җибәрмим. Ә комсомоллар- ның сүзенә карама син. Әлегә бездә торырсың — безнең өй иркен. Аннары комендант белән сөйләшеп, ничек тә булса үзеңне общежитие- гә төртермен.
Булат. Әмма хәйләкәр дә хатын икән, Габдрахман абый! Квартир тапкач, мин аннан үзем дә китә идем инде. Югыйсә, килә дә, шаярган булып минем янга ята. Килә дә, шаярган булып минем янга ята.
Габдрахман (*кызыксынып*). Шаярган буламыни?
Булат. Әйе! Аякларым туңды, җылыт әле дигән була. Аптырап беттем. Стенага таба борылам да ятам.
Габдрахман (*көлеп*). Стенага таба борылып ятам диген, ә?
Булат. Ә нигә? Үзегез ниһшләр идегез минем урында?
Габдрахман (*хәйләкәр елмаеп бармак яный*). Син эшләгәнне үк эшләр идем, наян!
Булат. Димәк, һаман ышанмыйсыз!
Габдрахман. Ярый, ярый. Минем алда акланып маташма. Кайвакыт үземдә дә була. Ун ел инде минем хатын үлгәнгә.
Булат. Ә нишләп өйләнмәдегез, Габдрахман абый? Үлгән хатыныгызга хөрмәт йөзеннәнме?
Габдрахман. Анысы да юк түгел, әлбәттә. Аннары, үзең уйлап кара: минем яшьтәге кешене яратып килүче буламы? Миңа килсә, — шул, тәрбиячесе булмаган яисә балаларыннан уңмаган тол хатын килә. Тамагын туйдыру өчен. Ул бит инде «Тукта, бу картны тәрбияләим әле», дип килми, үз нужасын нужаларга килә. Аны ашатып ятканчы, мин лучше елына бер курортка барып кайтам.

Җәүһәрия керә.

Ну, мин кушканны эшләдегезме? Күрсәт егеткә бүлмәне! (*Җәүһәрия Булатны ияртеп чыгып китә. Габдрахман юл өстендә торган урындык-*

*ны өстәл астына этәреп куймакчы була, ләкин анда нәрсәләр барлыгын тоеп җәймәне күтәреп карый. Зөбәйдәне күрә.)* А, бу кадәр сабырсызлыгың белән ничек син әниеннең карынында тугыз ай түзеп утырдың икән?

Зөбәйдә *(йөзе агарынган, өстәл астыннан чыга).* Кем ул?

Габдрахман. Безнең төзелештә эшләүче бер шофер. Квартир хозяйкасы өеннән куып чыгарган?

Зөбәйдә. Ни өчен куып чыгарган?

Габдрахман Тынычлы алмаганнар. Була бит кайчак шулай.

Зөбәйдә. Гаеп кемдә?

Габдрахман. Хозяйкасында, әлбәттә!

Зөбәйдә. Һы! Гаеп — хозяйкада, ә егетне комсомолдан чыгарганнар. Оригинально!

Габдрахман. Ярый, күп теленә салынма. Кешене урамда калдырып булмый.

Җәүһәрия керә.

Зөбәйдә. Ни өчен комсомолдан чыгарганнар аны?

Габдрахман. Ну, була бит кайчак шулай. Комсомоллар кызу халык. Төпченеп тормаганнар.

Җәүһәрия. Хуҗа хатыны белән чуалгандыр әле.

Габдрахман. Тсс!

Җәүһәрия. Шундый азган-тузган кешене өйгә алып кайттыңмы, абый? Кияүгә чыкмаган сеңелең, буйга җиткән кызың янына?

Габдрахман. Ул сезне ашамас. Бер-ике атнага түзәрсез.

Зөбәйдә. Түзмим! Андый кеше белән бер өйдә яшәргә теләмим!

Габдрахман. Зөбәйдә, син бала түгел! Егетнең критический момент. Ул эштән чыгарга җыенган иде. Мин аны үзем җибәрмәдем. Ул минем иң намуслы шоферым. Югыйсә, бездә беләсеңме нинди шоферлар да бар? Эшкә керә, без биш катлы йортны салып өлгермибез, ә ул үзенә Әмәт тавында биш почмаклы йорт салып кера. Гомумән, хәзер шофер табу җиңел түгел. Ә эшнең кызу чагы...

Мәрвәр керә.

Мәрвәр *(еламсырап).* Иптәш начальник, мин сездән ялынып сорыйм. Кая куйдыгыз минем иремне?

Габдрахман. Мин сезгә конторада чакта ук әйттем, иптәш Сафина. Мин бүген Булатны күрмәдем.

Кәримә, соңрак Фәрит керә.

Зөбәйдә. Начальник!

Мәрвәр. Ә миңа проходнойда башкача әйттеләр. Сезнең Булат белән киткәнегезне күреп калганнар. Кая куйдыгыз сез аны? Нигә сез, зур кеше була торып, бәхетсезлеккә дучар булган кыз баладан көләсез... Минә бит, плащы да биредә.

Зөбәйдә *(кулы белән күрсәтеп).* Ул әнә теге бүлмәдә!

Мәрвәр *(Зөбәйдә күрсәткән бүлмәгә таба китә. Ишектә Булат күренә).* Син мондамыни, бәгырь кисәгем? Нинди дулкынландыргыч очрашу! Газиз balаңны ташлап йөрисең, оятсыз, җирбит!

Булат. Бала минеке түгел! Синең моңа бернинди дәлилең юк!

Мәрвәр. Баланың синеке икәнлегенә шаһит юк дисең инде, ә? *(Башкаларга.)* Әйтегез, зинһар, андый эшнең шаһитлар күз алдында булуын кайсыгызның ишеткәне бар?!

Булат. Габдрахман абый!..

Мәрвәр. Габдрахман абыеңның безгә кирәге юк. Әйдә! *(Булатның кулыннан тарта.)*

Булат *(Мәрвәрнең кулын этәреп).* Кит әле!

Мәрвәр. Әле син шулай хатын-кызга кул да күтәрә беләсеңме-ни? Унбиш тәүлеккә утырмага барасың киләме, вак-төяк хулиган! Әнә анда кызыл билле машиналар йөреп кенә тора.

Фәрит *(Мәрвәргә)*. Туктале! Сиңа ничә яшь? Утыз биш? Кырык биш? Ә бу егеткә күп булса егерме. Ул — пацан. Ничек ул сине алдасын?

Мәрвәр *(мескенләнеп)*. Алданасың икән шул, жаныкам. Хатын-кызның чәче озын, акылы кыска дип белмичә әйтмәгәннәр. Без хатын-кызлар ирләрнең иркәләп-сыйпап әйткән сүзләренә ышанабыз. *(Мәлаемлык һәм кыланчыклык белән.)* Ә сез, мәхәббәтсезләр, сыйпаганда әйткән сүзләрегезне соңыннан онытасыз.

Булат. Алдаша ул, абый! Безнең арада андый эш булганы юк. Мин квартирант булып кына тордым.

Мәрвәр. Ялганлама, имансыз! Квартирант булып кына тормадың.

Фәрит *(Мәрвәрнең каршысына басып ишеккә ымлый)*. Кит шуннан!

Мәрвәр. Күр әле!

Фәрит. Кит шуннан!

Зөбәйдә *(зур канәгатьләнү белән)*. Ха-ха!

Мәрвәр. Нәрсә ха-ха? *(Габдрахманга.)* Әле сезнең үз кызыгызга кияү кирәк булдымыни? Шуның өчен минем иремне тартып аласызмы?

Зөбәйдә. Нахалка!

Булат. Ялган!

Жәүһәрия. Абый, нишләп милиция чакырмыйсың?

Фәрит. Да ыргытырга аны баскычтан! *(Мәрвәргә таба килә.)*

Мәрвәр. Ыргытмый гына тор әле — ыргытучы кушарлар! *(Булатка.)* Ну мин сиңа күрсәтермен әле, алла теләсә!

Фәрит. Бар, бар! Күрсәтәсе нәрсәңне син инде ана күптән күрсәткәнсең.

Мәрвәр *(Зөбәйдәгә)*. Егетнең бит бирнәсе бар! Китереп ташлыйммы бирнәсен?

Зөбәйдә. Ташла!

Мәрвәр *(Булатка.)* Билләһи, китереп ташлыйм баланны! *(Жилтерәп чыгып китә.)*

Фәрит. Что за авантюристка! Тапкансың, парень, бәйләнер хатын! *(Чыга.)*

Булат. Минем гаебем юк, абый! Ул яла яга! Оятсыз хатын ул!

Габдрахман *(утыра)*. Ух! Тәкатьне алды, ниһаять, бу хатын. Күренеп тора — ярты юлда туктап кала торганнардан түгел. Иртәгә трестка барып житәчәк. Берсекөнгә — аннан да югарыга. Ух, туйдым бу эштән. Берсе шешә белән дус. Икенчесе — хатыннар белән... Ә шуларның барысы өчен син жавап бирәсең... Туйдым! Жае гына чыксын, тынычрак урынга күчәм.

Зөбәйдә. Ә син кайда тыныч урын барын беләсеңме?

Габдрахман. Кайда?

Зөбәйдә. Бөек Британиядә. Королева Елизавета посты!

Габдрахман. И тилчә тел! *(Бүлмәсенә чыга.)*

Зөбәйдә *(тәрәзәдән карап)*. Нишләп йөрисез анда сарай түбәсендә, ә?! Егылып төшсәгез, ботыгызны бәреп сындырам бит! Төшегез! Төшегез, дим хәзер үк! *(Чыга.)*

Булат *(бер читтә аптырап басып торган Кәримәне күреп.)* Кәримә?! Син... син ничек монда?

Кәримә. Мин үземнең туганнарымда.

Булат. Син күптәнме монда?

Кәримә. Һәрхәлдә, синең хатынын килеп кергәндә, мин монда идем инде! *(Тиз-тиз чыгып йөгерә.)*

Булат *(тәмам югалып Кәримә артыннан бара)*. Ялганлый ул, Кәримә! Мин сина сөйләрмен! Мин сина аңлатырмын!.. *(Кәримә артыннан чыга. Зөбәйдә керә.)*

Әсхәт керә.

Әсхәт *(Зөбәйдәнең китап-дәфтәрләрен җыюын күреп)*. Кая барасын? Нигә өйрәнмисен?

Зөбәйдә. Әй, кылый күз коткарыр әле!

Әсхәт. Кем ул кылый күз?

Зөбәйдә. Анда университетта математиканы бер кылый күзле доцент кабул итә. Беләсеңме, матур кызларга белмәсә дә бишле куя икән. Ничек сиңенчә, матурмы мин?

Әсхәт *(оялып башын читкә бора. Тәрәзәгә карап)*. Самолет...

Зөбәйдә. Нәрсә?

Әсхәт. Самолет оча, реактивный...

Зөбәйдә китапларын күтәреп чыгып китә. Аның артыннан Әсхәт чыга. Габдрахман белән Фәрит керә. Бераздан тәмам аптыраган Булат керә.

Булат. Инде нишләргә Габдрахман абый? Әгәр ул баласын да китереп ташласа?

Фәрит. Илтәсен дә милициягә бирәсен! *(Чыга.)*

Габдрахман. Әйе!

Булат. Алай жәл була бит инде ул, Габдрахман абый...

Габдрахман. Жәл була? Димәк, бала синеке?

Булат. Қояштыр мена, минеке түгел! Шулай булса да жәл. Гөнаһсыз сабый бит ул! Нарасый!.. Өстәвенә, мин аны ярата да идем. Көлә дә башлаган иде инде ул.

Габдрахман. Беләсеңме нәрсә, энем. Син күзгә төтен җибәрмә! Болай булгач, хатынын да үзеңнеке, балаң да үзеңнеке! *(Кул селтәп чыгып китә. Булат ялгыз кала.)*

*Пәрдә*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вакыйга шунда ук бара. Искереп беткән коляска янында Җәүһәрия утыра. Бала елый.

Җәүһәрия *(коляскаиы селеккәләп)*. Я инде, бераз йоклап ал, ичмаса, бетәшәсе нәрсә!..

Габдрахман керә.

Габдрахман. Ашарга әзерме?

Җәүһәрия. Кайдан әзер булсын! Иртәдән бирле шушы имгәк янында.

Габдрахман. Зөбәйдә арбасымы?

Җәүһәрия. Әй, сарайдан алып менгән идем лә, селкеп утырырга җайлырак булыр дип. Иртәдән бирле елый. Ашамый да.

Габдрахман *(баланы карап)*. Нигә елыйсың, ә? Ярамый. Егет кешегә елау килешми... Күзләре Булатныкына да охшаган аның үзенең.

Җәүһәрия. Охшамый ни! Үзенеке булмаса, шунда ук илтеп ташлар иде әле.

Габдрахман. Шайтан белә бит! Миңа калса, егеттә гаеп юк. Бөтен хикмәт хатында монда — ул нәрсәнедер болгата.

Әсхәт керә.

Әсхәт. Исәнмесез! Зөбәйдә кайтмадымы әле?

Җәүһәрия. Күрмәдем... *(Әсхәтнең чыкмый торуын күреп, тупас итеп.)* Әйтәм ләбаса сиңа, күренмәде! Кайтканы юк Зөбәйдәнең *(Әсхәт чыга.)* Бүген августның икесе. Берсекөнгә без загска барабыз, мин китәм. Табыгыз урын балагызга. Таптылар бер опанный нәнке!

Габдрахман. Кызык син, Җәүһәрия. Кирәге булмаса, әллә мин аны өемә китереп тотар идемме! Дөнья бит бу — ата казга да сәлам бирергә туры килә кайвакыт. *(Өй эченә күрсәтеп.)* Шуның аркасында бит инде бу тормыш шулай булган. Менә бу йөз сиксән квартиралы йортны ай азагында тапшырсак — димәк, тагын премия. Расход чыга бит. Синең дә туеңны үткәрәсе бар.

Җәүһәрия. Үн ел асрау булып торган сеңелең турында авыз күтәреп расход дип сөйләргә оялмыйсыңмы син, абый?

Габдрахман. Сүз уңаенда гына әйтүем. Димәк, загска барасыз. Бәлки, берәз кичектерерсез, баланы урнаштырганчы сабыр итәрсез?

Җәүһәрия. Мин бик күп сабыр иттем инде — кырык сигезне тутырдым. Көне түгел, сәгате дә кадерле.

Габдрахман. Милициягә илтеп тапшырырга күндерсәң дә мәшәкате күп бит әле аның. Артыннан йөрергә, Булатны эштән җибәрергә кирәк. Җиңел генә булса — аны...

Җәүһәрия. Ә миңа җиңел! Бик җиңел миңа! Иртәдән чыгып киттегез дә, теләсәң нишлә, Җәүһәрия!

Сәрия керә.

Сәрия. Мөмкинме? Исәнмесез! Фәрит өйдә юкмы?

Җәүһәрия. Юк!

Сәрия. Кайчан гына өйдә була соң ул?

Җәүһәрия. Булмый ул өйдә, булмый! Кыяфәтеңне аздырып, егетләр куып йөрмә.

Габдрахман. Сез кем?

Сәрия. Ә сез, абый, кем буласыз?

Габдрахман. Мин Фәритнең әтисе.

Сәрия. Ә мин Сәрия. Буа кызы. Сезнең киленегез булам.

Җәүһәрия. Күрдеңме бу елдагы кызларны!

Габдрахман. Ничек була соң инде бу? Минем ишеткәнем юк иде әле. Узыгыз, утырыгыз. Сөйләгез.

Сәрия Рәхмәт. *(Утыра.)* Фәрит бездә еш була бит ул. Әле яз көне генә ике ай командировкада булып китте. Безнең районның бер колхозы яңа сорт бодай үстерә. Фәрит шул турыда диссертация яза. Хәер, анысын үзегез дә беләсез булыр инде...

Габдрахман. Анысын беләбез. Ә менә киленебез барлыгын беренче тапкыр ишетәм. Сез нәрсә, Фәрит белән загста да булдыгызмы?

Сәрия. И, абый җаным, яратуың чын булгач, загска барып язылу формальность кына бит ул!.. Ә шулай да, ул киткәч шактый борчылган идем.

Габдрахман. Соң?

Сәрия. Хәзер тынычландым инде. Бик җылы хатлар язып торды ул миңа.

Җәүһәрия. Шаярып Зөбәйдә язган хатлар ич ул, җүләр кыз! Мәзәк итеп язган хатлар!

Габдрахман. Ничек, мәзәк итеп язган хатлар?

Җәүһәрия. Фәрит үзе язмагач, Зөбәйдә язган. Абыйсы булып.

Габдрахман. Нәрсә дип язган?

Җәүһәрия. Шаярып язган инде, нәрсә дип язса да.

Габдрахман *(Сәриягә)*. Ул хатлар сездәме?

Сәрия (оялып). Соң бит, абый...

Габдрахман. Мин хатын укымам. Сез миңа аның кулын гына күрсәтегез. *(Сәрия сумкасыннан конверт чыгарып күрсәтә.)* Монда күп нәрсә аңлашылып житми, кызым. Фәритнең үзен күреп сөйләшү кирәк.

Сәрия. Өйдә туры килми бит! Әгәр институтына барсам?

Габдрахман *(сагаеп)*. Юк, институтта юктыр ул Фәрит. Син анда барып йөрмә. Мондый нәрсәләрне өйдә сөйләшү яхшы! Фәрит командировкага китәм дигән иде ул. Казанда юк Фәрит. Берничә көннән кайтыр. Килерсең. Сөйләшербез. Ә институтка барма, анда юк ул. Сау булып тор бүгенгә! *(Кул суза.)*

Сәрия. Сау булыгыз. *(Чыга.)*

Җәүһәрия. Син нәрсә — акылыңдамы?

Габдрахман. Кычкырма әле! *(Папирос каба, ачу белән шырпы сыза.)* Ух оятсыз! Өйләндерәм! Кыйнап булса да өйләндерәм!

Җәүһәрия. Тәкъдире житкәч, кыйнамасаң да өйләнер.

Габдрахман. Утыз көн уразаның бер гаете булырга тиеш ләбаса, ниһаять! Күпме сайларга мөмкин!

Җәүһәрия. Гомер итәсе кешене сайлыйсың шул аны!

Габдрахман. Син өйрәтәсеңмени әле аны сайларга? Егетләр сайлый-сайлый кырык сигезгә хәтле утырдың инде, авылның беренче кызы. Юк, әгәр яхшылык белән өйләнмәсә...

Җәүһәрия. Кыз үзе гаепле монда. Сарылмасын иде!

Габдрахман. Аның яшендәге кыз бала, яраткач үлеп торамыни!

Җәүһәрия. Акыллысы үлмый! Минем дә булды яшь чагым...

Габдрахман. Һәй, син дә сөйләшәсең ичмаса...

Җәүһәрия. Нигә сөйләшмим! Кәрим Сафасын ни яратып йөрдем! Сугышка китәсе кичне үлеп ялынды. Истәлек өчен бер генә үбим лә, диде. Үптермәдем!

Габдрахман. Үлем эченә китүче кешедән шуны да кызгангансың!

Җәүһәрия. Ник кызганмыйм! Ул шуннан башлана.

Габдрахман. Шуңа җимешсез агач шикелле утырып калдың да инде син. Кипкән ботак! *(Ишеккә бара.)* Ярты сәгатьтән мин өйдә булам. Фәрит кайтса, чыгып китмәсен! *(Чыга.)*

Җәүһәрия ялгыз. Трельяж тартмасыннан таушалып беткән, өчпочмаклы хат ала, утырып укый. Укып бетергәч, хатны күзгә өстенә куя, күзгәгә карап үйга чума. Битендәге жыерчыкларны сыпырып ала.

Мәрвәр керә.

Мәрвәр. Исәннәрме сез! Ни эш бетерел ятасыз? *(Каранып.)* Өйдә үзегез генәме? Минем юньсез кайда?

Җәүһәрия. Эштәдер.

Мәрвәр. Ничек соң, жаныкам, нәрсәләр сөйли? Өйгә кайтырга исәбе бармы?

Җәүһәрия. Аның исәбен мин кайдан белим!

Мәрвәр. Соң, жаныкам, сөйләшәсез булыр бит инде. Кичә мин чыгып киткәч ниләр булды?

Җәүһәрия. Берни дә булмады. Бала карап утырды — шул булды. Без аңа баланы милициягә илтеп тапшырырга кушкан идек. Илтмәде — жәл, ди.

Мәрвәр. Әә, жәл булмый ни, жаныкам, жәл шул. Газиз бала бит ул! Шуннан, жаныкам, шуннан?

Җәүһәрия. Менә мин багып утырам хәзер. Бүген елый да елый. Әллә авырый инде.

Мәрвәр. Шуннан, жаныкам, шуннан. Начальнигы ни ди соң? Бала аныкы дип әйтеп әйтәме?

Җ ә у һ ә р и я. Юк. Бала Булатныкы булырга тиеш түгел, ди.

М ә р в ә р. Ничек түгел ди?! Кеше күңеленә коткы салып йөрсә, мин аның белән сөйләшә белермен! *(Коляска янына килә.)* И, ничек ята бәгырь кисәгем! Өстенә рәтләп ябу юк, астына яхшылап җәю юк. Шулай кадерсез яткач, авырмый нишләсен бала! *(Баланың урынын рәтли. Култык астына китап-дәфтәрләр кыстырган Зөбәйдә керә.)* И, харап кына иткәннәр бәбәкәчемне. Башы мунча ташы кебек! Җары бар! Чакырдыгызмы врач?

Җ ә у һ ә р и я. Кайдан чакырыйк әле!

М ә р в ә р. Үзе юкның күзе юк, бетмәс әле дисезмени? Танырлык җирен дә калдырмаганнар балакаемның.

Җ ә у һ ә р и я. Алай бик кадерле бала булгач, китереп ыргытмаслар.

М ә р в ә р. Ыргытсам, үзенең әтисенә ыргыттым. Ә сез аңа салкын тидергәнсез. Шуннан үлеп китсә бала?

Җ ә у һ ә р и я. Беркемгә дә кирәге булмаган баланың үлүе дә хәерле.

М ә р в ә р. Әһе! Әле сез аңа юри салкын тидердегезмени? Үлсен дип? Бик җиңел котылырга уйлаган. Күрсәтермен мин аңа күрмәгәнен! Кеше үтерүчеләр өчен закон бар хәзер! *(Тәрәзә янына килә. Анда басып торган Зөбәйдәне бер кырыйга төртеп, тәрәзәне яба.)* Ирем үземә кала дип торма. Үтерешкә катнашучыларга да закон бар, чувиха!

З ө б ә й д ә. Нахалка! *(Мәрвәрнең битенә китап ыргыта.)*

Җ ә у һ ә р и я *(Мәрвәрне ишеккә таба төрткәләп)*. Син нәрсә — сугышырга килдеңме? Бар әле чыгып кит моннан!

М ә р в ә р. Әле сез шулаймыни? Баламны гына түгел, үземне дә җир йөзеннән юк итмәкче буласызмы?

Җ ә у һ ә р и я. Алып кит баланы!

М ә р в ә р. Китмим!

Җ ә у һ ә р и я. Алайса күземнән югал! *(Як-ягына каранып, нәрсә белән куndырыйм икән, дигәндәй.)* Китәсеңме, юкмы башың исән чакта?

М ә р в ә р. Яхшы! *(Зөбәйдәгә.)* Мин сине нишләтергә кирәген беләм. Комсомолдырсың әле син. Кайда укыганыңны эзләп табармын мин синең!.. Чыгып китмәгез — хәзер врач чакырам! *(Чыга.)*

Җ ә у һ ә р и я. Күр әле оятсызны! Монда килеп, болай да кызган канга тоз салып йөри... *(Зөбәйдәнең идәндә тузып яткан китапларын тибкәләп.)* Җый бу китапларыңны! *(Зөбәйдә кычкырып елап җибәрә.)* Нәрсә булды тагын?

З ө б ә й д ә *(үксеп)*. Провалить иттем!.. Шундый яхшы сөйләдем, шундый яхшы сөйләдем! Барыбер икеле куйды кылый!

Җ ә у һ ә р и я. Әйбәт булган — әчеңә таман. Икенче яхшырак өйрәнерсең... Үкермә, болай да башым авырта!.. *(Пауза.)* Теге нәмәрсә тагын килгән иде. Кичәге кызны әйтәм. Абый өйдә туры килде. Исе дә китми, мин сезнең киленегез дип шартлатып тора. Синең хатларыңны да күрде әтиең. Фәритне кыйнап өйләндерәм, дип чыгып китте... Фәритне яклаган өчен әлкте миңа. *(Үксеп.)* Аны син өйләндермисең, җимеш бирмичә корыган агач син, ди...

З ө б ә й д ә. Дөрес әйткән!

Җ ә у һ ә р и я. Корымый гына торсын әле! Җимеш бирәсе көннәрем алда әле минем. *(Көзгедән карап.)* Бал ачымый, кыз картаймый, дигәннәр. Бер ак чәчем юк әле минем! *(Бала шыңшыраша. Җәүһәрия бала янына килә.)* Сөтен дә эчми бу имгәк, әллә тамагы авырта инде. Кил әле, тамагын карыйк!

З ө б ә й д ә. Кара үзең!

Җәүһәрия. Я, кил инде! Мәктәптә медсестралыкка укыттылар лабаса үзегезне.

Зөбәйдә *(тәрәзә төбенә менеп утыра).* Аптыратма диләр сина! Үземнең дә башым бишкә ярыла — сабыйлыгым белән генә йөрим.

Җәүһәрия. Зөбәйдә дим! Я, кил инде!

Зөбәйдә *(коляска янына килә, үксеп, күз яшьләрен сөртә-сөртә).*

Елама, балам, елама,
Җылы катык сорама.
Җылы катык мичтә
Әнием кайтыр кичкә.

*(Кашык алып килеп.)* Яле, тамагынны карыйк әле, елак малай. *(Баланың тамагын карап.)* Ангина булган бит монда!

Җәүһәрия. Әйтәм җирле елый да елый.

Зөбәйдә. Менә дигән фолликуляр ангина. Пенициллин бир! *(Балага карап тора, мендәрен төзәтеп куя. Җәүһәрия күрше бүлмәгә чыга. Телефон шалтырый. Зөбәйдә трубканы ала.)* Ә, Булат икән. Нияз авырый әле, Булат, ангина булган. Юк, куркыныч түгел, пенициллин эчкәч бетә. Булат! Теге хатын килгән иде... Ну, Ниязның әнисе. Без аны кыйнап чыгардык. Честное комсомольское!.. Шоколад? Ярый. *(Трубканы куя. Фәрит керә.)* Сезне тәбрикләргә рөхсәт итегез, сударь! Өйләнәсез икән.

Фәрит. Что за глупость!

Зөбәйдә. Сәрия тагын килгән. Начальник барысын да белә.

Фәрит. Вот нахалка! *(Оекбашын салып Зөбәйдәгә бирә.)* Мәле, шуны эләктереп бир әле.

Зөбәйдә. Тиздән хатының була, яматырсың.

Фәрит. Не ослоумничай!

Зөбәйдә *(энә-җеп алып оекбаш ямарга керешә).* Оекбаш ямаудан котылам инде, алла теләсә! Кулмәкләренне дә хатының уар. Без уганны яратмый идең. Хәләл җефетебез бик яхшы уар инде!

Фәрит. Перестань пилить!

Зөбәйдә. Ха, өйрәнә тор! Әле болай гына пилить итмәс. Килен килә, килен килә, кисап бүе теле килә... Ә мин имтиханны провалить иттем.

Фәрит. Молодец!

Зөбәйдә. Молодец шул.

Фәрит. Әйттем мин сиңа университетка бирмә дип! Анда конкурс зур. Безнең сельхозга бирсән — ике экзаменына бишлене үзем куйдыртып чыгара идем.

Зөбәйдә. Ә мин анда теләмим. Теләмим авылга китәргә!

Фәрит. Укып бетергәч, китмәскә дә була.

Зөбәйдә. Барыбер теләмим!

Фәрит. Ну и җүләр!

Зөбәйдә. Җүләр икәнлегемне мин синнән башка да беләм. Берәр яңа нәрсә әйт син. *(Ачу белән оекбашны Фәриткә ташлый.)*

Җәүһәрия керә.

Җәүһәрия. Бөтен дөньяны актардым — бер генә таблетка пенициллин таптым. Мә, бир, сөтенә издем. *(Фәритне күреп.)* Абый синә чыгып китмәскә кушты. Ул сине теге нәмәрсәгә өйләндерәм ди. *(Чыга.)*

Фәрит. Нәрсә?

Габдрахман керә.

Габдрахман. Кайттыңмы син? Монда бер кыз булды. Исемен оныттым. Син аны беләсеңдер.

Фәрит. Бөтен ыргыткан кызларның исемен белеп бетермәссең.

Габдрахман. Ыргыткан! Ташлаган дип әйтә белсән иде, ичмасам. Ыргыткан! Әйдәле теге бүлмәгә! *(Фәритне иәртеп үз бүлмәсенә китә башлый).*

Зөбәйдә. Начальник! Сезнең кызыгыз бүген имтихан бирергә тиеш иде. Нишләп кызыксынмыйсыз?

Габдрахман. Бирденме соң?

Зөбәйдә. Икелегә... бирдем.

Габдрахман. Алайса ник авызыңны жәйден?

Зөбәйдә. Елыйммы әллә?

Габдрахман. Еласаң да урынлы...

Зөбәйдә. Елап тормыйм әле!

Габдрахман *(Фәриткә).* Әйдә! *(Фәритне бүлмәсенә кертеп ишекне яба башлый.)*

Зөбәйдә. Начальник! Мин укымаска булдым.

Габдрахман. Укыма! Әнә безгә балчык изеп торучылар кирәк. Барып керерсең.

Зөбәйдә. Хәзер, чаптым!

Габдрахман. Чапмасаң, алтмышка житкән башым белән мин сине ашатып ятмам.

Зөбәйдә. Ашатма!

Габдрахман. Ашатмам шул!

Зөбәйдә. Моңа кадәр ашатмаска да мөмкин иде бит. Хәтта мине тудырмаска да мөмкин иде. Мин бит сиңа «Начальник, мине дөньяга китерегез әле!» дип үтенеч язмадым.

Габдрахман. Булыр-булмас кешегә дилбегә буе тел бирер, дигәннәр. Шушыдыр инде ул. Кара аны, мин сине тунеядец итеп асрап ятмам!

Зөбәйдә. Курыкма, синекен ашамам. Кияүгә чыгам.

Габдрахман. Бар, бүген үк чык! *(Фәрит белән бүлмәсенә кереп бикләнә.)*

Зөбәйдә ялгыз. Коляскада бала елый. Зөбәйдә, колясканы кочаклаган хәлдә, тавышсыз гына елый-елый, бала тирбәтә. Жәүһәрия керә.

Жәүһәрия. Ни булды тагын?

Зөбәйдә *(кычкырып елап жибәрә).* Мин сине ашатам! Мин сине киендерәм!.. Әйтерсең мин үзем теләп тудым...

Жәүһәрия. Юк өчен авызыңны жәеп утырма! Күрмисеңмени, әтиеңнең кәефе начар вакыт.

Зөбәйдә *(әрнү белән).* Ә минеке яхшы!.. Кызы имтихан бирә алмыйча кайткан. Әти булган кеше бер кеше төсле итеп сөйләшергә тиешме, юкмы, синенчә?!

Кәримә керә.

Кәримә. Исәнмесез!

Жәүһәрия. Әйдә уз, Кәримә, ни эш бетереп йөрисең?

Кәримә. Бетергән эш юк. Менә Зөбәйдәне туган көнемә чакырырга килдем. *(Баланы ачып карый.)* Хи-хи-хи! Ничек матур итеп йоклап киткән!

Зөбәйдә. Кагылма балага, авырый ул!

Жәүһәрия. Һай, сиңа да үпкәгез тулды, Кәримә!

Кәримә. Бер тугач, үсәсең икән шул. Иртәгә сәгать жидедә, Зөбәйдә, ямә!

Зөбәйдә. Мин бармыйм, эшем бар.

Кәримә. Нишлисең?

Зөбәйдә. Дуңгыз дагалыйм!

Кәримә. Шулай инде. Без бит сезнең шикелле булачак доцентлар да, булачак инженерлар түгел...


Зөбәйдә *(аяныч белән)*. Кәримә!

Җәүһәрия. Бүген кәефе юк аның. Иртәгә хәтле кырык төрле булыр әле, барыр. *(Чыга.)*

Кәримә. Чит кеше бирәү дә булмый. Үзебезнең төзелештән берничә кыз гына. *(Баланың башын тотып.)* Бичаракайның башы ут кебек... *(Габдрахман бүлмәсендә нәрсәдер гөрселдәгән тавыш ишетелә.)* Нишлиләр анда?

Зөбәйдә. Начальник үзенең улын өйләндерә.

Этисе бүлмәсеннән Фәрит атылып чыга.



Габдрахман — РСФСРның атказанган, ТАССРның халык артисты Нәжип Гайнуллин.

Габдрахман *(ишектә)*. Кая барасың?

Фәрит. Мин сиңа мальчишка түгел, отчет бирергә.

Габдрахман. Кара нинди зур кеше булган, оятсыз! Әмма мин сине авызлыкларга юл табармын!.. Әгәр шуннан бала булса?

Фәрит. Мало ли кайларда синең белән минем балалар үсә! Бөтенесенә дә ата була башласаң... *(Габдрахман көч белән Фәритнең яңагына суга.)* Нәрсә, дөрес сүз күзне кадыймы? Әйтерсең, синеке булмады яшь вакыт?

Габдрахман. Синеке төслесе — юк!

Фәрит. Хәзер, ышандылар ди! Әни өчәр ай больницада авырып ятканда, әйтерсең син гулять итмәдең? Тетя Паша белән! Бишәр көн өйгә дә кайтмый идең... И хәзер дә әле син гулять итәсең! Уйлыйсың, мин белмим?

Габдрахман *(тәмам җебеп төшә)*. Белсәң, минем арттан өйгә килмиләр.

Фәрит. Еще бы! Син бит карт бүре!

Пауза.

Габдрахман. Җүләр син, улым. Мин синең үз файдаңа әйтәм. Әгәр ул институтка барса, партбюрога керсә! Бөтен карьераңны боза бит ул синең!

Фәрит. Ә син минеке өчен кайгырма. Үзеңне бел!

Фәрит чыга. Габдрахман нишләргә белми бүлмә буйлап йөргәндә Кәримәгә барып төртелә.

Габдрахман. Син монда нишләп торасың, Кәримә?!

**Кәримә** *(куркып)*. Мин... минә Зөбәйдәнс туган көнемә чакырырга килдем...

**Габдрахман.** Барыр, барыр! Аның эше юк хәзер. Кунакка йөрү генә калды.

**Зөбәйдә.** Бәлки бармам! Нигә минем өчен җавап бирәсең?

**Габдрахман** *(йомшак тавыш белән)*. Кәримә сиңа якын туган. Син аның туган көненә барырга тиеш.

**Зөбәйдә.** Мин барырга тиеш! Ә Кәримә үзе, гомер эчендә бер генә булса да, минем туган көнемә килергә тиешме?

**Габдрахман** *(бөтенләй югалып)*. Тиеш, әлбәттә. Синекен дә үткәрербез. Кайчан соң әле синең туган көнең?

**Зөбәйдә.** Белмим! Җүләрлегем аркасында тугач та календарьга каралмаган.

**Габдрахман.** Ярый, барыр ул, Кәримә. Мин аны җибәрермен.

**Зөбәйдә.** Ал яңа күлмәк — барам!

**Габдрахман.** Кияүгә чыгам дисең ләбаса. Киявең алыр.

**Зөбәйдә.** Бәлки синең шикелле саран туры килер. Алмас.

**Габдрахман** *(бармак янап)*. Ну синең бу телеңне! Кисеп алам әле бер!

Габдрахман чыга. Җәүһәрия керә.

**Җәүһәрия.** Кәримә, ускәнем, ашым соңга калды. Бәрәңге арчыш әле миңа. Син бик оста арчыйсың.

**Кәримә.** И раббым, бәрәңге арчырга осталык кирәкмени аңа!

**Җәүһәрия.** Әйдә инде, минем кулым авырта.

Кәримә белән Җәүһәрия кухняга чыгалар. Зөбәйдә ялгыз. Пауза.

**Зөбәйдә** *(радиола өстендәге курчакны алып тәрәзә төбенә утыра)*. Эшләр менә шулай, Ләйлә! Абау, кем буяды синең бу борыныңны! Яле, яле, сөртеп алыйк әле шуны. Менә шулай! Менә тәти булды хәзер Ләйлә. *(Курчакны һавага чөеп.)* Уп-па! Ха-ха-ха! Уп-па!.. *(Колясқада бала ыңгырашып куя.)* Тсс, Ләйлә, шаулама. Бәби йоклый. Бәбигә бубу булган, тамагы авырта бәбинең. Башы ут кебек булган бәбинең... Апаң имтиханын бирә алмый кайтты шул әле, Ләйлә. Нишләр инде хәзер апаң, ә? Башы да авырта апаңның. Тотып кара әле! Кайнармы? Бәбинең дә башы кайнар... Күлмәгең дә керләнгән икән инде синең. Кер уганда әйтерсең, яме! Кызлар чиста булырга, матур булырга тиеш... Ә? Нәрсә, нәрсә? Матур булсаң да икеле куйдылар, дисеңме? Белмәгәч, куялар икән шул, матур дип тормыйлар икән... Нишлибез соң инде хәзер Ләйлә? *(Курчагын кочаклап.)* Ичмаса, син дә миңа берәр киңәш бирмисең!..

*Пәрдә*

### ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бер сәгать узгач.

**Зөбәйдә** *(телефонда)*. Сәлам, Зөфәр, бу — Зөбәйдә. Зөфәр, бер минут торма, безгә кил! Сагындым, күрәсем килә. Килгәч белерсең. Озак торма! *(Трубканы куя. Тәрәзәгә килә.)* Әй, Славик, синең вакытың бармы? Бер йомыш кушсам тыңларсыңмы икән? *(Арттан тавыш: «Нәрсә ул?»)* Миңа магазиннан букет алып кайтып бир әле! Мә, акча! *(Ыргыта.)* Беләсеңме, букетны минем сигнал белән кертерсең. Менә курчак. Шушы курчак тәрәзә төбеннән юк булгач та, керт. Яме!

Әсхәт керә.

Ә с х ә т. Я ничек, бирдеңме?

З ө б ә й д ә. Нәрсә ул, Әсхәт? *(Әсхәтнең кулындагы картинкаларны ала.)* О, нинди күп!

Ә с х ә т. Бирдеңме имтиханыңны?

З ө б ә й д ә. Браво, Әсхәт! Син миңа ошыйсың.

Ә с х ә т. Имтиханыңны бирдеңме?

З ө б ә й д ә *(картинкаларны карап)*. О, нинди матурлары бар!

Ә с х ә т. Ничәгә бирдең?

З ө б ә й д ә. Берәү, икәү, өчәү...

Ә с х ә т. Санап торма. Өч йөз дә җитмеш бер.

З ө б ә й д ә. Ой, Әсхәтчек, кил шуның өчен бер үбим үзеңне! *(Ике колагыннан тотып Әсхәтнең маңгаеннан үбә).* Ой, Әсхәтчек, шушы картинкаларны ничек яратуымны белсәң иде син! Дөньяда иң зур куанычым шул. *(Радиола астындагы тумбочкадан бик күп картинкалар чыгара.)* Менә бит ни хәтле булды инде! Аларны менә шулай актарып утыруы, санап караулары шундый күңелле! Алар минем тормышымда бер бизәк кебек. Алар белән син минем тормышымны матурлыйсың, Әсхәт...

Ә с х ә т. Авыр сораулар эләктеме? Ничәгә бирдең?

З ө б ә й д ә. Әй, аптыратма әле, Әсхәт!.. *(Көзге алдына килеп пудра ягына башлый.)* Кил монда! *(Әсхәт Зөбәйдәгә якынлаша.)* О, чалбар балагың тарайткан! Ничә сантиметр?

Ә с х ә т. Унсигез.

З ө б ә й д ә. Таррак. Хәзер иң модный балак егерме сантиметр. Аннан манжет та модада түгел хәзер... Яле, сиңа пудра килешәме икән. *(Әсхәтнең битенә пудра яга.)* Сиңа мыек та чыга башлаган икән инде, Әсхәт... Ой, нинди матур булдың! *(Көзге өстендә Җәүһәрия онытып калдырган хатны күреп.)* «Икенче сентябрь, 1941 ел». Нәрсә бу? «Туган илләрдә яшәүче язгы таң күбәләгем, күктәге кояш кебек, ай кебек түгәрәгем! Табигать кочагында, кояш нурлары астында, кара урманда, яшел аланда үскән хуш исле гөлләргә тиңләмәслек гүзәл ярым... *(Укуык белеп.)* О, бу бит мәхәббәт хаты, Әсхәт! *(Көлә-көлә укуын дәвам итә.)* ...Челтерәп аккан салкын чишмә буенда, нечкә тал чыбыкларында канат кагынып сайраган сары сандугачлар санынча булган сагыну сәламнәремне шушы кәгазьгә язып, сезнең якка искән иркә таң җилләре белән синең үзеңә, нурлы йөзеңә, серле күзеңә... *(Хат укыганда Җәүһәрия керә. Ул азрак тыңлап тора да тиз-тиз килеп хатны тартып ала.)* Укып бетерим инде, туган апам!

Җ ә ү һ ә р и я. Бетерми генә тор әле! Бар әнә, аптиктән пенициллин алып кайт!

З ө б ә й д ә. Әсхәтчек, уң күзем, чалбар балагың да бик модный икән, чәчләрең дә көдрә — бар, йөгереп пенициллин алып кайт! *(Җәүһәрия Әсхәткә акча бирә. Әсхәт йөгереп чыгып китә.)* Туган апам, укыйм инде шул хатны!

Җ ә ү һ ә р и я. Укымый тор әле! Күпне белсәң тиз картаерсың.

К ә р и м ә к е р ә.

К ә р и м ә. Ярый, мин китәм.

З ө б ә й д ә. Юк әле, юк, китмисең!

К ә р и м ә. Ашыгызны өлгерттем. Бәлки ашатып та китәргәдер?

З ө б ә й д ә. Юк, чынлап. Хәзер бер кызык эш булачак! *(Куеныннан хат чыгара.)*

Җ ә ү һ ә р и я. Берәрсеннән хат бармы әллә? Кайда, укыйк әле!

З ө б ә й д ә *(хатны яшереп)*. Укымый гына тор әле! Күпне белсәң тиз картаерсың. Аннары Сәмигулланың да яратмас үзеңне.

Б у л а т к е р ә.

Булат. Исәнмесез, кызлар!

Кәримә. Исәнмесез!

Булат *(балага якынлашып)*. Хәле бик начар түгелме?

Зөбәйдә. Туена хәтле терелачәк!

Булат. Врач чакырырга сондыр инде хәзер...

Зөбәйдә. Мин куйган диагнозга ышанмыйсызмыни?

Булат. Ышанам да...

Зөбәйдә. Беләсегез килсә, мәктәптә безне медсестралыкка өйрәттеләр. Мин бишлегә бирдем.

Булат. Алайса, нигә медсестра булып эшләмәдегез?

Зөбәйдә. Яратмадым. Була бит шулай: эше ошамый.

Булат. Ә минемчә ул сүзне ялкаулар уйлап чыгарган — үзләрен аклар өчен. Кеше ялкау булмаса, хезмәт сөйсә — минемчә, һәр эштән кызык табарга мөмкин.

Зөбәйдә. Сез шулай уйлыйсызмы?

Булат. Әйе. *(Кесәсеннән ике плитка шоколад чыгарып Кәримә белән Зөбәйдәгә бирә.)*

Зөбәйдә. Мондый игътибарлы булгач, кызлар сезне яраталардыр, Булат.

Булат. Сезне дә егетләр читләтеп үтми бугай.

Зөбәйдә *(бармаклары белән санап)*. Унбер егет аяк очымда.

Булат. О, тиздән дюжина була, димәк!

Зөбәйдә. Ихтимал!

Җәүһәрия керә.

Җәүһәрия *(Булатка)*. Сәгать өч тулгач, балага сөткә керерсен, Булат. *(Зөбәйдәгә.)* Мин Сәмигулла абыеңа карлыган җыешырга киттем. *(Чыга.)*

Зөбәйдә. Сез тәнкыйть күтәрәсезме, Булат?

Булат. Тәнкыйтьне яратабыз инде аны.

Зөбәйдә. Нигә шундый киң балаклы чалбар киясез? Нәкъ юбка!

Булат. Чалбарны сез кигәнсез бит! Миңа юбка калган. *(Курше бүлмәгә үза.)*

Зөбәйдә. Серкәсе су күтәрми икән.

Кәримә. Ничек синеңчә, Зөбәйдә, бу бала чыннан да анныкымы икән?

Зөбәйдә. Кайгың шул гына булса, Кәримә, өеңә кайт та ят та йокла. Юк белән башыңны катырма.

Булат керә.

Булат. Ул бүлмәнең стеналарын кем обойлаган иде, Зөбәйдә?

Зөбәйдә. Әллә начармы?

Булат. Киресенчә! Кәримә, синең игътибар иткәнең бармы? *(Кызлар бер-берсенә карап елмаешалар.)* Нигә без үзебез салган йортларның квартираларын шулай көләп тора торган итеп буямыйбыз? Кайсы гына квартирага килеп кермә, күңел болгаткыч соры төс тә, көрән төс.

Кәримә. Әйт начальникка, җибәрсен яхшы буяулар.

Булат. Үз кызының бүлмәсен әйбәт буяткан ул.

Зөбәйдә. Беләсегез килсә, ул бүлмәне Кәримә белән без обойладык шул. Начальникның катнашы юк анда. *(Чыга.)*

Булат *(сүз юктан сүз булсын итебрәк)*. Ә мин синең Габдрахман абыйның туганы икәнеңне белми идем.

Кәримә. Кайчак шулай да була икән шул. Мин дә бит кайбер нәрсәләрне белми йөргәнмен.

Булат. Димәк, син миңа ышанмыйсың?

Кәримә *(балага ымлап)*. Ул сиңа охшаган.

Булат. Яшь баланың кемгә охшавын белеп буламыни әле аның! Ә ничек синеңчә, бу бала күпмелек?

Кәримә. Дүрт-биш айлыктыр.

Булат. Алтынчы ае. Ә минем ул хатында тора башлавыма бер ел.

Кәримә. Бәлки сез элек таныш булгансыз.

Өстенә матур күлмәк киеп Зөбәйдә керә.

Зөбәйдә. Иртәдән бирле елыйсым килеп йөргән иде, ачуын чыгарыйм әле! *(Булат коляскаиы бүлмәсенә алып китә.)*

Кәримә. Матур да инде син, Зөбәйдә! Артисткалар кебек. Нигә мин дә шулай матур булмадым икән!

Зөбәйдә. Ә мин сиңа күптән әйтәм, чәчеңне кистк, дип.

Кәримә. Чәч кисеп кенә матур булсалар иде!.. *(Пауза.)* Зөбәйдә! Кичә син аны ике көндә үземә гашыйк итәм, дигән идең.

Зөбәйдә *(Булат бүлмәсенә ымлап)*. Монымы? Аның миңа нигә кирәге бар!

Кәримә. Уйласаң уелып китәрлек эшләр бар дөньяда! Нишләтә инде ул хәзер бу баланы.

Зөбәйдә. Хафаланма. Өйләнгән төшкә эше кими торыр. Шундый оригиналь калымы булган егеткә чыгучы кыз табылса, әлбәттә.

Кәримә. Мине шундый егет яратса иде әле...

Зөбәйдә. Кәримә! Гашыйк булдыңмы?

Кәримә. Китсәнә, я үзе ишетер!

Зөбәйдә. Телисеңме, үзем яучы булам? *(Звонок.)* Керегез!

Сөендек керә.

Сөендек. Хәерле көн! Сәлам, Зөбәйдә! Сәлам, Кәримә! *(Зөбәйдәгә бер тартма монпасье бирә.)* Нәрсә белән котлыйбыз үзеңне? Отличномы?

Зөбәйдә. Бу монпасье унөч тиен тора. Саран син, Сөендек! Шуңа өйләнә дә алмыйсың.

Сөендек. Син бернәрсәне аңламыйсың, Зөбәйдә. Кайбер егетләр буш өйгә дә хатын алып кайталар. Хәтта кеше почмагына да. Ә мин алай теләмәдем. Мин башта булачак хатыным өчен шартлар тудырдым. Квартира, обстановка, машина һәм, әгәр теләсәң, запас на черный день. Шуларга өстәү итеп саф йөрәгем.

Зөбәйдә. Утызга житкән саф йөрәгең сөрсеп бетмәдеме икән синең!.. *(Звонок. Зөфәр керә.)* Менә Зөфәр чын кавалер ичмаса. Ул мине унөч тиенлек монпасье китереп мыскылламый. Таныш булыгыз: Сөендек — инженер-конструктор. Бусы — Зөфәр, врачлыкка укый. *(Зөфәр белән Сөендек кул кысышалар.)* Я, Зөфәркәем, эшләр ничек? *(Әсхәт керә.)*

Әсхәт *(Сөендек белән Зөфәргә каш астыннан карап)*. Кая куйыйм пенициллинны?

Зөбәйдә. Алып кайттыңмы, тәтием. Бир монда! *(Әсхәт чыга башлый.)* Кая барасың әле? *(Тәрәзә төбеннән курчакны ала.)*

Әсхәт. Бүрекле белән Күреклегә жим бирәсем бар, чыгам.

Зөбәйдә. Чыкмыйсың, чыкмыйсың! Син миңа кирәк. Утыр! *(Сабырсызланып ишеккә карый.)*

Зөфәр. Бу нәрсә — мәжлесме соң?

Зөбәйдә. Сабыр ит, Зөфәр, күрерсең. *(Булат керә.)* Ә сез кая барасыз?

Булат. Сөткә.

Зөбәйдә *(Булатның шешәсен тартып ала)*. Әле сәгать өч тулмаган, өлгерерсез... *(Зур букет күтәреп Славик керә.)* О, Славик! *(Кар-*

*шы килеп Славикның колагына.)* Артык бер сүз әйтмә. *(Кычкырып.)* О, шушындый матур букет миңамы бу? Рәхмәт! Уз әйдә, Славик, утыр! *(Пауза. Бернәрсә аңламаган егетләр бер-берсенә караналар.)* Ух алла! Әллә ниләр әйтергә теләгән идем — Славикны күргәч, уйларым таралды да китте... Кыскасы, егетләр, бүген мин имтиханны провалить иттем. Университетка керү очты.

Әсхәт *(шаккатып)*. Ничек провалить иттең?!

Зөбәйдә. Аh Әсхәт, ничек булуын күрерсең әле, башың яшь... Менә шулай, егетләр. Сезнең килүегездән файдаланып, мин киңәшмә үткәреп алырга уйладым. Киңәшмәне ачык дип белдерәм. Утырышыгыз! Кәримә, син дә утыр!.. Булат, әнә шул үзегез алып кайткан шоколадны китереп бирегезче! *(Булат өстәлдәге шоколадны китереп бирә.)* Көн тәртибендә бер мәсьәлә: Ленинград диңгезчесе Абдуллин Әнәснең хатын уку һәм фикер алышу. Белмәгән кешеләр өчен берничә сүз әйтеп китәм. Абдуллин Әнәс диңгез училищесын тәмамлаган егерме биш яшьлек егет. Хәзерге көндә Ленинградта яшь һәм чит илләргә йөрүче зур корабта хезмәт итә. Күптән түгел генә үзен капитанның беренче ярдәмчесе итеп билгеләделәр һәм инде капитан посты да чиртә башлаган. Бүген мин аннан менә шушы хатны алдым. *(Куеныннан хат чыгара.)* Башладык, егетләр. Хат уку өчен сүз Әсхәткә бирелә. *(Хатны Әсхәткә биреп тахтага менеп утыра. Шоколад ашый-ашый әле бер, әле икенче егетне күзәтә.)*

Әсхәт *(укый)*. «Кичә Лондоннан кайтып төштем. Лондон зур шәһәр, ләкин диңгезчеләр аны яратмыйлар, чөнки Лондонда һәрвакыт диярлек томан була. Юл шактый мәшәкатьле булды. Лондон порты акваториясеннән чыгып китүгә көчле шквал башланды. Аннары йомшак норд-вест куәтле норд-ост белән алышынды һәм җиде-сигез баллы шторм кузгалды... Май бәйрәменә өч бүлмәле квартира алдым, Кырым күпере янында...».

Зөфәр. Кырым күпере янында?

Зөбәйдә. Әhe!

Зөфәр. Ләкин Ленинградта андый күпер юк!

Зөбәйдә. Ничек юк?

Зөфәр. Әйе, юк! Мәскәүдә ул Кырым күпере, ә Ленинградта андый күпер юк.

Зөбәйдә ни әйтергә дә белмичә кыбырсынып як-ягына карана.

Сөендек *(Зөбәйдәгә карап серле елмаеп куя да)*. Гафу итегез, Зөфәр, сез Ленинградта күптән булдыгызмы?

Зөфәр. Узган җәй. Быел да барам. Мин Ленинградны яхшы беләм!

Сөендек. Ә сез ишетмәдегезмени — күптән түгел генә Ленинградта яңа күпер суктылар. һәм аңа Кырым күпере дип исем бирделәр.

Зөфәр. Кайсы елгага?

Сөендек. Невага, әлбәттә.

Зөфәр. Невага? Кайсы җиргә?

Сөендек. Әә... өскәрәк. Өскәрәк!

Зөфәр. Бәлки мин ишетмәгәнмен...

Зөбәйдә *(роленә кереп)*. И, тормыштан артта каласың да, кешегә бәйләнәсең. Бүлдермә! Укы, Әсхәт!

Әсхәт *(укый)*. «...Кырым күпере янында. Кухня, кладовой, ванна бүлмәсе һәм... һәм башкалары».

Зөбәйдә *(егетләргә чертеж биреп)*. Менә монда квартираның схемасын да ясап җибәргән.

Әсхәт *(укый)*. «...Чикләвек агачыннан эшләнгән диван-кровать белән тахта, шундый ук шифоньер, сервант — комбайн һәм төрле почмак-

лы өстәл, язу өстәле белән кухня өстәле, уникe урындык, бер тирбәлә торган кресло — бусы синa, радиола «Фестиваль», холодильник «Орск», кер уа торган машина һәм пылесос алдым. Шушы арада китап стеллажлары белән секретер алырга җыенам. Көзге мәсьәләсе әле хәл ителмәгән. Син ничек уйлыйсың, трюмо алсам яхшы булырмы, әллә трельяжмы? Безнең белән илле яшьлек тутам торачак. (Өй эшләрен эшләр өчен.) Эти белән әни борынгы саксон фарфорыннан аш һәм чәй сервизы, шуңа кушып көмеш прибор бүләк итәчәк. (Егерме дүрт персоналык.) Туйда кәләшкә ас мехыннан тегелгән манто...»

Булат. Нәрсә мехыннан?

Зөбәйдә. Ас! Ас — горностай. Ишеткәнегез юкмыни — Николай патшаның шундый бер туны булган.

Әсхәт (*укый*). «Ас мехыннан тегелгән манто һәм алтын сәгать салырга уйлыйлар. Әнинең абыйсы (отставкадагы генерал) пианино «Рига», әнинең энесе — персидский ковер вәгъдә итә. Әтинең апасы — хрусталь люстра, әтинең энесе — телевизор «Рубин», апа белән жизни — фил сөягеннән ясалган нәфис шкатулка һәм энҗе муенса, Ташкенттагы кардәшебез — мамык юрган, авылдагы әби белән бабай — каз мамыгыннан дүрт мендәр салачак. Минем капитаным Көньяк Америкадан алып кайткан ике попугай бүләк итәчәк. (Көмеш читлеге белән.) Мин үзем сиңа туй күлмәге, Париж мастерлары эшләгән кадак үкчәле туфля (атаклы актриса Брижитт Бордо үзенең аяк киемнәрен шул фирмада эшләтә) һәм бриллиант кашлы алка бүләк итәргә уйлыйм. Моннан тыш Франциядән йөз бутылка шампанское, илле бутылка коньяк, бер мичкә утыз ел саклаган бургунд виносы алып кайттым. Шушы арада Америкадан ике йөз бутылка пепси-кола кайтып җитәчәк».

Булат (*көлә-көлә*). Шәп кияү, шайтан алгыры! (*Бүлмәсенә китә.*)

Әсхәт (*укый*). «...Ун килограмм кызыл икра, биш килограмм кара икра, өч килограмм...»

Зөбәйдә (*Булат киткән бүлмәгә карап тора да хатны тартып ала*). Кыскасы, егетләр, диңгезче өйләнергә тели. Мене шушы байлыкларга өстәп, миңа үзенең кулын һәм йөрәген тәкъдим итә. Һәм, анысы үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, хезмәт хакын. Өч йөз илле, дүрт йөз тирәсе. Нишлим икән, егетләр? Шушы егеткә кияүгә чыгыйм микән?

Зур пауза. Булат керә.

Сөендек (*хәйләкәр елмаеп*). Да!..

Булат. Кияү дисәң дә кияү!

Зөфәр. Овчаркасы гына юк!..

Зөбәйдә. Тсс! Ягез, кем нәрсә әйтергә тели, иптәшләр? (*Әсхәт кул күтәрә.*) Сүз Әсхәткә бирелә.

Әсхәт (*тотлыга-тотлыга*). Ә үзең, Зөбәйдә, яратасыңмы ул егетне?

Зөбәйдә. Ну, Әнәс миңа ошый. Ул озын буйлы, кара көдрә чәчле... Мыегы да бар!

Булат. Тәгаен бармы мыегы?

Зөбәйдә. Билләһи, бар!

Булат. Алайса чыгарга кирәк ул егеткә, Зөбәйдә. Менә әгәр мыегы булмаса — ул вакыт икенче эш. (*Бүлмәсенә китә.*)

Сөендек. Тәмәке тартамы?

Зөбәйдә. Заграничныйны гына!

Сөендек. Аракы эчәме?

Зөбәйдә. Чамасын белеп кенә!

Зөфәр (*мыскыллап*). Әйе, тәкъдимне кабул итмәсәң, никадәр байлыктан колак кагачаксың!

Булат (*бүлмәсеннән*). Һәм магазиндагы трельяж белән секретердан да!

З ө б ә й д ә *(Булат бүлмәсенә карап торганнан соң кинәт Зөфәргә)*. Ну, Зөфәр, китереп тә карыйсың ачуымны!

З ө ф ә р. Үземә үзем гаҗәпләнәм. Нәрсә өчен яраттым икән мин сине?!

З ө б ә й д ә. Зөфәр, сиңа сүз бирелмәде!

З ө ф ә р. Сиңа безнең фикер кирәк түгел бит. Син бит бу комедияне үзеңнең бәяңне күтәрү өчен генә уйныйсың. Янәсе, минем мена нинди егетләрем бар! Һәм без ни генә дисәк тә, син бу егеткә чыгачаксың. Ул синең кем булуыңны бик яхшы аңлаган. Хайван шикелле аша да эч, йокла һәм иреннең диңгез аръягындагы илләрдән бүләкләр алып кайтуын көт. Ә ул кайтканчы койрыгыңны теләсәң ничек болга...

Әсхәт чалт иттереп Зөфәрнең яңагына суга.

Б у л а т *(араларына кереп)*. Егетләр, егетләр!

З ө б ә й д ә *(тахтага сикереп менеп баса)*. Молодец, Әсхәт, син миңа ошыйсың!.. Берничә сүз әйтергә рөхсәт итегез, иптәшләр. Монда, иптәшләр, Зөфәр мине койрыклы хайван һәм мещанка дип мыскыл итте. Ләкин ул ялгыша, иптәшләр. Мин саксон фарфоры белән ас мехыннан тегелгән манто кебек әйберләргә алданучы арзанлы мещанка түгел. Мин аларга кызыкмыйм. Кыскасы, тантаналы рәвештә белдерәм, иптәшләр, Абдуллин Әнәснең тәкъдимен мин кире кагам!

З ө ф ә р. Шундый зур корбанның кем өчен һәм ни өчен икәнен дә әйтерсең, бәлки?

З ө б ә й д ә *(ачуыннан нишләргә белмичә)*. Ни өченме?.. *(Еларга җитеп бер Зөфәргә, бер Булатка карап торганнан соң.)* Ни өчен дисеңме? Чөнки аның машинасы юк — менә ни өчен!.. Ә хәзер — киңәшмә бетте, таралыгыз! *(Шап итеп тахтага утыра. Зөфәр кискен борылып чыгып китә. Сөендек Зөбәйдә янына килә.)*

С ө е н д е к. Бәлки бераз машинада йөреп керербез!

З ө б ә й д ә. Вон моннан! Бөтенегез дә вон! Вон! Вон!

Әсхәт, Славик һәм Сөендек бер-бер артлы чыгып китәләр. Зөбәйдә үкереп елый-елый тахтага каплана. Булат стакан белән су китерә.

Б у л а т. Салкын су эчегез.

З ө б ә й д ә. Эчмим!

Б у л а т. Мин сөткә кереп чыгам. Кәримә. Нияз уянса...

К ә р и м ә. Бир, үзем алып чыгам. *(Булатның шешәсен тартып ала да чыгып йөгерә. Пауза. Зөбәйдә ярсып-ярсып елый.)*

Б у л а т. Монда бик бөркү. Бәлки тәрәзәне ачу кирәктер?

З ө б ә й д ә *(үкси-үкси торып утыра)*. Миңа нәрсә кирәген мин үзем дә белмим... Нишләргә инде хәзер! Нишләргә инде хәзер?!

Б у л а т *(ирония белән)*. Егет шәп бит. Тәкъдимен кабул итәргә кирәк.

З ө б ә й д ә. Мин бит ул турыда түгел!

Б у л а т. Шулай да мин бер нәрсәне аңламыйм. Ни өчен сез егетләрне шулай мыскыл иттегез?

З ө б ә й д ә. Шул кирәк аларга!

Б у л а т. Үзеңне яратып йөргән кешедән көлү, минемчә, яхшы түгел.

З ө б ә й д ә. Ярату тагын! Беләсезме, алар ни өчен минем тирәдә йөриләр? Матур булганым өчен. Берсенең минем белән көймәдә йөрисе килә. Икенчесенең — машинада. Ә мин ничек яшим, нинди кайгым бар — анда аларның эшләре юк.

Б у л а т. Ә Әсхәт?

З ө б ә й д ә. Нәрсә — Әсхәт?

Б у л а т. Ул да яратмыймы?

З ө б ә й д ә. Малай гына ич ул!

Булат. Күрәсең, сез әле беркемне дә яратмыйсыз, Зөбәйдә.
Зөбәйдә. Белмим. Бәлки яратамдыр. Ничек була соң ул ярату? Сез үзегез бирәр кызны яратасызмы?
Булат. Яратам.
Зөбәйдә. Торырга өегез юк, ә үзегез... Нәрсә, йортка керәсезме?
Булат. Тиздән минем үз өем булачак.
Зөбәйдә. Бүлмә бирәләрме?
Булат. Бүлмә түгел, квартирам булачак минем. Мин чиратта торам.
Зөбәйдә. Туган апам әйтмешли, эрләмәгән, сукмаган — Шыгаем, сиңа ыштанлык! Яхшымы соң кызыгызның квартирасы?
Булат. Белмим.
Зөбәйдә. Ничек инде?
Булат. Шулай. Яратсаң, андый нәрсәләрне сорап тормыйсың бит аны.
Зөбәйдә. Соң, өйләренә кергәнегез бардыр бит инде!
Булат. Юк. Мин әле аның кайда торганын да белмим.
Зөбәйдә. Әй, бернинди кызыгыз юктыр әле, мактанасыз гына булыр. *(Пауза.)* Медсестра булып керер идем — эшен яратмыйм.
Булат. Ә, сез ул турыдамыни. Бәлки, безнең төзелешкә керерсез, Зөбәйдә?
Зөбәйдә. Кем булып?
Булат. Безгә анда төрле эшчеләр кирәк. Штукатурчылар да житешми, малярлар да аз. Штукатурчы булып керсәгез — үзегезне Кәримә өйрәтер. Ул безнең алдынгылардан санала.
Зөбәйдә. Юк, штукатурчы буласым килми. *(Уйлап торып.)* Ә мин обой ябыштыра беләм. Сезгә андый кешеләр кирәкме?
Булат. Андыйлар да кирәк.
Зөбәйдә. Ә эшкә керу өчен иң башта кем янына барырга? Начальникка булса — мин бармыйм.
Булат. Габдрахман абыйның катнашы юк монда. Кадрлар бүлегенә генә керәсез. Телисезме, иртәгә үзегезне үзем алып барам.
Зөбәйдә. Йөрергә ерак булачак.
Булат. Автобус йөри бит. *(Зөбәйдә тахтада аунап яткан хатны ерта башлый.)* Димәк, диңгезчегә отказ!
Зөбәйдә. Әнәскәме?
Булат. Әйе.
Зөбәйдә. Юк бит ул Әнәс!
Булат. Ничек — юк?!
Зөбәйдә. Шулай. Мин аны үзем уйлап чыгардым. Егетләрдән кәләр өчен!

*Пәрдә*

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук зал. Колясkада кычкырып бала елый. Җәүһәрия моңа игътибар итмичә көзге алдында бизәнә. Эш киемнәре кигән Зөбәйдә йөгереп керә.

Зөбәйдә. Нигә инде шуны елатасың? *(Колясканы селки башлый, бала елаудан туктый.)* Я, тәтием, елама. Әлли-бәлли! У тәтием, көлеп тә җибәрде! *(Баланы үбә башлый.)* Яле-яле, шушы җиренне үбеп алыйм әле. Үбәм! Егет кеше дип куркып тормыйм — үбәм. *(Үбеп.)* Уппа! И, туган апам, кайчан минем дә шундый бәбием булыр икән!..
Җәүһәрия. Без хәзер загска китәбез. Булат кайтканчы бала янында утыр.

Зөбәйдә (тәрәзәне ачып җибәрә дә тәрәзә төбенә менеп утыра). Әллә кайсы җирләре генә сөйкемле аның. Күзләреме шунда. Туган апам, син аның күзләренә игътибар иттеңме?

Җәүһәрия. Әллә тагын!

Зөбәйдә. Сөйкемлеме соң ул синеңчә?

Җәүһәрия. Сөйкемле шул! Мин бит сиңа әйтә киләм.

Зөбәйдә (хискә бирелеп). Һәм нинди олы йөрәкле! Туган апам, синеңчә ничек, матурмы ул?

Җәүһәрия. Ирләргә матурлык кирәкми. Миңа аның акылы булсын.

Зөбәйдә. Юк, матурлык та кирәк, туган апам. (Ояла-ояла). Туган апам, әйт әле, сиңа ошыймы ул?

Җәүһәрия (бизәнүен дәвам итеп). Ошамаса, мин аңа әйләнеп тә карамас идем.

Зөбәйдә (канатланып). Миңа да! Миңа да ошый, туган апам! (Тагын да ояла төшеп.) Туган апам, ә син ничек уйлыйсың, ул мине яратыр микән?

Җәүһәрия. Нигә яратмасын — яратыр.

Зөбәйдә. Ә башка берәр кызы булса?

Җәүһәрия. Кемнең? Син кем турында сөйлисең?

Зөбәйдә. Ә син кем турында?

Җәүһәрия. Сәмигулла җизнәң турында.

Зөбәйдә (кул селтәп). Әй!..

Әсхәт керә.

Әсхәт. Исәнмесез!

Зөбәйдә. Исәнме, Әсхәт, уз.

Җәүһәрия. Әйдә, утыр, Әсхәт. Мин Мәликә карчыкка кереп чыгам.

Зөбәйдә. Ник?

Җәүһәрия. Тормышыбыз бәхетле булсын дип бөтен корьән чыгарга кушкан идем. Садакасын кертәм.

Зөбәйдә. Туган апам, бир әле миңа ун сум акча?

Җәүһәрия. Шаштыңмы әллә син? Кайдан миндә шул кадәр акча булсын, эшләмәгән кешедә! Нишлисең шул кадәр акча белән?

Зөбәйдә. Кирәк иде. (Җәүһәрия чыга. Әсхәт Зөбәйдәгә картинкалар суза.) Ничә?

Әсхәт. Илле сигез генә... Син бүген эштән иртә кайткансың?

Зөбәйдә. Ха, апаң шул персональ машина белән генә йөри. Булат абыеның шофер икәнлеген оныттыңмыни?

Әсхәт. Ул бит самосвалда!

Зөбәйдә. Самосвалның кабинасы да була ич.

Әсхәт. Ничек соң, авыр түгелме?

Зөбәйдә. Бер дә авыр түгел. Барыбыз да минем кебек яшьләр. Эшлибез, шаярабыз. Тиздән бу йорт бетә. Беренче катта балалар библиотекасы булачак. Без бүген шуның уку залын обойлап бетердек. Шундый матур булды!

Әсхәт (чалбар балакларын тарткалап). Синең линейкаң бармы?

Зөбәйдә. Нигә ул сиңа?

Әсхәт. Менә тагын азрак чалбарны тарайткан идем. Манжетын да алып ташладым.

Зөбәйдә (шаркылдап көлеп тәрәзә төбенә менеп утыра). Ой, Әсхәт, син мине көлдереп үтерәсең!..

Әсхәт. Ә нәрсәгә кирәге бар аның, манжетның! Барыбер тузан гына җыела бит ана... (Пауза.) Әйдә, Бүрекле белән Күреклене очырабызмы?

Зөбәйдә. Икенче вакыт, Әсхәт, хәзер минем вакытым юк. *(Тәрәзә төбенә сузылып ятып тышка үрелә.)* Ой, бүген көн шундый матур! *(Арттан Шопенның до-диез минор экспромт фантазиясенең салмак өлеше ишетелә.)* Ой, Әсхәт, нинди матур музыка! *(Тыңлыйлар.)*

Әсхәт *(тәрәзәдән караган килеш)*. Әнә күрәсеңме, ничек моңаеп утыралар. Чөнки очар вакытлары житкән, мине көтәләр.

Зөбәйдә. Әгәр шуннан ояларына кире кайтмасалар? Очып әллә кая китсәләр?

Әсхәт. Китмиләр шул алар.

Зөбәйдә. Җүләр алар синең күгәрченнәрең! Мин булсаммы, әгәр канатларым булсамы — әллә кайларга очар идем! *(Пауза.)* Әсхәт! Әгәр кемне дә булса яратсаң, ничек була икән?

Әсхәт *(башын иеп)*. Аны сөйләп биреп булмый.

Зөбәйдә. Ничек инде?

Әсхәт. Әгәр кемне дә булса яратсаң, син әллә нишлисең. Үзгәрәсең. Сиңа бөтен дөнья әллә нишләгән булып күренә башлый...

Зөбәйдә. Нишләгән булып күренә?

Әсхәт. Әллә нишләгән, матурланган булып күренә. Син үзең дә үзгәрәсең...

Зөбәйдә *(тыпырчынып)*. Ой, Әсхәтчек, ничек үзгәрәсең? Сөйлә, сөйлә!

Әсхәт. Ну, әйтик, син нәрсәнедер яратмыйсың. Ну... ничек дип аңлатыйм инде сиңа... Ну, әйтик, берәү маркалар жыя. Син үзең жыймыйсың... бу эшкә көлеп карыйсың. Була бит шулай... Ә яратсаң!.. Ну, әйтик, синең яраткан кешең маркалар җыйса... Мин моны мисалга гына әйтәм...

Зөбәйдә. Шуннан! Шуннан, Әсхәт!..

Әсхәт. Һәм кинәт... син үзең дә маркалар жыя башлыйсың. Аңа китерәсең... Моны эшләү шундый күңелле!.. Мин моны мисалга гына сөйләдем, билгеле. Башка берәр нәрсәне дә шулай яратырга мөмкин...

Зөбәйдә *(Әсхәтне кочаклап ала да тәрәзә төбеннән шуып төшә)*. Ой, Әсхәт, мин яратам бит! *(Әсхәт авызын ачкан хәлдә нәрсә дияргә дә белмичә, булмә тирәли чабып йөргән Зөбәйдәгә карый.)* Мин яратам, Әсхәт! Мин дә ярата беләм икән, ой! *(Аякларын салындырып тәрәзә төбенә менеп ята.)* Ой, тышта нинди күңелле бүген! *(Тәрәзә төбеннән сикереп төшә.)* Мин яратам, Әсхәт!

Әсхәт *(шатлыгыннан нишләргә белмичә)*. Минеме?!

Зөбәйдә. Сине дә яратам, Әсхәт! Ой, кайдан бер ун сум акча табарга икән?!

Сәмигулла керә.

Сәмигулла. Хуҗалар өйдәме, керергә ярыймы? Саумы, кызым!

Зөбәйдә. Исәнмесез, бабай!

Сәмигулла. Матур апаң кайда?

Зөбәйдә. Ул хәзер керер, бабай. Утырыгыз.

Сәмигулла. Шулаймы. *(Утыра.)* Нигә беркөн карлыган җыярга килмәдең, шаян?

Җәүһәрия керә.

Әсхәт. Карап тор, хәзер күгәрченнәремне очырам! *(Чыга.)*

Сәмигулла *(кулларын сузып Җәүһәриягә каршы килә.)* Сөбханалла, бу модный күлмәкне кигәч фәрештә күк булгансың ләбаса! Кил әле, кил, кил. *(Җәүһәриянең кулыннан алып үзенә таба тарта.)*

Җәүһәрия *(качынып)*. Нихәл, Сәмигулла абый, исән-сау гына йөрисеңме? Утыр.

Зөбәйдә чыга.

Сәмигулла. Утырып та торсак, соңга калмабызмы соң?

Җәүһәрия. Бер дә күнелем тыныч түгел әле, Сәмигулла абый...

Сәмигулла. Кияү куенына керергә йөргәндә күңел тыныч була димени ул! *(Кеткелдәп көлеп.)* Әле менә үземнең дә... Менә, тотып кара әле йөрәгемне. *(Җәүһәриянең кулын йөрәге өстенә куйган булып кочаклап ала.)*

Җәүһәрия. Алла! Алла, кытыгымны китерәсең, Сәмигулла абый!.. *(Ычкынып китә дә йомшак кына итеп Сәмигулланың кулына суга.)* Әдәпсез!

Сәмигулла. Әйдә, киттек! Пашпыртыңны алдыңмы?

Җәүһәрия. Әллә ничек кенә, Сәмигулла абый.

Сәмигулла. Аһ алла, без бит эшне качып-посып эшләмибез, законный итеп эшлибез. Башта загска барып хөкүмәт каршында эшне беркетеп куябыз. Аннан ары, аллаһы теләсә, күчеп үк килерсең дә, алла каршында да эшебезне законный ясарбыз. Никах укытырбыз.

Җәүһәрия. Улларыңнан уңайсыз.

Сәмигулла. Һи, кызык кына икәнсең син, әкәмәт! Әллә кайларда зимагур булып йөргән малайларның миндә чуртым эше бармы? Солдаттан монда кайтырга уйласа, кечкенәсен дә кертмим әле мин аның. Абыйлары янына Сверлауга китсен. Икәүдән икәү гөлдерәп кенә яшәрбез, аллаһы теләсә! *(Зөбәйдә керә.)* Кара инде бу баланың чәчен! Акыл юк шул хәзер яшьләрдә, акыл юк...

Зөбәйдә. Акыл чәчтә түгел бит, бабай, башта.

Сәмигулла. Баштасын башта ул. Әмма ләкин менә шулай пумала баш булып йөрү акыл зәгыйфьлек галәмәте. *(Җәүһәриягә.)* Һәйбәтләп үргән чәч толымнарыннан да күркәм ни бар инде хатын-кызга!

Җәүһәрия *(толымнарын алдына чыгарып салып)*. И, хәзерге яшьләрдән син аны көтмә инде, Сәмигулла абый!

Зөбәйдә. Ә син пумала башлардан көлмә, бабай! Бил тиңентен толым үстереп йөргән хатыннар ни эшләделәр? Ирләренә аш пешереп торудан уза алмадылар.

Сәмигулла. Хатын-кызның эше шул инде аның!

Зөбәйдә. Ә хәзер әнә пумала башлы кызлар космоста очалар!

Сәмигулла. Кайда?

Зөбәйдә. Космоста дим, галәмдә! Озакламый Айга да менәчәкләр.

Сәмигулла. Иөрсеннәр инде. Шундый матур Айны китеп төшерерләр әле, имансызлар... *(Җәүһәриягә.)* Әйдә, киттек! Тукта, утырып бер дога кылып алыйк. *(Дога кыла. Җәүһәрия әдәпле генә итеп битен сыпыра.)* Амин тотмыйча бик зур хата эшлисең, кызым. Амин тоту үзең дога кылу кебек үк саваплы булыр дигән китап.

Зөбәйдә. Мин аллага ышанмыйм шул, бабай. Мин — комсомолка.

Сәмигулла. Заманасы шул булгач, комсомол да бул син, кызым, комунис та бул. Әмма ләкин алланы да абижайт итмә. Пушчай кеше алла юк, дисен, ә син эчеңнән генә булса да, бар, дип йөр. *(Кошелогыннан ун тиен акча чыгарып, әйләндерә-әйләндерә карый да, Зөбәйдәгә суза.)* Бисмиллаһи рәхман иррахим. Мә, кызым! Маруз алып ашарсың.

Зөбәйдә. Ун тиенгә бер генә мороженое килә бит, бабай. Анда да иң арзанлысы. Мин аның белән генә туймыйм.

Сәмигулла. Туярсың, бисмилланы әйтеп аша.

Зөбәйдә. И, бер мороженоега инде, бисмилла әйтү түгел, бөтен корьән чыксаң да туймыйсың, бабай.

Сәмигулла. Карале, кара. Кайдан килеп мин сиңа бабай булыйм! Жизни дип әйт, җүләр! Мә!

Зөбәйдә. Алай бик жизни дә булсаң, син миңа ун тиен бирмә, ун сум бир, бабай!

Сәмигулла. Кара, кара, кара! Күрәсенме бу елдагы яшьләрнең чаялыгын!

Зөбәйдә. Син курыкма, бабай, мин синнән бурычка гына сорыйм.

Сәмигулла. Әә. Шулай дисеңмени?

Зөбәйдә. Әйе, жизни. Зарплата алгач та түләрмен.

Сәмигулла. Түләрмен, дисеңмени? *(Кошелогын чыгара.)*

Зөбәйдә. Түлим, түлим. Үлеп кирәк иде бүген ун сум акча. *(Колагына.)* Концертка барабыз.

Сәмигулла. Шулаймыни... Алайса инде, кызым, син аны минем күк пенсе акчасына яшәгән карт-корыдан сорама. *(Кулындагы ун тиенне салып, кошелогын кесәгә яшерә.)* Жалунья алган кешедән сора. Атаңнан!

Зөбәйдә. Минем әти саран шул, бабай. Ул миңа акча бирми, бозыласың, ди.

Сәмигулла. Дөрес әйтә. Акча яшьләрне боза. Боза яшьләрне акча! *(Зөбәйдә чыга.)* Пашпыртыңны онытмадыңмы? Әйдә!

Җәүһәрия. Әллә азрак сабыр итик микән, Сәмигулла абый? Әти-әниләр белән киңәшим микән?

Сәмигулла. Киңәшеп торасы юк! Һич үкенмәссең, аллаһы теләсә. Пенсе акчасына яшим дигәч тә, әллә син... Әлхәмделиллаһи шөкер! Дварис хәтле йортым бар. Сад бакчасы. Кара карлыган сатып кына да өч йөз файда итәм быел. Шуның янына кыяры-суганы, башка чурт-чурамасы. Квартирант кызлар... Әлхәмделиллаһи шөкер, һәр жирем житеш. Малайлардан гына уңмадым. Аталарына ярдәм итмәс өчен читкә качып беттеләр.

Җәүһәрия. Син ул оятсызларны судка бирәсең бар, Сәмигулла абый. Алимент түләтәсең бар.

Сәмигулла. Хе, хе, хе. Сәмигулла абыеңны жүләр дип беләсең ахыры, син. Сәмигулла абыең законнарны бик яхшы белә. Яши белеп яшәсәң, сәвитски влач картларны абижайт итми. Әлхәмделиллаһи шөкер, бишесе дә алимит түләп тора. *(Кесәсеннән саклык кенәгәсе чыгарып, кулыннан ычкындырмый гына Җәүһәриягә күрсәтә.)* Менә монда карале! Хе, хе, хе! Күпме дигән, өч мең дә сигез йөз дигәнме? Яна акча белән бит бу!

Җәүһәрия *(күлмәк изүеннән саклык кенәгәсе алып кирәкле битен генә ача да).* Менә монда да яңа акча белән!

Сәмигулла *(кенәгәгә ябышып).* Сөбханалла! Дүрт мең!..

Җәүһәрия *(Сәмигулланың авызын кулы белән томалап).* Шулай булгач, синең карлыган саткан акчаңа кызыкмыйм мин, Сәмигулла абый.

Сәмигулла *(кызып).* Минем тагы бар! Акча бетсә дә бетми торган жирдә бар...

Җәүһәрия. Тсс!..

Зөбәйдә керә.

Сәмигулла. Әйдә, киттек! Пашпыртыңны онытмадыңмы?

Сәмигулла белән Җәүһәрия чыгалар. Зөбәйдә аларны тәрәзәдән елмаеп карап кала.

Зөбәйдә. Бүген көн шундый матур! Өйдә утырасы да килми. Әллә кайларга чыгып китеп, әллә ниләр эшләп йөрисе килә!.. *(Жырлый.)*

Без яңа йортлар салабыз
Казанның кырыенда,
Мин — маляр, ул самосвалда
Буяу китереп тора.
Самосвалын бушата да
Кул болгап китеп бара.

Кайтыр юлларына карап
Күз керфекләрем тала.

Фәрит керә.

Юл өсте булганга түгел,
Өзелеп яратканга,
Эш беткәч илтә өемә
Утыртып самосвалга.
Самосвал кабинасында
Утырып барулары!
Өемә кайтып житкәнче
Онытыла аруларым.

Фәрит *(ясалма көлеп)*. Ха, ха, ха! Әле кемендә «Москвич»ы булган егетне генә яратам, дип йөри идең. Инде казенный самосвал булса да ярыймы?

Зөбәйдә *(елмаеп Фәриткә карап ала да, дәвам итә)*.

Өйләнгәч дип, көтеп торсак —
Соңгарак калырбыз, ди.
Язылдым әле чиратка
«Москвич» алырбыз, ди.
Агыйдел камышлары,
Йөрәгем сагышлары,
Таратты сагышларымны
Самосвал тавышлары!..

Фәрит чыга. Габдрахман керә.

Габдрахман *(коры гына)*. Булат кайттымы?

Зөбәйдә. Юк әле. *(Коляска янына килгән Габдрахманны куып.)* Юмаган кулларың белән балага кагылма!

Габдрахман. Ярый, күп газапланасыгыз калмады. Бүген ул бездән китәчәк.

Зөбәйдә. Ничек — китәчәк?

Габдрахман. Әллә мин аны мәңге үз өемдә тотыйммы?

Зөбәйдә. Бала белән кая барсын ул?

Габдрахман. Анысы инде минем эш түгел...

Зөбәйдә чыга. Елый-елый Җәүһәрия керә.

Габдрахман. Нәрсә булды?

Җәүһәрия. Үлде!

Габдрахман. Кем үлде?!

Җәүһәрия. Загска барып житкәч, кулларыбызны куйгач, егылды да үлде. Алып киттеләр... машинага төяп...

Габдрахман. Язылышкач булдымы шул хәл?

Җәүһәрия. Башта кулымны мин куйдым. Аннары ул... Сәмигулла Искин дип язуы булды, егылып үлүе булды... *(Чыга.)*

Сәрия керә.

Сәрия. Исәнмесез!

Габдрахман *(каушап)*. Син килеп тә життеңмени... Мин Фәрит белән сөйләшә алмадым бит әле. Өйдә юк Фәрит, командировкада.

Фәрит керә. Ул шактый исерген. Бернирсәгә игътибар итмичә тахтага барып ята.

Габдрахман. Син командировкадан кайттыңмыни?

Фәрит. Син нәрсә — яртыны салып кайттыңмы әллә? Минем бер кая киткәнем юк.

Габдрахман. Син гафу ит, кызым. Мин аның белән сөйләшкән идем инде. Ләкин син артык бетерешмә...

Фәрит *(күзләрен Сәриягә текәп торып утыра. Габдрахманга.)* Кит шуннан! *(Габдрахман чыга. Фәрит чайкала-чайкала Сәрия янына*

*килә, кул суза.)* Исәнме! Тыңлама син ул карт дуракны. Килүең яхшы булды. Мин үзем синең янга жыена идем. Мин бит... Син минем соңгы хатны алдыңмы?

Сәрия. Сеңелегез язган хатнымы?

Фәрит. А, чепуха! Да, миндә яңалык бар. Мин институттан китәргә булдым. Мин аңладым. Агроном кешенең урыны авылда. Югары уңыш өчен көрәш барган жирдә.

Сәрия. Син мине элеккеге кебек бала акылы чыгып бетмәгән кыз дип уйлыйсың ахыры. Ләкин мин инде олыгайдым, Фәрит.

Фәрит. Берничә айда?!

Сәрия. Олыгаю яшь белән йөрми икән шул. Соңгы бер атнада мин үземне бик күп олы итеп сизә башладым.

Фәрит. Чепуха!

Сәрия. Мин әле генә институтыгызда булдым. Синең эштән куылуыңны мин беләм. Сәбәбен дә әйттеләр.

Фәрит. Алайса ник килдең?

Сәрия. Болай гына. Сина карыйсым килде.

Фәрит. Ну кара инде алайса, кара!

Сәрия. Синең эштән чыгарылуыңны ишеткәч, мин сине кызганган идем. Сине нахакка рәнжеткәннәр, аңламаганнар төсле тоелды. Һәм мин бөтен нәрсәгә күз йомып, сина кул сузарга теләгән идем. Кызганычка каршы, институтта сине дөрес аңлаганнар. Син иң соңгы чиккә кадәр алдашасың.

Зөбәйдә йөгереп керә, Сәрияне күреп кинәт туктап кала.

Фәрит. Слушай, төкер син институтка! Мин синең янга Буага кайтам. Матур итеп яшәрбез. Син бит мине яратасың. Яратасың бит син мине?

Зөбәйдә. Яратмый! Яратмый ул сине! *(Сәриягә.)* Шулай бит, яратмыйсыз бит?

Сәрия. Яратуын яратам мин сине. Ләкин бу ярату хата булган, Фәрит. Ә хатаны иртәме-соңмы төзәтү тиеш.

Зөбәйдә. Сез мине кичерегез, мин сезнең алда бик зур гаепле...

Сәрия. Сез шул бик яшь әле, сеңелем. *(Ишеккә таба бара.)*

Фәрит. Карале...

Сәрия. Карадым, күрдем.

Фәрит. Юк, мин дөрес әйтәм. Мин эшкә сезнең районга барам.

Сәрия. Рәхим ит, безнең районның кырлары киң!

Сәрия чыга. Габдрахман керә.

Габдрахман. Ул нәрсә, чынлап сөйлиме?

Фәрит. Нәрсәне?

Габдрахман. Эштән чыгару турында?

Зөбәйдә көлә-көлә телефонда номер жыя башлый

Габдрахман. Нигә шул кадәр авызыңны жәйдең, жүләр баш?

Зөбәйдә. Үзең гаепле! Акыллы итеп тудырырга хәлеңнән килмәгән.

Габдрахман *(өстәлгә сугып)*. Бу нинди оят белмәс кыз бу, ә? Үнжиде яшьтә ниләр генә белми!

Зөбәйдә *(искиткеч тыныч кыяфәт белән)*. Һо, андый нәрсәләрне мин инде күптән беләм. Әйтимме кайчаннан бирле? Әни бар вакытта мине кинога йөртә идең бит әле. Мине кинога кертеп жибәрә идең дә, үзең әллә кая китә идең. Соңыннан әнигә кинода икәү булдык дип әйтә идек...

Габдрахман. Житте!

Зөбәйдә. Берсендә мин кинога кермичә артыннан ияреп бардым. Җиде-сигез яшьлек бала бит — кызык...

Габдрахман (*Җәүһәриягә*). Ашатасыңмы, юкмы син мине бүген?!

Җәүһәрия белән икәүләп кухняга чыгалар.

Зөбәйдә (*Габдрахман артыннан кычкырып*). Ә мин барыбер күрдем! Мин карап тордым! Мин барысын да беләм! (*Фәриткә.*) Нигә шулай кайгыга баттың? Күңелеңне төшермә, сударь, нык бул! Шулай өйләнә алмый калсаң, картлык көннәрегезне туган апам белән үткәрерсез. Барырсыз авылга. Агроном дипломы булган кешегә авылда да эш табыла бит!..

Бала тавыш чыгарып куя. Зөбәйдә коляска янына килә. Фәрит чыга.

Уяндыңмы, тәтием! Нәрсә кирәк? Яле, үсик әле. Үсте, үсте, үсте — уппа! Менә нинди зур булып үсте, Нияз. Кил кулыма. (*Баланы кулына ала, үбә.*)

Кояш кебек йөзләре,
Шомырт кара күзләре,
Сары ефәк чәчләре,
Тик чыкмаган тешләре,
Бите әнис алмасы —
Бу кемнәрнең баласы?
Кемнеке? Безнеке!

Булат керә. Зөбәйдә баланы тиз-тиз коляскага сала. Булат бала белән кайнаша башлый.

Зөбәйдә (*тәрәзәгә килеп*). Бүген көн шундый матур! (*Пауза.*) Булат! Мексика балеты концертына барасыңмы?

Булат. Мексика балетына?

Зөбәйдә. Әйе.

Булат. Кайчан?

Зөбәйдә. Бүген барабыз, хәзер.

Булат. Син дә барасыңмы?

Зөбәйдә. Әһе, икәү барабыз. Бүген соңгы концерт! Күрмичә каласың!

Булат. Рәхмәт, Зөбәйдә. Мин бара алмыйм.

Фәрит керә. Булат белән Зөбәйдәне күреп тыңлап тора.

Зөбәйдә. Нишләп бара алмыйсың?

Булат. Вакытым юк.

Зөбәйдә. Минем белән барырга хурланасың, шулаймы? Минем чәчем дә кырыккан, тырнакларым да буяулы. Курыкма, бүген буямаган. Менә кара!

Булат. Кызык кына син, Зөбәйдә...

Зөбәйдә. Акланма, зинһар. Син бит мине җүләргә саныйсың. Чөнки мине бу өйдә бөтен кеше җүләр, ди.

Булат. Мин сине җүләргә санамыйм, Зөбәйдә...

Зөбәйдә. Алайса нигә бармыйсың?

Булат. Минем чыннан да вакытым юк. Бүген мин сездән китәргә тиеш. (*Чыга.*)

Зөбәйдә (*йөзен яшерү өчен читкә борыла.*) Ай, гел ничек кояшка тартылган!

Фәрит. Синең сюрприз чыкмый бит әле.

Зөбәйдә. Нишлим икән, абый? Әллә яратканлыгымны әйтимме икән?

Фәрит. Син нәрсә, чынлапмы?

Зөбәйдә. Эһе. Нишлим икән? Нишлим икән, абый?! *(Фәрит көлә.)* Мин бит синең белән чынлап сөйләшәм! *(Фәрит шаркылдап көлә.)* Көләргә хакың юк! Хакың юк синең көләргә!..

Фәрит. Җүләр син!

Зөбәйдә. Мена ничек! Мин сине абый дип йөрим тагын. Сине аңларга тырышып йөрим. Ниһаять, мин сине аңладым. Йөрәксез син! Синең беркайчан да ратканың юк. Синең һичкайчан яратачагың да юк! Беләсеңме, син кем? Син — ничтожество! Иң саф хисләремнән көлгәч, син миңа абый түгел. Минем абыем юк!.. *(Фәрит чыга. Булат керә.)*

Булат. Син мине гафу ит, Зөбәйдә. Теләсәң, без синең белән концертка икенче вакыт барырбыз.

Зөбәйдә. Кит, дип начальник әйттеме сиңа?

Булат. Юк, ул әле бу хакта әйтеп өлгермәде. Ләкин миңа хәзер үк китәргә кирәк. Габдрахман абый белән конфликт чыкты безнең.

Зөбәйдә. Нинди конфликт?

Булат. Синнән соң участокка Габдрахман абый килде. Балалар библиотекасы өчен эшләнгән помещениены җимереп квартира ясарга куша. Чертежлар да китергән.

Зөбәйдә. Бәлки ул хаклыдыр. Квартира кирәк кешеләр күп бит.

Булат. Анысы шулай ул. Ләкин бу бит тресттагы ниндидер шишка өчен! Йөз егерме метрлы библиотекадан махсус аның өчен квартира ясарга чамалыйлар.

Зөбәйдә. Нинди дуңгызлык!

Булат. Менә шул шул. Шуның өчен без, комсомол яшьләр, приказга буйсынмаска булдык. Җимермибез библиотеканы!

*Габдрахман керә.*

Габдрахман. Кайттыңмы син, герой!

Булат. Кайттым.

Габдрахман. Иптәшләрең битеңә төкергәндә мин сине яклап калдым. Торыр урының калмагач, мин сине үз өемә алып кайттым...

Булат. Болары өчен рәхмәт...

Габдрахман. Ә син бөтен бригаданы миңа каршы котырткансың. Син беләсеңме ул кеше кем? Яков Борисович бит ул, тресттан. Безнең бөтен эшебез шуңардан бәйле — син шуны аңлыйсыңмы, юкмы?

Булат. Юк. Без ул йортларны үзебезнең менә шушы кулларыбыз белән салабыз. Күпчелегебез общежитиеда тора. Кайсыларыбызның ул да юк. Шулай да сабыр итәбез, чиратыбыз җиткәнне көтәбез. Ә ниндидер Яков Борисовичка башкаларга ярагaн квартиралар гына ярамый. Аңа мәйданы өч квартира хәтле булган библиотека кирәк!

Габдрахман. Шәһәрдә шул кадәр йорт салдырып, күңеленә ошаганча квартира ясатып керергә хакы юкмыни аның!

Булат. Юк! Безнең комсомол яшьләр бригадасы бу эшне эшләмәячәк.

Габдрахман. Эшләмәсәгез — ялынучы да юк. Иртәгәдән объектка бишенче бригада күчә.

Булат. Без жалоба язачакбыз!

Габдрахман *(ирония белән)*. Кая язачаксыз? Тресткамы? Горисполкомгамы? Языгыз, яз.

Зөбәйдә. Жалобага мин дә кул куям!

Габдрахман. Безнең эшкә синең нинди катнашың бар!

Зөбәйдә. Турыдан-туры. Таныш булыгыз. Алдыгызда комсомол яшьләр бригадасының обой ябыштыручысы Зөбәйдә Сабитова.

Габдрахман. Син?!

Зөбәйдә. Әйе, мин. Дөрес, әлегә минем стажым биш кенә көнлек. Ләкин библиотеканың стеналарын мин дә обойлаштым. Мин дә жалобага кул куям.

Габдрахман. Куй, куй.

Мәрвәр керә.

Мәрвәр. Исәнмесез!.. Исәнмесез, иптәш начальник! *(Зөбәйдәгә.)* Акыллым, исәнме! *(Булатка.)* Нихәл!.. Мин Ниязны алырга килгән идем, Булат. Әә... ничек дип әйтеп әйтеп әйтим инде... Синең балаң түгел икән ул, Булат. *(Коляскага иелеп.)* Яле, сеңелем, алыйк әле Ниязны.

Булат. Кагылма балага.

Мәрвәр. Соң, җаныкам, Ниязның үз әтисе табылды.

Булат. Кайдан табылды ул?

Мәрвәр. Синең аны күргәнең юк, җаныкам. Син кергәндә ул читтә иде. *(Габдрахманга.)* Тырнак очы кадәр генә дә гаебе булмаса да биш елга төрмәгә утыртканнар иде Мөбарәгемне. Төнәген кайтып төште — амнистиягә эләккән. Китер, җаныкам, Ниязны!

Булат. Кагылма балага! Бала минеке!

Мәрвәр. Әй, синеке түгел лә инде! *(Балага үрелә.)*

Зөбәйдә. Нияз безнеке!

Мәрвәр. Күр әле, кайдан килеп сезнеке булсын ул?! Шаштыңмы әллә син!

Булат. Якын килмә балага. Бала минеке!

Мәрвәр. Син нәрсә, күз тегәп көтеп алган ирем белән арабызны бозмакчы буласыңмы? Бирәсеңме, юкмы баланы?

Булат. Бирмим!

Мәрвәр. Яхшы! Мин синең белән генә сөйләшә белермен. Кешенең газиз баласын тартып алырга берәү дә юл куймас сиңа! *(Чыга.)*

Булат тиз-тиз баланы төрә башлый.

Габдрахман. Син миңа әйт, наконец. Бу бала синекеме-түгелме?

Булат. Түгел!

Габдрахман. Алайса ник бирмисең?

Булат. Кем очрады аңа ыргытырга туп түгел бит ул. Ул бит — адәм баласы.

Габдрахман. Ыргыта бирсен — анда синең ни эшең бар!

Булат. Ничек эшем булмасын!.. *(Уйлап.)* Безнең авылда бер карт бар иде. Шуның бер сүзе хәтердә калган: адәм баласын адәм иткән дә — ата-ана, әрәм иткән дә ата-ана. Дөрес ул. Кемдер төрмәдән кайткан. Каракмы, бандитмы. Ярый ла ул төзәлеп кайтса. Шундый кешеләргә ничек бала бирәсең! Алар аны кем итеп үстермәсләр!

Габдрахман. Дурак! Нинди закон сиңа бала бирсен! Үз балаң булса да сиңа бирмиләр әле аны. Закон буенча бала һәрвакыт анада кала.

Булат. Әгәр ул ана баласына дөрес тәрбия бирерлек кеше булмаса дамы? Әгәр ул ана үзенең баласын туп шикелле типкәләп, бүген бер, иртәгә икенче кешегә ыргытып йөртсә дәме! Юк! Андый законның булуына мин ышанмыйм. Баласына карата шундый мөнәсәбәттә булган ана — ана түгел. Андый ата-аналарның ата-ана булу хокукларын алырга кирәк! *(Баланы төреп күтәрә.)*

Зөбәйдә *(аяныч тавыш белән)*. Булат!! *(Нишләргә белми бераз торган.)* Ә син аны арбасы белән алып кит! Ул мин үскән арба.

Булат. Рәхмәт. *(Баланы кире коляскага сала.)* Ярый, рәхмәт, Габдрахман абый. *(Җәүһәриягә.)* Сезгә дә рәхмәт, апа. *(Фәриткә.)* Сезгә дә. Мин сезне шактый борчыдым — гафу итегез. Зөбәйдә, сиңа да бик зур рәхмәт.

Габдрахман. Шулай да син минем киңәшне тот. Жалоба язып йөрмәгез. Ул шәһәр Советының ризалыгы белән эшләнә торган эш.

Б у л а т. Шәһәр Советыннан югары оешмалар да бар бит. *(Коляска751 этәреп ишеккә бара.)*

З ө б ә й д ә *(йөгереп килеп коляскага ябыша).* Мин дә синең белән, Булат!

Б у л а т. Бик ерак бит, Зөбәйдә. Кайтырга куркырсың.

З ө б ә й д ә. Ә мин кайтырга түгел! Бөтенләйгә!

Г а б д р а х м а н. Зөбәйдә!

З ө б ә й д ә. Калдырма мине, Булат, ал үзең белән! Мин син уйлаганча ук начар кыз түгел. Мин яратам сине!

Г а б д р а х м а н *(Зөбәйдәне аралап алып Фәриткә бирә).* И җүләр баш! *(Булатка.)* Ярый, бар, юлыңда бул!

Б у л а т. Гафу ит, Зөбәйдә. Син бик әйбәт кыз. Ләкин мин башканы яратам... Гафу ит... *(Ишек төбенә килеп җиткәч Фәриттән).* Абый, сез миңа Кәримәнең адресын бирә алмассызмы?

Ф ә р и т. Кәримәнең адресын? Минем аларга барганым юк. Зөбәйдә! Әйт шуңа Кәримәнең адресын!

З ө б ә й д ә *(елаудан чак кына тыелып).* Нәриман урамы, сиксән беренче йорт. Унбишенче квартира. Ишек алдына кергәч тә уң якта...

Б у л а т *(уңайсызланып).* Рәхмәт. Гафу итегез... *(Коляскаvы тартып чыгып китә. Артта мәче тавышы.)*

З ө б ә й д ә. Ачып чыгарыгыз әле шул мәчене, акырмасын!..

Ф ә р и т. Бәхетең юк синең, Зөбәйдә...

З ө б ә й д ә. Заткнись, пожалуйста! Беләсең килсә, мин үземнең бу бәхетсезлегемне синең миллион бәхетеңә дә алыштырмыйм әле.

Г а б д р а х м а н. Күр әле бу җүләрне! Берәүгә дә хөрмәт юк. Абыйсына да! Әтисенә дә!

З ө б ә й д ә. Әтисенә? Син минем әтиеммени?!

Г а б д р а х м а н. И җүләр баш!

З ө б ә й д ә. Алайса нигә син миңа бервакытта да кызым димисең?

Г а б д р а х м а н. Ә кем сине ашата, җүләр баш! Кем сине киендерә! *(Булмәсенә уза.)*

З ө б ә й д ә. Ашата, киендерә! Синең бар белгәнең шул гына да инде... Әнә гөлне күрәсеңме — гөл булып гөл кояшка үрелгән... Адәм баласы да шулай бит! Аңа да җылы, ягымлы сүз кирәк. Ашатам! Киендерәм! Ул гына җитәмени адәм баласына! Кайчак башыңны кемнеңдер күкрәгенә куеп, бер җылы сүз ишетәсе дә килә бит! Хәтта ул баш җүләр булса да!.. *(Гәрәзәгә килә.)*

Әсхәт керә.

Ә с х ә т *(Зөбәйдә янына узып ун сум акча суза).* Син ун сум акча эзләгән идең...

З ө б ә й д ә *(кинәт исенә килеп).* Кайдан алдың бу акчаны?

Ә с х ә т. Таптым.

З ө б ә й д ә. Кайдан таптың?

Ә с х ә т. Таптым инде.

З ө б ә й д ә. Әниеңнекен урлагансың, әшәке малай!

Ә с х ә т. Юк!

З ө б ә й д ә. Ә мин әйтәм, урлагансың!

Ә с х ә т. Юк! Юк!..

З ө б ә й д ә. Әйдәле әнием янына, карак малай! *(Елый-елый Әсхәтне ишеккә таба сөйри.)*

Ә с х ә т *(елый-елый).* Юк! Мин карак түгел! Юк! Бу акча минем үземнеке! Үземнеке!..

З ө б ә й д ә. Кайдан килде сиңа ун сум акча! Урлагансың! Урлагансың!

Ә с х ә т. Юк!.. *(Бераздан.)* Мин күгәрченнәремне саттым...

Пауза.

Зөбәйдә. Гафу ит, Әсхәт. Мин сине аңладым... Ләкин син күңеленне төшермә. Ярата һәм газаплана белү — ул инде зур эш, дустым. Ярату нәрсә икәнлеген дә белмәүче, таш йөрәкле кешеләр дә бар бит дөньяда. Син әле бик яшь, дустым. Син әле бәхетле булырсың!.. *(Тезләрен кочаклап тәрәзә төбенә менеп утыра.)*

Габдрахман керә.

Габдрахман. Кечкенә бәби кебек тәрәзә төбендә утырма инде. Үзең кияүгә чыгам, дисең!..

Зөбәйдә *(тәрәзә төбеннән төшә-төшә)*. Чыкмыйм мин кияүгә! Чыкмыйм! Чыкмыйм!.. *(Йөгерә-йөгерә чыгып китә. Артыннан Әсхәт бара.)*

*Пәрдә*

## *Халык мәзәкләре*

### ҮЧ

Бераүнең кызы күрше авылда кияүдә икән. Көннәрнең берендә кыз әтисе өенә кайткан да:

— Икенче самоварны эреткән өчен киявең яңагыма суга язды,— дип кычкырып елап җибәргән.

Бик ачуы килгән кебек иткән әти кеше:

— Ул минем кызны рәнҗеткән икән, үчне аның хатынынан алыйм әле,— дигән дә кызын яңаклап алган.

### ТЕЛ ӨСТЕ — ЮЛ ӨСТЕ

Ике кодагый чәй эчеп утыра, ди. Кунак кодагый балны каерып каба икән дә:

— Бигрәк тәмле, кодагый җаным. Авызга салу белән таралып китә,— дип мактый икән.

Кодагые «үзе туктый белер микән бу тәмле таман», дип көтеп торган-торган да ахыры түзмәгән:

— Кай җиреңә саласың син аны? — дип сораган.

— Тел өстенә салам, кодагый җаным. Тел өстенә.

— Бигрәк тә юл өсте шул,— дигән тегесе, көрсенеп.

### ӘМӘЛЕН ТАПКАН

Элек бер аүнең ике хатыны булган.

Бервакыт хатыннары аңардан:

— Син кайсыбызны күбрәк яратасың? — дип сораганнар.

— Икегезне дә бик яратам,— дигән ир кеше. Ләкин хатыннар моның белән генә канәгатьләнмәгәннәр:

— Әгәр су кергәндә икебез дә бата башласак, беренче булып кайсыбызны коткарыр идең? — дип бәйләнгәннәр.

Шул чак ир кеше картрак хатынына:

— Син үзең дә йөзә беләсең бит! — дигәнен сизми дә калган.

# *Рәдиф Гатауллин*



*Миңа 25 яшь. Уйласаң, тәп-төгәл чирек гасыр яшим; тормыш, җир, ә кайчак, хыялда, күк юлларында да йөрим икән. Башкортстанның Марс авылы — юлларымның башы, аннан Уфа һәм Казан, университет...*

*Язам да, укыйм да; мине дөнья әдәбияты кызыксындыра. «Табына торган аллам» — Тукай булса, «пәйгамбәр»ләрем күп: Пушкин, Гейне, Маяковский, Лорка, Такташ...*

*Мине туктаусыз эзләнүче, дөньяга гашыйк яшь кеше образы мавыктыра. «Лирик сөйләшүләр»ем шул образга бәйләнешле булулар инде.*

*Әйбәт шигырь язу авыр. Кайчак:*

...Әйт күңел! —
Бәхетме бу?
Шигырь юлларында
Сәйях булып уза яшь гомер,—

*дип тә куясың. Ләкин бу — болай гына. Чорыбызга лаек җырлар язсаң иде, дигән теләк өстенрәк, көчлерәк, әлбәттә.*

*Мин юлда әле...*

# Лирик сөйләшүләр

•

**О**чрашасы иде...
Арабызда яткан ераклыклар томанына
уч итеп, бер очрашасы иде.
Югалган дип уйланган,
юлы бүленеп торган
шатлыклар чыгында
керфекләрне чылатасы иде! —
Очрашасы иде!
Бәхетнең тик автобуста килгән,
баскычлардан йөгереп менгән,
ишекләрдән кергән
ситсы күлмәкле
гади кызын очратасы иде:
таңнар атканда,
кояш баеганда,
йолдыз кабынганда —
очрашасы иде!
Ялгыз калган топольләрне җанландырып,
тын ярларны шатландырып,
җилләр белән куышып,
җирне янгыратасы иде,
пәрдә япкан тәрәзәләрне
оялтасы иде.

Кемнәргәдер үч итеп,
кемнәрнедер үз итеп,
гайбәтләргә туры карый алган
күзләреңне очратасы иде. —
Очрашмау дигән сүзнең үзен дә онытырлык булып очрашасы,
тизрәк очрашасы иде!

## Безнең Одиссея

Без дә Одиссейләр —
егерменче гасыр кешеләре,
ерак сәяхәтләр сөючеләр,
яки аңа охшаш ирләр.
Хәйләкәрлек белән Трояны алган
һәм яндырган
сугышчы Одиссей түгел без;
Ә бәлки — ил гизүче,
өйгә кайтырга,
Итакага юл эзләүче
мәңгелек юлчы —
Одиссей без.
Очрый безгә дә давыл,
циклоплар,
күп куркынычлар күрәбез;
Зевс әмере белән түгел,
йөрәк һәм кыюлык белән
барысын да без җиңәбез.
Сиреналар очрый юлда,
йөзмә утраулар.
Әйләнешләр күп, ураулар;
без йөзәбез, ил гизәбез
Итаканы эзләп һаман.
Бер-бер көн кайтырбыз ана —
сөекле Пенелопаны
безне көтә белүе өчен
ирләрчә, кочып үбәрбез,
язмышны җиңеп көләрбез.
һәм гомерне
оныкларга
Одиссея итеп сөйләрбез.

●

— Үткәннәр белән араны өзәргә! —
дип, сүз бирдем
киләчәк көннәргә:
уйламаска —
бала чакны,
шатлык белән генә истә калган чакны.
Сагынмаска —
иң беренче шатлыкларны,
иң беренче сөйгән ярны.

Күз алдына китермәскә —
шул чактагы
иртә килгән һәм соң киткән язны, җәйне,
ялан аяклы сары бер малайны...
— Үткәннәр белән араны өзәргә! —
дип, ант итеп, имза куйдым
күңелемдәге ак дәфтәргә:
Имза куйган чакта
ана кара тамды,
каплап алды.
Вакыт һәм бетергеч табып,
бетерәсе бар шул караны;
аннан өзәм, сүзсез өзәм
үткәннәр белән араны!

●

— Елаганың күргәнем юк, димсең?
Ә нигә еларга миңа?!

Кояшлы көндә яңгыр сирәк ява.
Елгалар да башланганда
чишмә булып челтерәп ага,
суы болгана тик соңга таба!

Нигә еларга ди миңа?!
Иртәнге чык —
көмеш күлү ошый мина.

Мин тозлы суны яратмыйм.
Миңамы еларга?! —
Мин әлегә ул көйне белмәгән гитара.
Нинди дәртле минем җырым —
тыңлап кара!

●

*(Көньякка киткән кызга)*

— Сочиның матурлыгын син сөйләмә миңа...
Платаннар янында төшкән рәсемеңне күрдем.
Күзләреңдә
каеннарның зәңгәр шәүләсе иде.
Сагынгансың кебек.
Әйдә, хыялда үзебезнең урманнарда
йөреп килик?!
— Диңгез табигате турында еш язма миңа!
Никадәрле соклансаң да
чәчләреңне
Ык сулары үстергәнне онытма, яме?!
Чинарларга гашыйк булып,
хәтереңдә калдырма талларның,
көнләшмәсен,
боекмасын Ык гөләбе!
— Көньякларга чакырма син мине,
андагы бәхетең турында язма!
Мондагы көннәремә күш син
алтын апельсиннар төсен.

Карашында
көньяк жылылыгын ал да,
ашыгып кайт син...
туган якта
ал чәчәкләр тагын күзен ачсын язга!

•

— Мәхәббәттән башка берни белмисең син,
күрмисең син... —
шулай диләр. Юк, мин беләм.
Мәхәббәттән башка да мин күпне күрәм:
Гөл керфекләре тибрәнеп ни аңлата?
Сандугач ник жыр ярата? —
әйтеп бирәм.
Нәкъ Гейне күк мин йолдызлар телен беләм.
Җил искәндә, нәрсә сөйли,
яшь топольләр нәрсә көйли,
бәхет кайда күбрәк үсә,
кайгының ник көне бетә —
барысын беләм.
Мин тормышны бөек иткән көчне
Мәхәббәттә —
илгә, җиргә Мәхәббәттә күрәм.
Һәм, яшермим: күбрәк сөям.
Мине:
— Хисләреннән шашкан дисез,
әйеме?!
Берсүзем юк.
Мәхәббәтнең
Мәҗнүн премиясе
лауреаты исемен
бу ел миңа бирегез, яме?!

## Сеңелләр!

Сездә көннәр шулай матур булса,
абый,
бездә —
көнгә әйләнәчәк кояшлы иртә.
Йолдыз, аегыз турында да
күп ишеттек:
төн күге зур,
бар кешегә дә ул җитә.
Топольләрем шаулый, дисез,
сокланасыз:
безнең урамда да шул ук җилләр исә.
...Зур сер шикелле саклыйсыз сөю сүзен:
ә күрмисез —
безнең толымнар да тиздән
тезгә җитә.

## Чишмәгә килгән кыз

*(Рәсем)*

Менә
    баш очыннан гына җинел болыт үтте.
Күзләр тирән ачылып китте.
Иренгә бер тамчы янгыр,
керфекләргә Кояш төште.
Җил оялтты —
                    күлмәгеннән тартып китте.
Керфекләрдә яшь күренде,
                            аннан кипте.
Гадәттәгедән матуррак сайрап,
                            кошлар үтте.
Күрше малай ана карап, авызын ачкан,
чиләгендәге су агып бетте.
Чишмәнен дә түземе бетте.
Толымын тешләп, һаман уйда
                            утыра кыз.
чиләкләре сусаганны оныткан ул;
пышылдый тик:
— Бәхет килде... Сөям, сөям!
                        Вакыт җитте!

## Вьетнам турында уйлыйм

Төнбоеклы күл
                    һәм аккош мәхәббәте,
Шушы хакта язарга иде! —
ләкин,
    аккошнын яралануы турында
                            хәбәр килде.
Кояшлы көнне мактаган сөю җыры! —
һич өзлексез җырларга иде...
Ләкин,
    болытлар капладылар да көнне —
аяз көн көе өзелде.
...Вьетнам турында уйлыйм.
Лотос гөледәй гүзәл җирнен
                    ярасыннан аккан ал кан —
авторучкамнан да минем
                    тама сыман.

●

Ачуланып, тамырларын өзден —
гөлләрем үлмәде,
                    һаман да үсте, үрләде:
Син янымда иден.

Аяк астымнан
                    җирне тартып алдын;
Егылмадым.

Йолдызларга тотынып тордым:
Син янымда калдың.
Бүген бөтен нәрсәм үз урынында,
тыныч —
ләкин, бушлыкта йөзгән кебекмен —
бернәрсә дә күрмим,
тапмыйм:
Син — киттең.

## Рәхмәт, тормыш!

Күп нәрсәгә өйрәткәнсең, тормыш:
җырларга, еларга.
Югалганны эзләргә, табарга;
табылмаса, чыдарга...
Подлец булырга ләкин өйрәтмәдең.
Мәхәббәткә һәм нәфрәткә дә
син өйрәттең,
битараф булырга, ышанам,
өйрәтмәссең.
Әле юлда минем йөрәк;
Сораулар белән тулы күзләр —
әле табигатьтән серләр озак эзләр.
Әле карда, комда озак калыр эзләр.
Тик,
ышанам:
Әбүгалисина ачалмаган хакыйкатьне
уйга чумып эзләгәндә,
түземлелеккә дә мине өйрәтерсең.
Инде «таптым!» дип уйлаганда да —
кыйбламны һәм йолдызымны
күчерерсең дә,
ялгышымны күземә төртеп,
җанны тагын тетрәтерсең.
Барыбер...
рәхмәт сиңа, Тормыш!

●

Зур корабка — зур дәрья, ди.
Бу ярларны калдыр, Сөю.
Зур йөрәккә зур кайгы бар,
җиңел бәхеткә ышанма,
тын ярларны калдыр, Сөю!

Монда ташлар, салкын алар,
алар дәшми, җанлы түгел.
Өмет-чәчәк сула монда,
җавап-сөю көтмә, күңел!

Аңламаслар мине монда,
таш булырсың, йөрәк, син дә...
Бу ярларны калдыр, Сөю,
зур корабка — зур дәрья, ди.

Син киттеңме, сөю?
— Әйе... —
Яр буш хәзер, тып-тын тора.
Ачы итеп җил сызгыра,
ә зур йөрәктә — зур кайгы.

●

Хәерле иртә!
Капкагызны аччы, сеңелем!
Бакчагызны карыйм сезнең...
Алмагач чәчәкләренә —
синең бәхетең төсенә
карап сокланасым килә.
Капкагызны аччы, сеңелем!

Хәерле кич!
Бакчагыздан китәм, сеңелем!
Мин бернигә дә тимәдем.
Чәчәкләрне дә өзмәдем.
Бик ошады миңа бакча.
Ләкин
һәркем кереп йөрмәсә иде,
бикле торса иде капка.
Гөлләреңне сагынып синең,
Мин килермен, сау бул, сеңелем!

## Малайлар

Малайларның күбесен анекдотлар кызыктыра,
ә романнар түгел.
Малайларга — тыелган әйберләр күңеллерәк,
рөхсәт ителгәнгә тартмый күңел.
Малайларга олыларча булу кызык,
сөйләшүләр, киенү...
Трубка йөртү яшереп кенә,
хәтта сүгенү —
тәҗрибәле күренү.
Малайларга бөтен нәрсә ашыгыч кирәк —
салмак атлау —
кызыкмыни?!
Олы буын әнә — нинди кызу йөри,
һәрчак алда,
киләчәккә юллар сызып йөри.
Малайларны да бит тарта батырлыклар,
ерак юллар,
адаштырган утлар.
Малайларга тизрәк өлкән булу кызык.
Алар белми:
өлкәннәрнең үзләрендә,
күпләрендә
малай чакны сагыну яши:
тәвәккәл чак — малайлык юк!
Тик ирләргә артка таба чигенер юл юк.
Малайларга исә — барысы кызык...

## Яшьләр иҗаты

*Альберт Хәсәнов*

# ЯШЬ НАРАТЛАР

*Хикәя*

Урамның аргы очында тракторлар гөрелтесе ишетелгәндә, Нигъмәт абзый ишек алдында йорт эшләре караштырып йөри иде. Ул, торган саен якыная барган мотор гуләвен ишетмәскә тырышып, лапас астында яткан кул арбасына көчәнеп-көчәнеп тирес төяргә кереште. Тегермәнче Ганилар турысына җиткәч, тракторлар, нәкъ Нигъмәт абзый көткәнчә, унга борылдылар һәм аларның тавышы әкренләп ерагая барды.

— Шунда барышлары, дөмеккереләрнең, шунда. Ярты сәгать эчендә дөньясын астын өскә китерәчәкләр, — дип мыгырдады Нигъмәт абзый. Аннары арбага каерып-каерып тагын бер-ике сәнәк тирес салды. Тракторлар ул арада авыл каршындагы үрне күтәрелеп, олы юлга чыктылар. Алар, чыннан да, моннан әле биш-алты ел гына элек нарат утыртылган һәм хәзер ямь-яшел булып ерактан ук күренеп торган «Зур алан»га табан юл тоталар иде. Ниһаять, Нигъмәт абзый түзмәде, сәнәген көч белән тирес өстенә бәрде. Сәнәк әллә кирпеч, әллә тимер кисәгенә бәрелеп әче зыңгылдады һәм тирес эчендә бер тешен калдырып, читкә очты. Ләкин Нигъмәт абзыйда аның кайгысы түгел иде әле...

— Күрәләтә торып... Яклаучысыз калганмени алар, — дип, сөйләнә-сөйләнә тиз-тиз атлап өенә кереп китте. Минут та авышмагандыр, ул яңадан баскычта күренде. Тез өстенә генә салып, мылтыгының ике көпшәсен дә корды да ашыга-ашыга капкадан чыгып китте. Хуҗасының кискен хәрәкәтләрен баштан ук күзәтеп торган карт этәч: «Мондый вакытта хуҗаның күзенә чалынмавың яхшы», дип, читән аша гына күрше ишек алдына очты.

Нигъмәт абзый урамга чыгу белән тыкрыкка борылып, Лашман кизләвенә, аның аша турыдан гына урманга, наратлар утыртылган «Зур алан»га ашыкты.

...Алай өскә аварлык калын булмаса да, үзенә күрә бүресе кереп качарлык, төлке-куяны оя ясарлык куе чытырманлыклары, кып-кызыл булып җиләккә күмелгән түгәрәк аланнары булган Ташсу урманы Нигъмәт абзыйга үз алма бакчасы кебек үк якын һәм кадерле иде. Җәен булса җинел плащ алып, кышын булса кыска тунын киеп, эштән буш араларда көннәр буена биредә югалып йөрсә дә, кирәксезгә ул биредән бер генә яфрак та өзми, бер генә ботакны да сындырмый. Киресенчә, малай-шалайлар сындырган чикләвек куакларын, шомырт ботакларын да, туктап, хәсиятләп бәйләп, кояшка таба каратып куеп китә иде. Дөрес, заманында, яшь чагында, сунарчылык та итте, куян-төлкесен дә аткалады. Ә соңгы вакытта, урман тирәсендә кош-корт, җәнлекләр күзгә күренеп сирәгәя башлагач, мылтыгын да ул болай

гына, сылтау өчен генә асып йөрде. Кояш нурларына күмелгән урман ялнында дөньясын онытып балалары белән уйнап ятучы төлке-мазар туры килгәндә дә, Нигъмәт абзый үзен:

— Аннан башка да санаулы гына калып барган урман халкын карт башың белән инде син дә киметмә, — дип кисәтеп, тегеләргә бармак кына янап уза. Урман булгач, аның бүресе дә булырга тиеш. Кышкы озын төннәрдә улап, балаларны куркытырлык бүресе дә булмаса, ул урманның авыл уртасына бәрәмләп агач утыртып ясаган бакчадан ни аермасы бар?! Ә урман — зур, киң ул, колачлы ул дигән үз фәлсәфәсенә нигезләп, Нигъмәт абзый Ташсу урманының иң түрендә инде ничәмә еллар ялгызы гомер кичерүче карт бүрегә кул күтәрергә дә уңайсызлана.

— Ерткыч булуыңда синең гаебең шул кадәр генә. Сине табигать шулай яраткан инде, әйдә, көнеңне күрә бир, түлке бик азынма, — дип, ул бүре оясы янынннан да әйләнеп уза иде.

Кош-корт, урман-болыннарның, кыргый табигатьнең ышанычлы дусты Нигъмәт абзый шундый законнар белән яшәп яткан көннәрнең берсендә Ташсуга Әлмәттән нефть эзләүчеләр килделәр. Кемнән сорыйлардыр да, кайсы таш йөрәклесе рөхсәт бирә торгандыр, алары Нигъмәт абзыйга билгесез. Әмма нефтьчеләр тракторлары белән шаулап үсеп утырган урманны шатырдатып ертып керәләр дә, кылт бер урта жиренә туктап, бораулларга керешәләр. Ул да булмый, әлеге аланның астын-өскә китереп, тәмам мәсхәрәләп ыргыталар да, китеп тә баралар. Дөрес, Нигъмәт абзый нефтьнең алтын кебек кадерле икәнен дә бик яхшы аңлый. Әле фронтта чагында ук үзенең туган якларында нефть чыга башлау турындагы беренче хәбәрләрне ишетеп, башкалар белән бергә бүреген һавага чөеп шатланды. Әлеге шушы нефть булмаса, күктә самолетлар очмасын, иген кырларында комбайннар йөри алмасын теләсә кемгә үзе аңлатып бирә ала. Тик менә бер байлыкны юк итеп, икенчесен булдыру исәбен башына сыйдыра алмый ул. Әлеге нефтьчеләр ташлап киткәннән соң, бөтенләй тынып, кызганыч хәлдә калган аланга, тамырларын өскә күтәреп яткан яшь имәннәргә, каеннарга, наратларга карап, Нигъмәт абзый ни дип әйтергә дә аптырап озак вакытлар сүзсез тора-тора да, ахырда: «Шушы збирләрнең берәрсе үземә туры килмәсме әле, тотып яңакларын ярып идем», дип үзен юатып куя иде...

Урман алдында яңгыраган мотор тавышлары Нигъмәт абзыйның уйларын бүгенге сәгатькә кайтарды. Ул адымнарын тагын да тизләтә төште.

— Бер генә адым атлап карасыннар, ике дә уйлап тормыйча, чәнчелдерәм дә жибәрәм. Әмма посадка өстенә берсен дә аяк бастырмыйм, — дип, мылтыгын кысып тоткан хәлдә, ул инде тездән югары булып килүче наратлар үсеп утырган зур урман аланына килеп чыкты.

Абзыйның шикләнүе рас булды. Ул хәл алырга да өлгермәде, аның артыннан бастырып, аланга тракторлар да килеп керделәр. Нигъмәт абзый аларны ызан башында каршылады. Тракторлар белән ара ике-өч дилбегә бүе калгач, ул йөгереп алга чыкты һәм мылтыгын изи-изи: «Борылыгыз! Хәзер үк кире борылыгыз!» — дип кычкырып жибәрде. Абзыйның нәрсә әйтүен аңламасалар да, егетләр берсе артыннан берсе тракторларын туктаттылар һәм кабинадан башларын тышкы якка суздылар, кайберләре жиргә сикерделәр.

— Туктарга димәдем, барыгызга да кире борылырга куштым, — диде Нигъмәт абзый, кырыс кына тавыш белән.

Егетләр дәшмәделәр. Башта бер-берсенә карашкан булдылар, сүзсез генә елмаештылар. Берсе кесәсеннән көзге чыгарып, комбинезон якасын рәтләгән булды. Янәсе, алда мылтык тотып баскан Нигъмәт абзый алар өчен вак мәсьәлә иде.

Тракторчылар исеменнән сүзне алдагы машинада килүче Илһам башлады.

— Кем дип торабыз. Нигъмәт абзый, син икәнсең. Син, нәрсә, безнең юлга алай каршы төшәсең әле, — диде.

— Нигә төшмәскә. Бишек балаларыдай шушы яшь наратларны күрәләтә торып сездән таптатып торыйммени? Ю-у-к, уйламагыз да. Посадка өстенә берегезне дә аяк атлатмыйм. Яхшы чакта кире борылыгыз!

Абзыйның бу сүзләреннән соң, егетләр яңадан бер-берләренә карашып алган булдылар, сүзсез елмаештылар, күз кысышып алдылар. Иптәшләре исеменнән сүзгә тагын Илһам керешге:

— Нигъмәт абзый, сатулашып торырга вакытыбыз юк. Кыскасы, бу урында тиздән буровой булачак. Без менә шушы аланны чистартырга, буровойга урын әзерләргә килдек, — диде.

Нигъмәт абзый бу тәкәббер егетнең кыланышларында, һәр сүзендә эрелек, үзе эшләячәк вәхшилеккә бернинди дә җаваплылык сизмәвен тойды. Ул ташып кабарган ачуын тота алмыйча:

— Чистартырга, имеш. Сөйләшүен кара син бу малакасусның, атасы каберен актарырга әзер, — диде, һәм аннары: — Ә миңа дисә, буровой түгел чурт булсын, әмма посадка өстенә керүне өмет тә итмәгез, — дип өстәде.

Нигъмәт абзыйның бу сүзләрен егетләр уенга алыштырып, шаяруга күчереп җибәрмәкче булдылар.

— Абзый кеше, син монда юкка бака боты кыстырып йөрисең, алачыгыңа кайтып, тире җыючы Һадиның сукыр атын дагалый торсаң, файдалырак булыр иде, коры көнне дә кибет алды үрен менә алмый ди, шуңа күрә Һади баш төзәтергә гел җәяү йөри ди, — дип көлешә-көлешә, кире кабиналарына кереп утыраша башладылар. Ә Илһам бераз елмаеп:

— Ул вакытта, Нигъмәт абзый, үпкәләштән түгел, аланга сине таптатып үтәргә туры килә, — дип тракторын урыныннан кузгатты. Ләкин шул вакытта Нигъмәт абзый мылтыгын югары чөеп, гөрселдәтеп атып җибәрде. Мылтык тавышы урман өстеннән кире кайтып яңгырарга да өлгермәде, Нигъмәт абзый йөгереп барып, егетне якасыннан эләктерде. Һәм бер йолкуда аны өстерәп җиргә төшерде. Урынсызрак шаяруны аңлап та бетермәгән егетне җилтерәтеп:

— Салмак Сабир малае, малакасус, син, молчайт еще миңа каршы. Мин өченче сугышны тәмамлап култык таягына таянып кайтканда, әле урам буйлап ыштансыз чаба идең. Хәзер үстең, егет булдыңмени? Молчайт еще миңа каршы, — дип зәһәрләнеп, егеткә авыз ачарга да ирек бирми, орыша башлады. Үзе Илһамны орыша, ә үзе як-ягына каранып, башкаларга да мылтыгы белән яный. Әгәр дә мәгәр, берәрегез батыраеп, мине санга санамый посадка өстенә атласын, бүрегә корылган ядрәләр белән тиле башларыгызны чүлмәк итәм, дип кисәтә. Бу, кызу кан белән бер-бер хәвеф-хәтәр эшләп, безгә җавап бирергә туры килмәгәе дип, шиккә калган егетләр берәм-берәм тагын кабиналарыннан җиргә сикерә башладылар. Аларның кайберләре сырган бишмәтләрен асларына җәеп, җиргә яттылар, ә кайберләре бер-бер эш тапкан булып, тракторлары тирәсендә кайнашырга керештеләр. Абзый кулыннан ычкынган Илһам да: «Һәй, безгә барыбер ич, түлке начальство килгәч, җавабын үзегез бирерсез», дип сөйләнә-сөйләнә иптәшләре янына килеп чүгәләде.

Арттагы тракторга утырып йөрүче «бөтерчек» кушаматлы бәләкәй малайны мондагы хәлне сөйләп бирергә дип авылга йөгерттеләр.

Ә Нигъмәт абзый кире үз посадкасына чигенде. Үзе кәкрәеп, кыйшаеп утырган агач башларын рәтләп, турайтып куя, ә үзе эченнән: «Кызыбрак киттем, ахры. Салмак Сабир малаен юкка якаладым. Олы кешегә болай килешми иде, дип үзен шелтәли һәм шул ук вакытта:

«Хәер, шулай итмәсән, разе аларны туктата аласың? Авыз ачып торсаң, аланның астын өскә китереп куйган булырлар иде әле», дип аклана да иде. Ә тракторчы егетләр хәзер шаян сүзләр дә әйтешмиләр, сөйләшмиләр дә. Егетләр аны тыныч кына күзәткән хәлдә, дәшми-тынмый гына тәмәке көйрәтәләр.

Аларга озак көтәргә туры килмәде. Урман юлында мотоциклга атланган авыл Советы председателе Закир күренде.

Председатель тимерче Нигъмәт абзый характерын күптәннән белә иде инде. Шуңа күрә дә ул сүзен җайлап, җил уңаеннан гына башлап җибәрде.

— Абзый кеше, син егетләргә каршы төшмә инде. Наратлар миңа да җәл, әмма берни эшләп булмый, порядогы шул. Кыскасы, абзый кеше, анысы синең эшең түгел, үзебез сөйләштек, үзебез килештек. Агачлары әрәм булса була, әмма конторлары акчасын бише белән түли...

— Төкерәм мин аларның акчаларына, — диде Нигъмәт абзый председательгә сүзен әйтеп бетерергә дә ирек бирмичә һәм аяк астына төкереп тә куйды. — Сельсовит башың белән, Закир энем, син дә юк сүз сөйлисең. Куандырдың! Акчасын түлиләр, имеш. Ә мин аларны алтынга алыштырмыйм. Бу бит байлык!

Председатель килгәч, җан кергән тракторчы егетләр дә телгә килделәр. Абзыйны алар үзләренчә үгетли башладылар.

— Абзый кеше, биредә күп булса, бер-ике гектар чамасы посадка бозылыр. Ләкин бу урында яңа скважина булачак. Күп тә үтмәс, ул нефть бирә башлар. Ә бу скважинадан чыккан нефть, ягулык булараж, шушындый ук меңнәрчә наратларны, чыршыларны саклап калачак, — диделәр егетләр.

— Сез, малакасуслар, молчайт еще миңа каршы, — дип Нигъмәт абзый аларны да туктатты. Әйттем ич, төкерәм мин сезнең нефтегезгә. Шул нефте дия-дия судан балыкны, урман-күлдән кош-кортны качырып бетердегез. Урманнарыбыздан җәнлекләр кача, күлләребезгә очар кошлар утырмый. Табигатьнең яме калмады. Бөтен әйләнә-тирәне сасы мазутка батырдыгыз. Төкерәм мин сезнең нефтегезгә, дип Нигъмәт абзый сүзен кырт кисеп куйды. Аптырашып, абзыйга каршы ни дип әйтергә белми торган егетләргә карап алды да: «Бик кулыгыз кычытып тора икән, әнә, буш аланнар да җитәрлек, шунда котырыныгыз», — дип өстәде. «Алай булмый бит ул, Нигъмәт абзый. Бу аланны геологлар сайлап билгеләгән. Ә алар җирнең кайсы урыныннан бораударга икәнен синнән-миннән яхшы беләләр», диештеләр егетләр.

— Фән кушканча эш итәләр, — диде Илһам, кулы белән ишарәләп.

— Һай, фән-наука дип сез миңа юкны сөйләмәгез. Беләм мин ул сезнең дүрт күзле геолог-миолог дигән карачкыгызны. Моннан атна-ун көн элек нәкъ менә шушы аланда кайнаша иде. Күңелем шул вакытта ук сизенгән иде, ә менә посадка өстеннән җилтерәтеп чыгарырга башыма да килмәгән, — диде һәм аннары: «Һай, шуның сүзенә ышанып, җир бозуларын әйтер идем», дип, ниһаять, бераз юашланып, ак таза тешләрен күрсәтеп, көлеп җибәрде. Кесәсеннән янчыгын алып, тәмәке төрә башлады.

— Моңлыбаш! Сираҗиларның да мунчаларын сүттереп, шуның урыгына бораулаган иделәр бит. Янәсе, шул дүрткүзле карачкыгызның әйтүенчә, нефтенең иң күп урыны шул мунча астында икән. Дөбер-шатыр йөргәннәренә күрә чыктымы соң эшләре? Чыкмады, билгеле. Бер дигән ак мунча урынына тимер-томыр өемнәре калдырып киттеләр, шул булды. Хәзер мунча да юк, нефте дә тәтемәде.

Төп мәсьәләдән читләшә баруын үзе үк сизеп алып, Нигъмәт абзый сөйләвеннән шып туктады, тәмәкесен кабызмыйча да җиргә ташлады. Иңбашына аскан мылтыгын кире алды.

— Кыскасы, шул, посадка өстенә берегезне дә аяк бастырмыйм! — Нигъмәт абзый сүзен куәтләү өчен, мылтык көпшәсен ачып, аннан бүрегә корылган ядрәле пуляны алды да, аны да уч төбендә әйләндергәләп һәм яхшылап сөртеп, кире урынына салды.

Тимерченең әйткән сүзеннән бер карыш чигенмәячәген председатель Закир элек-электән белә иде. Бу юлы да бер эш чыкмаслыгы көн кебек ачык иде. Абзыйны санга сукмый, яланга егетләрне кертсәң, ышанма, атып та җибәрер, бәласеннән башаяк. Ә олы кеше белән тарткалашып, аның кулыннан мылтыгын тартып алу тагын күңелле эш түгел, дип уйлады ул. Җитмәсә, халык та аның ягында, абзыйныкы дөрес. Туган як табигатен шулай вәхшиләрчә тракторлардан җимертүгә, таптауга ул үзе дә эченнән сыкрана, сызлана иде. Ә хәзер, абзыйның сүзендә нык торуына да шатланып: «Һәй, Нигъмәт абзый, синең белән килешми буламы соң?» дип, кулын гына селтәде дә, мотоциклына атланып, китеп барды. Көннең бушка узуына ачулары килгән механизатор егетләр: «Кара син бу картлачны, бөтен урманга хуҗа булган. Каравылчы-мазар, я исә урманчы булса, тагын бер хәер. Урманга бер катнашы булмаган килеш тыгыла, баш була бит, алачыгында тимерләре белән җенләнеп ята да килеп бездән ачуын ала», дип мыгырдана-мыгырдана председатель артыннан тракторларын авылга таба бордылар.

Ә икенче көнне иртән кояш та чыкмаган иде әле, «Зур алан»га бернichә машина төялеп авыл яшьләре килеп керделәр. Алар аландагы һәр наратны төпләп-төпләп, машиналарга төйи башладылар. Алар белән бергә эшләүче Нигъмәт абзый соңгы төп яшь нарат үсентесен машинага күчергәч, мылтыгын югары күтәреп, тагын бер атып җибәрде. Монысы инде тракторларга урманга керергә рөхсәт сигналы иде.

---

## *Халык мәзәкләре*

### ШАЯН БАБАЙ

Хатын-кызлар кырда чүмәлә куялар икән. Алар белән бик шаян бер бабай да эшли икән. Шул бабай бер кызга әйткән:

— Кара әле, кызым, юл буйлап куян чаба түгелме?

— Юк, бабай, бернәрсә дә күренми.

— Алайса, кызым, чүмәләң өстенә менеп кара, бәлки шуннан күрерсең.

Кыз чүмәлә өстенә менгән икән, чүмәлә бөтенләй җиргә сеңгән. Кыз эшне аңлаган да чүмәләсен яңадан куя башлаган.

### ӨЧ ШИНЕЛЬ

Элекке заманда солдаттагы бер егет авылга ата-аналарына хат язган. Хатын болай дип тәмамлаган: «Минем өчен борчылмагыз: минем аста да шинель, өстә дә шинель, баш астында да шинель». Хатта язылганнарны үзенчә аңлаган анасы җавабында: «Бер шинелеңне безгә дә җибәрсәңче. Тезәттереп, чикмән итеп кияр идең», — дип язган ди.

## Б. Хәлимов



*Борис Хәлимовка 24 яшь. Ул хәзер Казан университетының журналистлар әзерләү факультетында укый. Моңа кадәр ул Башкортстанның Миәкә тугайларында печән җыеп, чүмәләләр куйган, Октябрьск каласында техник училище бетергәч, калмык далаларында нефть эзләүдә катнашкан; аннан соң ике елдан артык Совет Армиясендә хезмәт иткән. Шигырь язу өчен каләм тоту хокукына Хәлимов әнә шулай ирешкән. Кешеләргә әйтер сүзе башта аның күңелендә, шуннан соң гына теленә килгән.*

*Б. Хәлимовның шигырьләре җир сулышы белән сугарылганнар. Мондый шигырьләр хезмәтнең, мәхәббәтнең, тормышның кадерен белгән кеше йөрәгендә генә туарга мөмкин. Яшь шагыйрьнең әсәрләре шигырь сөючеләргә, ягъни матурлык сөючеләргә, ләззәтле минутлар китерер дип ышанам.*

МОСТАЙ КӘРИМ.

### Кереш сүз

Сүзләрем минем
Челтер-челтер аккан
Шарлама[1] чуерташлары булып
Ялтырасын иде,
Сүзләрем минем
Корычларда чыңлап
Яңгырасын иде.
Сүзләрем минем
Илем ындырларындагы
Кешелләргә аккан бодай булып
Шылтырасын иде.
Сүзләрем минем
Курай моңы булып
Халкым күңелен
Иркәләсен иде,
Сүзләрем минем
Өязе[2] елга камышлары кебек
Җилләр кочагында
Дулкынлансын иде.
Шигырьләрем минем —
Йөрәк тамырларыннан сызылып чыккан
Сабыйларым минем,
Комлыкларга очыгыз,
Иреннәрен чылатырга су тапмаган юлчы
Җырларымның зәңгәр чыгын эчсен.
Баррикадаларга очыгыз.
Революция көрәшчеләренә ак яулык болгап
Диңгезләр кичегез.
Алга, яктылыкка!
Сүзләрем минем,
Курыкмагыз!
Әгәр мин көрәшче икән, сез — минем коралым.

---

[1] Шарлама — Башкортстандагы кечкенә елга.
[2] Өязе — көньяк Башкортстандагы елга исеме.

## Таң букеты

Сыек томан зәңгәр ситсы булып
Иңен салган инеш ярына.
Чәчәк аткан шомырт дулкыннары
Шул ярларга барып сарыла.

Салкын чыклар чәчәк керфегендә.
Монда изрәп йоклый табигать.
Хәерле көн, дуслар!
Алдыгызда —
Сезне сагынып килгән бер солдат!

Сихри тынлык.
Без яраткан тынлык.
Бай да икән нурга бу һава!
Җил дә исми...
Нинди гүзәл тынлык!
Сары томан булып бал ява.

Күпме язлар,
Кояш нурын сагынып,
Таңда күзегезне ачканда,
О юк, болыннарда
Шартлау ташкын булып ташканда
Еллар сезне кырыс хөкем итте...

Яз чәчәксез икән — җир елый!
Дары исе дөнья агулый.
Чәчәкләргә иртән — бал ява.
Кайда дары — шунда кан ага.

Гөрлә инеш, гөрлә!
Җырың — матур.
Нинди зур булмасын бомбалар —
Кояш көнчыгыштан китек чыкмас,
Кайта-китә торыр торналар...

...Жигулидан кояш күзен кыса...
Хуш ис аңкып торган букетны
Походларда кырык михнәт күргән
Котелокка кертеп утырттым.

## Мәхәббәтем турында монолог

1

Хәтереңдәме, кайнар иреннәреңнән синең
Беренче тапкыр үпкән идем?
Син шунда ук, шырпыдай чатнап,
Төн зәңгәрлегенә йөгереп кереп киткән идең?
Ә ак яулыгың
Иңеңнән очты да
Һавада бөтерелеп-бөтерелеп,
Капланды җиргә —
Теләп ак бәхет...
Өязе елгам, дулкыннарың шаһит.

2

Хәтереңдәме, тынлыкта йөзгән тауларга бәрелеп
Өч тапкыр кабатланды безнең аһәң:
«Мәңге бер-гә-ә-әү... әү... әү...»

Кинәт бит алмаларың бәрхетендә эз калдырып
Ике терекөмеш тамчысы тәгәрәде җиргә...
Куллар кулны кысты.
Кичләр кавыштырды,
Ә таңнарда,
Таңнарда булды
Мәхәббәтебезнең урак өсте...

3

Ай нуры өстендә коенып тауларга ташландык.
Бу — сөттәй пакь йөрәкләребезнең бәйрәме иде.
Ә күкнең зәңгәр җәймәсенә сибелгән йолдыз гаиләләре
Безнең өметләребезнең ачкычлары бәйләме иде.
Сайрадылар кошлар
Кунып иңебезгә...
Карт таулар уйнады курайда
Икебезгә, тик икебезгә!

4

Кулларыбыз белән ишә-ишә йөздек сөт диңгезендә —
Чалкан туган ап-ак ай иде безнең көймә...
Сузылган идем көймәдән
Өзеп бирим дип бер тәлгәш йолдызлар миләшен
Бушлыкта пышылдадың миңа:
«Торсыннар... тимә...»

5

Җәяүләп авылдан чыкканда үпкәләп калдың.
«Сине миннән башка кем саклар,
үзең белән алмыйсың», — дидең.
Илләр гиздем.
Яшь йөрәкләр Союзы биргән адрес белән мин
Җир кабыгын ярып
Факеллар кабыздым,
Саллар агыздым.

6

Вулкан идем.
Күкрәгемнән чыккан кайнар лава белән
Байтак кына хаталар да күккә чөйдем...
Ә соңыннан — нишлим? — ташка башымны бәрә-бәрә
Җирем күкрәгендә үкси идем...
Тормыш мине чакма ташы итте.
Ут кирәксә — кабынам.

7

Авырайган миемнең һәр күзәнәге — өлгергән йөзем.
Чакыру сигналларымны ишетеп тә хәбәрең булмаса,
Күк зәңгәрлегән танымыйм якты күзем.
Чәчләреңне сагынам.
Толымнарың — төнге су юлы!
Хуш исле ул — яңа чапкан солы...

8

Ал минем мәхәббәтемне.
Яшьлегем күгенең ал болыннарында озак гизгәннән соң
Ул үзенең корылмасын яшеннәргә бушатты.
Җылы яңгыр булып яуды ярмалы туфракка,
Гәрәбәдәй орлыкларны иркәләп уятты.
Шатлыгым атланган ак атымны
Беркемгә дә бирмәм.

9

Ташлап качса аты яуларда
Нишли ала соң кыю ир?
Киленнәр тол калса тауларда
Тын гына,
Тын гына
Ташларың елый бит, туган җир...
Еллар ераклыгында хисләрең саекса,
Җәлләмә мине. Калдыр.
Син бүләк иткән сулмас мәхәббәтем
Гомерләргә минем белән калыр.

## Иркәлә, бәгырем...

Ай сусап елгага төшкән,
Нурлар кайтара...
Алтын буразна су өстен
Урталай яра.
Яр буенда — егет һәм кыз.
Шомырт исләре...
Шигырь итеп укый егет
Сөю хисләрен.
Кызның дымлы керфеккәе
Керфеккә тиде.
Гүя ул, серле талпынып,
Ялвара иде:
«Сөенеп сөеләсе вакытым —
Иркәлә... бәгырем...
Я, сирәк кенә булса да
Үпсәнә, бәгырем...».

●

Күзләр хушлашканда — сүзләр артык.
Күзләр алар... күзләр алдашмас.
Давылларда бер буразна ярып
Тапкан дуслык мәңге адашмас.

●

И. Шакировка

Мендәң дә син Урал тауларына
Хәйран калдың, басып ташына.
Таулар кайтавазы булыр идем
Җырыңдагы моңлы тавышыңа...

●

Йолдызларны көндез күзләмә,
Бәдрә таллар үсми чагында.
Эзләмә.
Ширбәтле тел яхшы — табында.
Уз теле бар җырның давылда.

# БЕЗДӘ КУНАКТА ЛЕНИНГРАД ШАГЫЙРЬЛӘРЕ

*Михаил Дудин*

## Идел ташкыны

Язның көче торган саен арта,
Туктый белми юлда арып ул.
Киң Иделнең күксел бозын вата
Зур дулкыннар белән бәреп ул.

Ачыла ярлар. Кими бара төтен.
Ташкын шаулый. Ерыла буалар.
Юеш җирнең көлсу-кара битен
Су һәм кояш бергә юалар.

Тын култыкка баржа уза башлый
Шыгырдатып тутык чылбырын.
Тәкәрлекләр хоры суза башлый
Зәңгәр күккә аяз көн җырын.

Яз җылысы салкын төнне куа.
Таңның ата алсу төслесе.
...Шундый чакта, шушы якта туа
Безнең Ленин — бәхет кешесе.

Шунда сөя, шунда укый башлый,
Шунда үсә аның фикере,
Учакларга шунда утын ташый,
Шунда төшә суга сикереп.

Шунда күрә язгы боз ярсуын,
Су шавына колак сала ул.
...Һәм мәңгегә туган ил халкының
Рухы булып ныгып кала ул.

Ил язының яме булып кала,
Һәм яшәргә өнди ашкынып.
...Бер-бер артлы яңа юллар сала
Планетада Идел ташкыны.

*Николай Браун*

## Сүзләр турында

Тик сүз генә, көчле сүз генә
Балкый ала уттай кабынып.
Туктаталмый вакыт үзе дә
Андый сүзнең кыю адымын.

Килеп керә синең йортыңа
Һәм янында синең кала ул.
Уята ул сине йокыдан,
Синең җырың була ала ул.

Көчле сүзнең көчле адымы
Җиңел итә синең эшеңне.

Кабат әйтсәң — кинәт кабыкып
Көчле итә бүтән кешене.

Әйтер аны җирдә бүтәннәр
Һаман-һаман, кат-кат, һәрвакыт —
Иҗатчысы аның күптәннән
Әйткән төсле көчле яңгыратып.

Син, көчле сүз, — кыю йөрешле!
Киләчәккә байлык булып бар!
Син, көчле сүз, — газап җимеше...
Онытмасын шуны оныклар.

*Сергей Орлов*

## Россиям

Калку кырлар, күлләр, урманнар...
Болар бар да минем Россиям!
Сиңа миндә бик күп җырлар бар,
Шуны көйләп сиңа баш иям.

Йөрәк әйтсен йөрәк сүзләрен
Ишеттереп бөтен якларга.
Полкым белән бергә тезләнеп,
Мин ант иттем сине сакларга.

Утка керттә бик күп көн безне,
Җиңү юлын еллар салдылар.
Күпләребез фанер йолдызлы
Каберләрдә ятып калдылар.

Мәтәлдердек упкын төбенә,
Фашист явын издек, таптадык.

Чыктык читкә. Синең күгеңнән
Киңрәк күкне ләкин тапмадык.

Байрак төсе, арыш, күк төсе...
Синең төсең болар, Россиям.
Сүнмәс кояш, сүнмәс ут төсле
Даннарыңа синең баш иям.

Баш иям мин чыксам болынга
Нинди саф, дип, җирдә чык бүген.
Баш иям мин мактап җырымда
Бетоныңның тиңсез ныклыгын.

Нәрсә кылә минем кулымнан —
Бар да сиңа, минем Россиям!
Син тудырган Ленин юлыннан
Алга атлап сиңа баш иям.

*Елена Вечтомова*

## Таң атканда

Майданнарда зур пыяла йортлар
Күренә балкып, күренә матурланып.
Гудок тавышы һава яра портта —
Төнне куа Нева катерлары.

Мин канәгать җирдә бу иртәмнән,
Өем иппе — күптән-күптән таптым.
Труба сузып, дустым су үткәргән,
Дустым салган мичне кичтән яктым.

Стенамны таныш утлар уйнап
Торган итеп рәссам бизәкләде.
Тирә-юньдә — барча сукмак буйлап
Сеңелем чәчкән чәчәк бизәкләре.

Ә булмәдә — шарлавыктай баскыч,
Минем кебек, ул да дулкынлана.
Ә киләчәк котә ишек ачып,
Яңа җырым булак булсын аңа.

*Павел Кустов*

## Көз

Көз юллары! Тынмас ташкын булып
Илебезне баета торган юл.
Олауларга өем-өем тулып
Хезмәтебез кайта торган юл.

Бакчаларны төннәр үзе саклый,
Керим дисәң — билет түләүсез.
Үләннәрне анда кырау аклый,
Алмагачлар анда терәүсез.

Тегермәндә берәү он тутыра,
Ә берәүләр — ауга юл тота.
Туй бүләге чигеп кыз утыра,
Тик булмавы туйның куркыта...

Гомер көзем! Шулай тулсын иде
Уңыш булып минем эшем дә.
Өсталемдә сый да булсын иде,
Булсын иде янда кешем дә.

*Леонид Хаустов*

## Могҗиза

Мин могҗиза күрдем асфальт юлда:
Бер калкучык башта күренде.
Иртәгесен шул җир ярылды да
Яшь үсенте өскә үрелде.

Бик охшаган иде яшел нурга —
Нечкә иде, туры иде ул.
Караңгылык көчен җиңде ул да,
Хәзер җирдә балкый инде ул!

Күктә әгәр кояш балкып янса,
Орлык төшсә әгәр туфракка —
Үсми калмый җирдә җанлы нәрсә,
Яңа җиңә һәрбер очракта!

*Владимир Торопыгин*

## Улыма

Тунтаусыз тәкелди курнослар,
Гөр килә балалар бакчасы.
Сез берга уйныйсыз, сез — дуслар,
Сезнеке — хыялның барчасы.

Буйлары — тик карыш барысының,
Үзләре — безнең зур килачәк.
Озатып безнең бу гасырны
Яңага нәкъ шулар керәчәк.

Үлчәп һәм чамалап барысын да
Тарихка шушылар язарлар.
Төшмәсме шул хөкем каршында
Без тоткан бүгенге базарлар?

Үлмичә яшәрме эшебез,
Холкыбыз заманча кырысмы?
Матурмы кичергән хисебез,
Җырлаган җырыбыз дөресме?

Үс, улым! Дусларың төркемен
Үз итеп, ярата белеп үс.
Үс, минем булачак хөкемем,
Иң якты өметем булып үс!

*Вилен Борисов*

## Тарих битләре

Хәтерләтте сүрән диңгез буен
Кырыс култык безнең карашка.
Дымсу һава. Тын җир. Үлән нуе.
Берәү чыга яшел шалаштан.

Кепкасын ул артка басып кигән,
Ерак карый, күрем киң аның.
Кашын җыера — гүя шушы җирдән
Күрер өчен бөтен дөньяны.

Һәм шул кеше учак янына килә,
Зур дәфтәрен алып утыра.
Хәтсез йөгерек карандашы белән
Тагын бер бит язып тутыра.

...Яңа ылыс. Чатнап китә бер моң.
Бөтереләләр уйнак чаткылар.
Юлбашчының бите Октябрьның
Байрагыннан гүя яктыра.

*Ольга Берголльц*

## Сынау

Шәрә чүлгә миңе илттең син.
Юллары юк. Көннәр озыннар.
Калдырдың да шунда киттең син:
«Сыныйм сине. Атла. Үзең бар!»

Һәм атладым, үзем киттем мин.
Кичер мине — бик нык шүрләдем.
Ерак юлны озак үттем мин,
Әлсерәдем, көйдем, тирләдем.

Белмәдем мин нигә син шулай
Теләгәнсең мине сынарга.
Мин чыныктым юлда шушылай,
Мин күнектем юлда шуңарга.

Мин яңадан синең каршыңда.
Йөрәгемә баккан күзең бар.
Әйт, кабатла тагын барсын да:
— Мин ышанам сиңа. Үзең бар!

*Александр Решетов*

## Яшьтәшләрем турында

Мөмкинме соң моны күрмәскә,
Күбебез инде ап-ак чәчле без.
Очрашсак та һаман бернәрсә:
Исталеклар сөйли башлыйбыз.

Мактанабыз: ничек тырыша
Малаебыз яки кызыбыз.

Әйтерсең лә, инде зур эшкә
Ярамыйбыз хәзер үзебез...

Юк, беләбез, эшләр муеннан,
Без эшләсәк — начар чыкмас ул.
Утлар кичкән солдат уенннан
Яшь солдатлар ләкин чыкмасын.

ЗӘКИ НУРИ тәрҗемәләре.

—✿✿—

# *Шота Руставелиның тууына 800 ел*



*Грузин халкының бөек шагыйре Шота Руставели иҗат иткән шигъри роман — «Юлбарыс тиресе ябынган батыр» дөнья әдәбиятының гүзәл үрнәкләреннән берсе булып санала.*

*Саф мәхәббәт, кешеләр арасында туганлык, халыклар дуслыгы, туган илне сөю, аны чит ил баскыннарыннан саклау, хаклык юлында фидакарьлек идеяләре белән сугарылган бу әсәр көнбатышның һәм көнчыгышның бик күп телләренә кабат-кабат тәрҗемә ителде. Рус теленнә генә дә аның алты тәрҗемәсе бар. Ул татарчага да кыскартылып тәрҗемә ителгән һәм басылып чыккан иде.*

*Журналыбызның бу санында без бөек Руставелиның үлемсез әсәреннән бер бүлек урнаштырабыз. Ул бүлектә романның төп каһарманнарыннан берсе булган Автандилның, гашыйк дусты Тариэлга ярдәм итү максаты белән, үзенең сөйгән яры Тинатинадан аерылып йөргәндә Кояш, Ай һәм Йолдызларга ялваруы сөйләнелә.*

## Автандилның күк яктырткычларына ялваруы

Әй, хәсрәтле дөнья, әйтче,
Нинди серләр саклыйсың син?
Адәмнәрне ник шулчаклы
Изәсең һәм таптыйсың син?
Кайдан килде алар сиңа
Һәм кай җирдә булыр туфрак?
Синнән җәбер күргәннәрне
Үзе генә яклый бер Хак!

Автандил күп яшьләр түкте
Тариэлдан аерылгач:
«Тагын, — диде, — ялгызым мин,
Тагын хәсрәт минем юлдаш.
Үлгәннән соң кавышу кебек
Аерылуны кичерә кеше.
Адәмнәр бит төрле була,
Газаплары ник бертөсле?»

Ерткычлар да еладылар,
Күреп аны шул чагында,
Көйдергәндә йөрәген ул
Кайгы-хәсрәт учагында.

Гүзәл яры Тинатина
Хәтеренә төште тагын.
Иреннәрнең ал гөлләрен
Хәсрәт җиле кисте тагын.

Шиндә ал гөл. Алоэ күк
Зифа буе сулды шунда.
Үткен кристалл, кызыл якут
Тоныкланды аһ утында.
Һәм әйтте ул йөрәгенә,
Көч бирергә аңа теләп:
«Кояш сүнгәч, караңгыга
Гаҗәпләнмә бер дә, йөрәк!»

«Әй син, Кояш, — диде аннан, —
Тинатинам төсле йөзең.
Аның белән икәү бит сез
Яктыртасыз бу җир йөзен.
Мин бит гашыйк, мин бит мәҗнүн,
Сездән фәкать нур алам бит.
Минем шашкан йөрәгемә
Җылыгызны бирмисез ник?

Кояш сүнсә, кешеләргә
Салкын була җирдә кышын.
Бер түгел бит, ике кояш
Сүнде хәзер минем өчен.
Ничек түзим? Авыртуны
Белми тик таш кыя гына.
Пычак бит ул дәваламый,
Ул бит тәнне суя гына».

Кояшка ул карап тагын,
Болай диеп зарын түкте:
«Үтәсең син җиңүле юл,
Кояш, гизеп чиксез күкне.
Җан өрәсең җансызга син,
Көчсезгә көч бирәсең бит.
Кызган мескен Автандилны,
Сөйгәнемнең янына илт!

Зөхәл, газап йолдызы син,
Күбрәк җибәр газап миңа.
Матәмгә төр йөрәгемне,
Галәмне күм караңгыга.
Җилкәмә сал дөньядагы
Авырлыкның бөтен йөген.
Тик әйт аңа: — Сөйгән ярың
Сине сагына анда, — диген.

Әй, Мөштәри, гадел хаким,
Син генә бит җир һәм күктә.
Синең алда — ике йөрәк.
Гадел хөкем алар көтә.
Бул рәхимле! Харап итмә
Мин гаепсез гашыйк җанны.
Минем йөрәк бер гүзәлнең
Карашыннан яраланды.

Мәрих, сугыш йолдызы син,
Када сөңгең, мә, тәнемә.
Юнәлт канлы укларыңны,
Кызганмыйча, күкрәгемә.
Тик үтенәм: сөйгәнемә
Газапларны минем сөйлә.
Күрәсең ич, тилмерәм мин
Еракларда ялгыз көйгә.

Зөһрә, сөю йолдызы син,
Салчы колак аһ-зарыма.
Янам гыйшык утында мин,
Ярдәм кулың сузчы миңа!
Бизисең син гүзәлләрне
Тиңсез гүзәллекләр белән.
Кызган мине! Шундый гүзәл
Берәүне мин сагынып үләм!

Әй, Гатаруд! Үз язмышым
Охшатам мин язмышыңа.
Син кояшка буйсынасың.
Мин дә бит — үз кояшыма.

Яз син минем күргәннәрне,
Һәммәсен дә. Белсен галәм.
Карап булсын күз яшьләрем,
Кипкән гәүдәм булсын каләм.

Кайчак тулы, ә кайчакны
Зәгыйфь, нечкә буласың, Ай!
Кояшымның әмре белән
Мин дә яшим һаман шулай:
Кайчак көчле, кайчак хәлсез.
Кызган мине! Күр хәлемне.
Сөйлә, зинһар, кояшыма
Аны уйлап кипкәнемне!

Бар йолдызлар шаһит миңа.
Күреп мине югарыдан,
Кояш, Зөхәл, Гатаруд һәм
Мөштәри кайгыга чумган.
Мәрих, Зөһрә, шулай ук Ай
Күреп тора һәммәсен дә.
Ташламасын мине ярым
Шундый хәсрәт дәрьясында».

Әйтте аннан йөрәгенә:
«Газапланма, җитәр, йөрәк!
Шайтан әнә саклап тора
Мыскылларга безне теләп.
Кара карга канат җәйгән,
Сөйгәнемнең каплап йөзен.
Көчеңне җый, бәхет безгә
Киләчәктә көлсен өчен!

Әгәр дә мин исән калсам
Батырлыгын саклап җаным,
Онытырмын газапларны,
Кояшымны күреп тагын».
Шундый матур җырлады ул,
Бөртек-бөртек яшьләр түгеп,
Сандугач аның янында
Булып калды байгыш кебек.

Еладылар бар ерткычлар,
Автандилның җырын тыңлап.
Ташлар чыкты елгалардан
Җанлы нәрсә шикелле нәкъ.
Гаҗәпләнеп тыңладылар
Аның аһлы бу җырларын,
Һәм кызганып еладылар
Газап чиккән батыр җанын.

*ӘХМӘТ ИСХАК тәрҗемәсе.*

---

АҢЛАТМАЛАР:

Зөхәл — Сатурн, газаплар йолдызы.

Мөштәри — Юпитер, гадел хөкем йолдызы.

Мәрих — Марс, сугыш йолдызы.

Зөһрә — Аспироз (Венера), мәхәббәт йолдызы.

Гатаруд — Меркурий, сәяхәт һәм сәүдә йолдызы.

# Очерк

*Габделхәй Сабитов*

## ҺӘР НИГЕЗНЕҢ ТАРИХЫ БАР...

Ул әкрен генә төнге урамнар буйлап атлый. Тулы ай, сыек кына болытлар артына кача-поса, ана няреп бара. Һавада яз исе, дымлы жир исе, яшь бөреләр исе аңкый... Ельховой авылы, ай нурына манчылып, изрәп йоклый... Тынлык, көмеш тынлык. Хәтта күктә йолдызлар атылганы да, хәтта бөреләр эчендә яфрак шытканы да колакка ишетелгәндәй була...

Хәлиулла абый, серле тынлыкка колак салып, әкрен генә атлый. Урамның ике ягыннан тезелеп киткән йортлар, үзләренең караңгы күзләре белән тын гына, тып-тын гына аңа карап калалар. Йортлар... Һәр йортның, һәр гаиләнең үз кайгысы, үз шатлыгы бар. Һәр нигезнең ерак елларга киткән үз тарихы бар... Менә бу нигездә кайчандыр жиде балалы ярлы ялчы яшәгән. Көн-төн байга эшләп тә тамак туйдыра алмагач, йорт-жирен сатып каядыр читкә киткән дә суга төшкән кебек юкка чыккан... Ә бу нигезнең хужасы гражданнар сугышында үлеп калган, балалары ачлык елда кайсы кая таралып беткәннәр. Хәзер ул урынга яшь бер колхозчы егет яна йорт салып, матур гына оя корып куйган. Әнә теге йорттан арсландай таза өч егет Ватан сугышында һәлак булды. Йорт урыннары әле хәзер дә, төзәлеп житмәгән яра кебек, ярылып ята... Ә бу нигездән ата белән бала хәбәрсез югалды... Бу йорттан өчәү, тегесеннән икәү кайтмады. Бер Ельховой авылыннан гына да фашист аждаһа 297 ир-егетне ашады...

Шифер түбәле бер йорт турына килеп житкәч, Хәлиулла абый озак кына тукталып торды. Кайчандыр анда авылның беренче коммунисты Юнысов Әгъләм яши иде. Аны сәнәкчеләр үтереп киттеләр. Аның белән бергә халык күңелендә азатлык тойгысы уятып, ярлы-ялчыны көрәшкә туплап йөргән Сафиуллин Шәйдулланы аклар Шушма ярына бастырып аттылар. Ул чакта Хәлиулла әле бала гына иде. Шулай да бу вакыйга аның хәтерендә сакланып калган. Шәйдулла абзыйның үле гәүдәсе су өстенә авып төште. Хатыны ике көн буена, елый-елый, көянтә башы белән су төбен айкап йөрде. Ләкин аның мәетен берничә көннән соң гына табып алдылар... Исәпләсәң исең китәр! Шушы айлы төннәрнең тынычлыгын, шушы йортларның иминлеген саклау өчен бер авыл гына да күпме корбаннар биргән!

Хәлиулла абыйның күңелендә әрнүле, авыр уйлар кузгалды. Ул, өенә кермичә, кире борылып, Шушма буена төште дә күпер рәшәткәсенә барып сөялде... Кинәт аның бала чагы, инде исемнәре дә онытыла башлаган балалык дуслары аермачык булып күз алдына килде...

...Шушмада боз ага. Яр буенда күтәрмәле чабата кигән бәләкәй Хәллә йөгереп йөри. Дус малае Ибраһим да, Камил дә, Вәжи дә, тагын бик күп башка малайлар да шунда. Алар боз кисәкләре өстенә салам, тирес өяләр дә, ут ягып, суга агызалар. Һәрберсе үз утларын ягарга тырыша... Утлар, утлар... Алар да кеше гомере кебек. Кайберсе пыскып кына яна, кайберсе эчтән дөрли, кайберләре гөлт итеп кабына да, су өстенә чаткылар чәчрәтеп, еракларга, әллә кайларга йөзеп китә.

...Малайлар, дөньяларын онытып, шул утларга карыйлар. Бәләкәй Хәллә дә карый. Ә күпер өстеннән инде маңгаена жыерчыклар чыккан өлкән Хәллә — Хәлиулла карап

тора... Кинәт малайлар барысы берьюлы күпер ягына борылалар. Алар, бик гаҗәпсенгән кебек, Хәлиулла абыйга текәләләр... Язгы һавадай саф, зәңгәр, карлыгандай кара күзләрен зур ачып, нәрсәнедер серенә төшенергә теләгәндәй, йөрәккә үтәрлек итеп карыйлар һәм, нәрсәдер өмет иткәндәй, тып-тын басып торалар. Гүя алар күпер өстендә олы Хәллә белән янәшә олы Ибраһимнар, олы Вәҗиләр булмаганга аптырыйлар. «Син ник аларны алып килмәдең, ник аларны оныттың?!» дип, гүя Хәлиулла абыйга рәнҗиләр. Алар үзләренең кечкенә Хәллә дусларына да үпкәлиләр:

«Әллә оныттыңмы? Чабатандагы күтәрмәнең юкәсе өзелгәч, мин ялгап биргән идем», ди кечкенә Ибраһим.

«Әгъләм абыйны сәнәкчеләр үтергәч, ни әлек сина кем килеп сөйләгән иде? Ник онытасың?» ди Хаҗи. «Ә мин булмасам, Бәрәскә ягыннан кызыллар килгәнен күрми кала идең», дип бармак яный кечкенә Камил...

Ни әйтсен Хәлиулла абый, хак сүзгә җавап юк!

Ул, бәлки, шушы төндә үз хыялында җанланган балалык дуслары алдында вәгъдә биргәндер: «Юк, без беркайчан да сезне онытмабыз. Сез безгә бәхет яулаганда һәлак булдыгыз. Без сезнең якты истәлекне мәңге саклarбыз», — дигәндер.

●

...Тыңлагыз! Колхоз радиоузелы сөйли. Клуб мөдире Хәлиулла Әхмәтшин чыгышын тапшырабыз...

«Кадерле авылдашларым! Гаеп итмәгез, мин артистлар кебек матур итеп сөйли белмим. Күңелемдә ни бар, шуны әйтәм. Кайчак без, тормыш вак-төягә белән мавыгып, зур нәрсәләрне, изге нәрсәләрне онытып җибәрәбез. Яшьләр белмиләр, картлар кайгыртмыйлар. Һәр көн саен Шушма күпере аша үтеп-сүтеп йөрибез. Ә бит ул күпер төбендә безнең бәхетебез өчен Шәйдулла абзый үз гомерен бирде... Кайсыбызның шул урыннан узганда, ул кешене исенә төшергәне бар? Кайсыбызның ихтирам белән баш киемен салганы бар? Юк бит. Болай булса, тагын утыз-кырык елдан аларның исемен дә онытырлар. Киләчәк буын яшьләренә нинди истәлек калыр? Юк, иптәшләр, бу эшне ил гафу итмәс. Без аларны онытмыйк. Һәйкәл салыйк без ул көрәшчеләр истәлегенә. Авылыбызда алардан башка да нинди генә кешеләр булмаган... Төрле илләрнең, дәүләтләрнең тарихы язылган. Ә бит һәр авылның, һәр йортның үзенә күрә тарихы бар. Безнең Ельховойның тарихы аеруча бай. Әйдәгез, үзебез исән чакта шул тарихны яшьләргә сөйләүнең берәр әмәлен табыйк»...

Хәлиулла абыйның бу чыгышы Ельховой кешеләренең күңелен кузгатып җибәрде. Октябрьның 40 еллык бәйрәменә авыл уртасына Юнысов Әгъләмгә һәм Сафиуллин Шәйдуллага Кызыл Йолдызлы һәйкәл салып куйдылар. Ватан сугышы бетүгә егерме ел тулган көннәрдә сугышта һәлак булган 297 батыр хөрмәтенә тагын ике һәйкәл калкып чыкты. Ләкин Хәлиулла абыйның күңеле аның белән генә тынычланмады. Ул Октябрьның 50 еллыгына моңарчы берәүнең дә башына килмәгән зур бүләк әзерләү эшенә керешкән иде.

●

...Бәрәңге бакчасы сөргән вакытта, буразнадан нинидер җиз калай кисәге табылды. Күгәреп, яшелләнеп беткән кечкенә генә таңка. Бер читенә тишек тишелгән, урта бер җиренә 7112 саны сугылган.

Хәлиулла абый, галимнәрдән сорашып, аның нәрсә икәнен ачыклады. Борын заманда крепостной крестьяннарның түшенә шундый жетон тага торган булганнар... Димәк, кайчандыр Ельховой авылында 7112 нче номерлы бер кеше яшәгән. Ул гомере буе алпавыт өчен җир сукалаган, иген иккән... Хәер, кем белә, бәлки, ул, тәмам үзәгенә үткәч, йорт-җирен ташлап, кара урманнарга качкандыр, гомеренең соңгы көннәренә кадәр кыргый киекләр арасында качкын булып яшәгәндер. Ә бәлки, Пугачев яуларына кушылып, алпавыт утарларының көлен күккә очырып йөргәндер... Бер дә гаҗәп түгел, элек-электән Ельховой авылында гаяр егетләр күп булган...

Нинидер мулладан калган иске йортны сүткән вакытта, чормадан бер төргәк саргайган кәгазьләр табылды. Моннан 150—158 ел элек язылган нинидер хатлар, мышаныч




кәгазьләре, жир бүлү исемлекләре. Аларның күбесе ертылып, теткәләнеп беткән. Кайберләренең башы, кайсының ахыры юк, янгыр суы үтеп, хәрефләре жуелып беткән.

Хәлиулла абый хәрефләп, иҗекләп булса да аларны укырга, мәгънәсенә төшенергә тырышты...

«18... нче ел, 22 гыйнвар.

Мин Габдулла Кормаши улы Каташлы кырыннан 4 колач жиремне саттым. Түбәндәге шаһитлар хозурында, шул ук авылның Шаһидулла Һидиятулла улына. Бәһасы 1 сум.

Бән, Габдулла Кормаши улы 1 сум акчаны алдым.

Бән, сельский староста, пичәтемне бастым»...

«18... нче ел, 28 үктәбр.

Минзәлә өязе, Ярсубай волосте Биктимер Әбүталип улы, Фазлытдин Тимербулат улының казна бурычы өчен, паек өчен, страховой өчен тиешле мәгъҗүмәне 22 сум 13 тиенгә (мәзкүр егерме ике сум унөч тиенгә) алдым. Фазлытдин Тимербулат улында калмыш мөлкәттән. Ызба йорт урыны белән, һәм читән, һәм бер самовар, һәм өч пот арыш оны, бер батман бәрәңге, янә подаука, урындык, гер әсбаплары.

Кабул итеп алдым, тамгамны салдым».

Бу кәгазьләрне укыгач, Хәлиулла абый тирән уйга кала... Крепостное право инде бетерелгән. Ельховой крестьяннары «ирек» алганнар. Түшләренә тагып йөргән элеге коллык тамгаларын өзеп ташлаганнар, ләкин куллдагы богаулар шул килеш калган. Ниндидер Кормаши улы бер сум акчага үзенең соңгы өметен — 4 колач җирен сата. Казна бурычлары өчен икенче берәүнең йорт-җирен, иске читәнен, урындыгын, бер батман бәрәңгесен саталар. Үзен ач-ялангач килеш бала-чагасы белән урамга куып чыгаралар. Өченче бер бичара, апрель аенда ук ашарына бетеп, байга әҗәт сорап бара, кулыннан язу биреп, табагач тамгасын куеп, алдагы җәйдә түгеләчәк маңгай тирен сата.

«...апрельнең 21 нче көнендә Фәтхетдин байдан алдым акчасыз: бер кадак чәй — 13 тиен, өч кадак ит — 70 тиен, ярты кадак шикәр — 18 тиен.

Тамгамны куйдым.

13 нче майда янә алдым: ярты кадак чәй, ярты кадак шикәр, бер кадак тоз — 21 тиен. Каснлы елгадагы арышын уру өчен.

Тамгамны куйдым»...

Хәлиулла абый, төннәр буе утырып, саргайган кәгазь кисәкләреннән, күгәргән тәңкәләрдән, каяндыр табылган борынгы орден, медальләрдән туган авылының тарихын терки. Ул инде үзенең хыялын сер итеп сакламый. Колхоз радиоузелы буенча тагын чыгыш ясый, уку йортына абруйлы картларны җыеп киңәшә:

— Авылда тарих музее ачарга диган хыял бар. Шул эшкә ничек карыйсыз? Ярдәм итәрсезме? — ди.

— Һай, Хәлиулла энем, бик изге эшкә алынгансың. Рәхмәт сиңа, — диләр картлар. — Әйдә, тырыштырып кара. Кулдан килгәнчә булышырбыз.

— Әнә миндә иске намазлык бар. Кирәк булса, бүген үк китерәм, — ди берәүсе.

— Намазлык дисең син. Минем чормада әнә полный коръән аунап ята. Аны да куй, күрсеннәр безнең башны нәрсә белән черетканнәрен...

— Минем чиннектә чабагач аламасы ята бугай. Кирәк булмасмы?..

Музей төзү эшенә озакламый бөтен авыл халкы кушылып китә. Әкъдәс исемле укучы малай борынгы акчалар табып китерә, сыер савучы Сафина Җинания каяндыр көмеш чулпылар табып бирә. Тәзкирә исемле яшь килен музейга зур хәситә бүләк итә. Тора-бара уку йортында аяк атлар урын да калмый. Хәлиулла абый экспонатларны үз өенә җыярга керешә. Шкафлар, өстәл тартмалары шыгрым тула. Табак-савыт куярлык та урын калмагач, Минлегаян апа картыннан көлә:

— Җуләр таш җыяр, диләр иде, Хәлиулла, син ташын да, тимерен дә, бакырын да читкә куймыйсың. Инде ятар урын да калдырмадың бит,— ди.

Ләкин Хәлиулла абыйның яклаучылары җитәрлек. Өч кызы өч яктан ярдәмгә килергә әзер торалар. Яклаучылары булгач, Хәлиулла абый да батыр кылана. Көн саен я борынгы бизмән, я чакмалы мылтык, я булмаса кулак обрезы табып кайта. Житмеш яшьлек Закирә апа ана киндер сугу станогы биреп чыгара.



Чабата ясаучы татар карты.
Х. Әхмәтшин эше.

— Кулбашларыма кан төшерде, аркама бөкре чыгарды, каһәр суккыры. Инде кабат күрергә язмасын, — ди ул.


Көннәрдән бер көнне, Хәлиулла абый ике тәрәнле зур сабан сөйрәп кайткач, Минлегаян апа чыгырыннан чыга:

— Инде алып уздың, Хәлиулла, — ди ул. — Бусы артыннан трактор да алып кайтмасаң ярар иде инде...

— Колесный трактор табып булмый шул әле, карчык,— ди Хәлиулла абый.— Юкса, бик кирәк нәрсә ул. Музейда гына күрмәсәң, хәзер аны кайда күрәсең... Әле нефть вышкасы китерәселәр иде. Искеләре белән рәттән, хәзерге заман техникасын да күрсәтергә кирәк бит...

Хәлиулла абыйның уены-чыны бергә. Ул, чыннан да, вышка мәсьәләсендә нефтьчеләр белән күптән сөйләшеп куйган.

Кайчак уен белән уздырса да, экспонатларның төрле җирдә чәчелеп ятуына аның күңеле әрни. Бу эшкә ул күпме көч түкте, авыл халкы, мәктәп балалары күпме булышты, куяр урын булмагач, җыеп, халыкка күрсәтеп булмый...



Музей бинасының тышкы күренеше.

Хәлиулла абый, җаен туры китереп, бу турыда колхоз идарәсендә сүз кузгатты. Ни әйтерләр, дип куркыбрак кына килгән иде, колхоз җитәкчеләре ныклап, зур итеп кинәшергә керештеләр. Ул көнне Хәлиулла абый идарәдән шатланып, дулкынланып кайтты.

•

...Шыр ялангач иске авыл өе. Стена буенда киндер сугу станогы. Бүкән утыргычта сәләмә киемле бер бабай чабата үреп утыра. Башында каешланып беткән түбәтәй, өстендә ямаулы иске күлмәк, киндер алъяпкыч. Аягында иске тула оек, тишек чабата... Кайчандыр бабай аю белән көрәшерлек пәһлеван егет булган. Ләкин хәзер аның маңгаен җыерчык баскан, тәне хәлсезләнгән, аркасы бөкрәйгән, бер җилкәсе түбәнрәк төшкән. Кешене нужа изгән, нужа картайткан...

Стенада төрле картиналар — иске тормыш күренешләре... Ельховой авылының бер ярлы кешесе үзенең дүрт колачлы җирен сукалый. Арык аты аягында чак басып тора. Аптырагач, хуҗа үзе аңа булыша, бөтен көче белән сука башыннан этеп бара...

Икенче бер рәсемдә хатын-кызлар бил бөкрәйтеп урак уралар... Ике ир кеше пычкы белән такта яра, бер әби үзенең бердәнбер хайванын — көтүдән качкан азгын кәҗәсен алып кайта.

Болар барысы да Хәлиулла абый иҗат иткән картиналар, ул эшләгән макетлар...

Музейның алты бүлегендә 8000 нән артык экспонат бар. Пыяла витриналар эчендә борынгы акчалар, ахаклар, беләзекләр. Кайчандыр татар халкының элекке бердәнбер музыка коралы — кубыз да табылган. Кораллар бүлегендә чакмалы пистолетлар, ханҗәрләр, кистәннәр... Кем белә, бәлки, кайчандыр бу кистән берәр канәчкеч алпавытның башын бәреп ваткандыр. Һәрхәлдә, Ельховой авылына ул тикмәгә килеп кермәгән, тикмәгә аны кеше күзеннән яшереп сакламаганнар!

Ельховой егете иңендә Берлиннарны әйләнеп кайткан соры шинель, сугышчан орденнар, медальләр, һәлак булган батырларның фоторәсемнәре...

Пыяла эчендәге, ак кәгазь өстендә зур калибрлы фашист пулясы. Ул җиде ел бер егетнең йөрәк җылысын суырып, канын агулап йөргән. Аны докторлар шул кешенең тәненнән ярып алганнар...

Бу музейдагы экспонатларда — чалгы, чабагач сапларында, чабата калыпларында гасырлар аша кеше кулының җылысы сакланып калган. Бу әйберләр инде күптән исемнәре дә онытылган кешеләр авызыннан сөйли беләләр: без менә шулай газап чиктек... Без менә шулай яшәдек... Без шулай көрәштек, шулай үлдек, диләр. Сез әнә шулай яшисез, шулай яшәрсез... Безне онытмагыз... Әй, кешеләр! Бүгенге тормышыгызның кадерен белегез. Кояшлы көннәрегезне, айлы төннәрегезне уяу саклагыз, диләр...

*Әлмәт районы, Ельховой авылы.*

# БАШКОРТСТАН БЕЛӘН ОЧРАШУ

*(Юл язмалары)*

Биектә-биектә, Күрдем авылы турысында, самолет оча. Шундый биектә ул, Татарстан белән Башкортстан аңа тау-урманнары, тасма юллары, уртан елгалары белән берьюлы күренә торгандыр.

Ә без җирдән барабыз.

Зур Башкортстанның авыллары, кешеләре, чәчәк-гөлләре белән әерым-әерым, берәмләп-берәмләп күрешәбез. Яңавылда әдәби атналыкка чыккан бер төркем татар һәм башкорт язучыларына райком секретаре Закир агай Мөхәммәтшин әйткән иде: «Еллар быел әйбәт, игеннәр матур күренә, халыкның күңеле күтәренке, сезгә халык белән очрашулар бәйрәм булыр әле»,— дигән иде. Аның сүзләре Аксаит авылына килеп керү белән үк расланды. Алай гына булса әле! Без килгән көнне шаулатып яңгыр явып узды. Безнең язучыларга шул җитә калды: менә без сезгә яңгыр да алып килдек, дип бераз гына мактанышып алырга да күп сорамадылар.

Аксаит авылына кереп, колхоз идарәсе янына килеп туктауга, Әлмәт язучыларының җитәкчесе Әдип Маликов белән, кояш кебек яктырып, бер кеше килеп күрешә һәм Әдипнең кулын озак кына җибәрми торып:

— Син һаман яшь кое, якташ, бер дә генә картаймагансың,— диде.

Әйе, бу яклар Әлмәт язучылары Әдип Маликов белән Саҗидә Сөләйманованың, башкорт язучылары Гайнан ага Әмири белән Әнгам Атнабаевның туган-үскән яклары икән. Аларга якташлары белән күрешү, якташларына аларның шигырьләрен тыңлау, ә безгә шул шатлыклы очрашуны күреп тору бик күңелле булды. Авыл саен диярлек Нурихан Фәттахны, Сәет Кальметовны, бертуган Юзиевларны сораштыралар. Аларның да туган-үскән яклары Яңавыл районы булып чыкты. Бәхетле район — әдәбиятка күпме язучылар биргән! Җырларда җырлана торган Әри суы да Аксаит янынкан гына ага икән. Тугайлары матур, ерак урманнары әллә кайлардан ук күренеп тора. Кавказны хәтерләткән әерым таулар очрый, кыр урталарында, төркем-төркем булып, кипарисларга охшаган чыршылар үсә. Киң күңелле, ачык йөзле кешеләрне шул тугайлар үстергәндер инде...

Кичен клуб шыгрым тулы иде. Якташларының шигырьләрен дә, кунак шагыйрьләрнең шигырьләрен дә йотылып тыңладылар. Сүз Гамил Афзалга бирелгәч, залда халык кузгалышып куя, шушы сәхнәдән аның шигырьләрен ничәмә-ничә мәртәбә укыганнар, күрәсең. Менә хәзер үз шигырьләрен шагыйрь үзе укый. Бәйрәм түгелмени бу?! Әнгам Атнабаевның шигырьләрен дә бер генә мәртәбә ишетмәганнәрдер. Ул үзе дә сүзен: «Минем инде сез белмәгән шигырьләрем дә юк», дип, тыйнак кына башлап китә китүен, әмма яктырып киткән йөзләрдән аны укып та, тыңлап та туймаганнары күренеп тора. Әдип Маликовның «Әниемә» дигән шигыре бигрәк нык тәэсир итте. Рауза апага багышланган шигырь бит инде ул. Тугыз бала үстереп, тугызысын да шушы Аксаит мәктәбендә укыткан, барысы да диярлек мәктәпне медальгә тәмамлап чыкканнар. Хәзер аның төпчек кызы Лема аттестат алу өчен имтихан тота. Әни кешенең бар сүзе шул булды: «Менә үзем генә калам бит инде шушы өйдә»,— ди. Үзең генә түгел инде, Рауза апа. Урам аша гына балаларың укыган мәктәп кала, алар әчеп үскән чишмәләр, тәгәрәшеп уйнаган болыннар кала синең белән!

Без Аксаит мәктәбе музеенда булдык. Авылның тарихы, хөрмәтле кешеләре язылган бер альбомда Рауза апа белән Малик агайның балалары да рәсемгә төшерелгән.

Авыл мәктәбеннән соң вузлар тәмамлап, инженер, артист, шагыйрь, укытучы булып зур илебезнең төрле якларына очып киткәннәр алар.

Мәктәп йортлары, мәктәп каралтылары Аксаитта үзләре бер урам булганнар. Шуңа күрә бу авылда мәктәп урамы дигән урам да бар икән. Мәктәп директоры Сафуат Сабиров һәм ул җитәкләгән укытучылар коллективы балаларда табигатьне ярату хисе тәрбияли алганнар: алмагачлары, карлыганнары, җир җиләкләре булган мәктәп бакчасы күкрәп тора! Бакчадан килгән табышка урын җитәрлек: мәктәп ишек алдында кирпечтән зур клуб салынып ята, анда спорт залы да булачак, инвентарьлар сатып алырга кирәк. Авыл яшьләре арасында спорт белән кызыксынучылар күп.

Без булган икенче авыл — Күрдем авылы — иңкүлеккә урнашкан. Шуңа күрәдер инде урамнарын аркылап та, бакча артларыннан да чишмәләр агып ята. Язын ике тау битеннән карлар эреп акканда тамаша буладыр анда. Аның каравы зур-зур өянкеләр шушы авылда гына үсә икән. Без фатирга урнашкан Тоҗа апаларның ишек алдында да, урамның ике ягында да әллә ничә кеше җитәкләшсәң генә уратып алырдай өянкеләр шаулап утыра. Идарә янындагы бакчада, карт өянкеләр төбенә, авыл халкы үзенең Ватан сугышында һәлак булган улларына һәйкәл куйган. Колхозның 350 кешесе кайтмый калган. Бер өй эченнән икешәр, өчәр кеше үлеп калучылар да бар. Кичен клубта очрашкан чакта язучыларга күп итеп чәчәкләр китерганнәр иде. «Болар безгә тиеш түгел», диделәр язучылар һәм ул чәчәкләрне әнә шул һәйкәл янына салдылар. 350 кеше исеме арасында Әдип Маликов бергә укып үскән дустының исемен очратты. Тәтешле военкоматыннан бергә чыгып киткән булганнар. Әнә нинди авыр очрашулар да була...

Мондый һәйкәлне Югары Кодаш авылында да күрергә туры килде. Бу Кайпан авылы клубы янында зур мәһабәт һәйкәлне тезеп бетереп киләләр. Ленин исемендәге колхозның гаҗәеп уңган, булдыклы председателе, аз сөйләп, күп эшли белүче Әхәт Батталов һәйкәлгә куйдыру өчен мемориаль такта яздырырга боерыклар әйтте. Һәрбер һәйкәл янында һушыңны алырдай, җаннарны өшетердәй озын исемлек. Күпме ир-егетләр кайтмый калган яу кырыннан! Күпме тол хатыннар, ятим балалар калган ил буйлап. Ләкин ничек кенә авыр булмасын, тормыш бара, гомер үтә. Ятим калган балалар, әтиләре яшенә җитеп, үзләре гаилә корганнар, тормыш хәзер шулар кулында, колхоз авылының авыр йөге алар җилкәсендә.

Башкортстан авылларында күргән һәйкәлләр безнең Татарстандагы һәйкәлләрне дә искә төшерделәр. Шуңа күрә татар әдәбияты турында сөйләгән кереш сүзен Гариф Ахунов Фатих Кәримнәрдән, Муса Җәлилләрдән башлап җибәргә иде. Егермеләп татар язучысы илгә фашизм афәтен җибәрмәс өчен чик буйларында ятып калдылар. Альп тауларында полковник Нур Баян кабере сакта тора, Кенигсберг янында Фатих Кәрим уяу йоклый. Польша җирендә трибун шагыйрь Гадел Кутуй ятып калды. Европа өстендә Җәлил тавышы яңа сугыш уты кабызучыларга каршы көчле набат булып яңгырап тора. Без бурычлы алар алдында. Ирешкән уңышларыбыз, җир өстендә тыныч яшәвебез, көлүебез, һәр сулышыбыз — аларның бик иртә өзелгән гомерләренә бурычлы. Язучылар әнә шул хакта сөйләделәр.

Бу атналыкта катнашучылар яшьрәк буын әдәбиятчылар булганлыктан, татар һәм башкорт әдәбиятларының нигез ташларын салучы Тукайларны, Гафуриларны, Галимҗан агайларны, Такташларны һәм аларның эстафетасын бүгенге яшьләргә китереп тоташтырган өлкән буын әдипләребезне бер генә минутка да онытмадылар.

Без Күрдем авылында иртән кояш чыкканны карарга тау өстенә күтәрелгән идек. Биектә-биектә очкан самолетны без әнә шунда күрдек. Тонык зәңгәр күктә ак юл сузып узучы самолет күңелдә зур уйлар кузгатты. Без кояш чыкканны көтәбез, ә самолет аны күптән күрде бит инде; без Башкортстан җирендә өч меңнән артык күл бар икән дип сөйләшеп торабыз, ә ул аларны барлап, аларга сөенеп узды бит инде. Көмеш канатлы самолетлар очкан биеклектән бик күп нәрсә күренә. Бәлки язучыларга да кайвакыт әнә шул биеклектән торып карау кирәктер. Дөньяның зурлыгы, матурлыгы да ул чакта күбрәк күренер, уй-тойгылар канатлырак булып очар иде. Вакыт-вакыт безнең шагыйрьләребез үзләренең ил язмышы белән бәйләнмәгән чамадан тыш тар, артыгы белән интим тойгылары белән мавыгып китәләр бит.

Очрашулар төрле-төрле булды. Кичен авыл клубларында игенчеләр белән очрашу, көндез җәйләүләрдә савымчыларны күреп сөйләшү, башлап язучыларга консуль-

тациялар бирү, киңәшмәгә җыелган авыл культура эшчәннәренең әдәбият һәм сәнгатькә булган таләпләрен тыңлау. «Урал» колхозында парторг Зариф агай Адыев безгә үндүрт урында җәйләү барлыгын хәбәр итте. Без булган Кучмә Кызыл байраклы беренче бригада җәйләве матур бер урман аланына урнашкан иде. Терлекчеләр белән бергә, төрле авыллардан җыелган культура работниклары яшел чирәм өстенә, зур бер чыршы тирәсенә түгәрәкләнеп утырдылар. Язучылар сөйләгән саен, яшь бер егет яки кыз, аланнан чын чәчәкләр өзеп, букет китерә торды. Чәчәк бирүнең бу яңа төре атналыкка чыккан иптәшләргә ошап куйды. Әмма шул ук чәчәк бирүчеләр соңыннан татар һәм башкорт язучыларына зур таләпләрен дә куя башладылар. Тәтешле китапханәсеннән Гәраева иптәш: «Авыл сәхнәләре өчен пьесалар, интермедияләр, куплетлар һәм скетчлар эзли-эзли күзләр тонып бетә», диде. Чыннан да, авыл пьесаларга бик мохтаҗ. Бәлки шуңадыр, башкорт драматургы Әсхәт Мирзаһитовның яңа пьеса укуын һәр авылда бик кызыксынып тыңладылар. Очрашулар вакытында ул, берәр картиналап, пьесасын бөтенләе белән укып чыкты. Тагын шул ягы бар: Әсхәт Мирзаһитовның кайчандыр сәхнәдә уйнавы, тигез көр тавышы кичәләрне алып барган чакта бик ярап куйды, аның сүзе салмак һәм җитди яңгырады.

Яңавылның беренче урта мәктәбендә булган зур һәм кызыклы очрашудан соң, атналыкка чыккан татар-башкорт язучылары ике төркемгә бүленделәр. Икенче төркемдә башкортның өлкән шагыйре Гайнан ага Әмири, Казаннан шагыйрь Нәби Дәүли, Әлмәттән Рафаил Төхфәтуллин, Алабугадан Эдуард Касыймов, Уфада чыга торган «Пионер» журналының редакторы, гаҗәеп җор табигатьле юморист шагыйрь Марат Кәримов керде. Алар «Буй» совхозында, Яңа Уртавыл мәктәбендә, Ямады, Эткенә, Айбүләк, Карман авылларында — барлыгы сигез урында очрашу үткәргәннәр. Бу төркемдәге язучылар Карманда үткәрелгән культура работниклары семинарында һәм Карман ГРЭСы төзелеше эшчеләре алдында да чыгыш ясаганнар. Алар үзләре белән бик күп мәзәкләр, үткен сүзләр, тормышның кызыклы вакыйгаларын алып кайттылар. Башкортстан кымызын, ачык һавада, кыр вагоннарында төн кунуларын матур бер истәлек итеп сөйләделәр.

Ике төркем Яңавылда тагын очрашты. 5 июньдә Яңавыл район культура йортында йомгаклау кичәсе үткәрелде, китаплар сату оештырылды. КПССның Яңавыл райкомы һәм райбашкарма комитеты әдәбият атналыгында башкарган эшләре өчен Татарстан язучылар союзының Әлмәт бүлеген һәм аерым язучыларны Почет грамоталары белән бүләкләде. Моңарчы язучыларга авылларда почетлы пионер һәм почетлы колхозчы исемнәре бирелгән иде.

Калган ике көнебез Уфада узды. Ямьле Агыйдел буена, биек тау башына менеп утырган соклангыч каланың истәлекләрен кыска гына юл язмаларына сыйдырып бетерү мөмкин түгел. Гаҗәеп киң күңелле, кунакчыл башкорт язучылары безне Совет власте елларында төзелгән яңа зур Уфа белән таныштырдылар, мәҗлесләргә чакырдылар. Башкортстанның башкаласында бакча-паркларның күп булуы таң калдырды. Курай моңнарын тыңладык. Дала кебек киң дә, Агыйдел тугайларының ярсулы сулары кебек ашкындыргыч та көйләр әле дә булса күңелдә яңгырап, моңсу гына тирбәлеп торалар.

Әдәби атналык вакытында Уфаның Луначарский паркында Әлмәт дәүләт драма театры җәйге гастрольләрен башлап җибәргән иде. Анда татар драматургиясенең күренекле вәкиле Таҗи Гыйззәтнең «Ташкыннар»ы белән бергә, бүгенге язучыларның, атап әйткәндә Әлмәт язучыларының да, әсәрләре күрсәтелде. Спектакльләрне башкорт тамашачыларының яратып каравы, театр залларының тулы булуы әдәби атналыкка тагын да ямь өстәде. «Кызыл таң», «Совет Башкортстаны» газеталарында әдәби битләр, аерым язучыларның әсәрләре, атналык турында информацияләр әледәнәле бирелеп барды. Ике кардәш республиканың, туган илгә күп итеп нефть бирүче, күп итеп игеннәр үстерүче ике туган халыкның дуслык хисләре чагылды бу сәхифәләрдә.

Мондый очрашулар тугандаш әдәбиятларны тагын да якынайта икән. Без башкорт язучыларын, шагыйрьләрен, драматургларын әлек тә укып бара идек, бу юлы ничектер якыннанрак белдек. Башкортстанның халык шагыйре, балаларча кызыксыну сәләтен үзендә саклап калган яшь күңелле Мостай Кәрим, кешеләр белән мөгамәләдә судагы балыктай йөзүче Нәҗар Нәҗми, шигъри табигатьле Муса Гали, алы һәм күче

күңелле Кадыйр ага Даян, фәннәр докторы, халыкчан юморга бай Кирәй ага Мәргән, кырыс чырайлы, ләкин киң күңелле Гыйлемдар Рамазанов, Агыйделне өзелеп яратучы Хаким Гыйләҗев, сүзен үлчәп кенә әйтә, әмма бер әйтсә, берәгәйле әйтә белүче лирик хикәяче Фәрит Исәнгулов, кай ягы беләндер барысыннан да үзгә Ахияр Хәкимов, революция темасына турылыклы яшь прозаик Вазих Исхаков, кызлар йөрәген бер күрүдә яндырып ала торган яшь һәм чибәр шагыйрь, баянчы Рафаил Сафин, башкорт далаларының елъязмасын алып баручы Рәмил Хәкимов, моңлы тавышлы Кәтибә ханым Киньябулатова, басынкы табигатьле Рәми Гарипов, усал тәнкыйтьче Гайсә Хөсәенов — зур башкорт әдәбиятының шушы вәкилләре белән генә очрашу да күңелдә тирән тойгылар калдырдылар.

Күптәнге дустыбыз Шәриф Биккол больницада авырып ята икән. Без аны юл уңаенда гына күреп, күрешеп чыга алдык. «Күңелем гел сезнең белән булды, телевизор янына утырып, политмәгариф клубындагы дуслык кичәсен башыннан азагына тиклем карадым,— диде ул.— Озакламый чыгармын инде, үзебездәге очрашуларда була алмавымның каруын Татарстанга барып кайтарырмын». Оптимист дустыбызның күңел күтәренкелеге безгә бик ошады. Без аның тизрәк терелеп чыгуын теләдек.

Һәм менә поезд безне Татарстанга алып кайтып китте. Күңелләрдә әллә ничек моңсу да, сөенечле дә. Башкортстанның башкаласы белән танышып йөргән чакта без Мәҗит Гафури, халык шагыйре Рәшит Нигъмәти, яшьләй һәлак булган революционер Шәһит Ходайбирдин һәм башкорт халкының милли герое, мәкатдәс улы Салават Юлаев һәйкәленә баш иярга барып, аларга чәчәкләр салып, гөлләр утыртып кайткан идек. Башкортстан җирендә үскән гөлләрне без үзебезнең туган якларга да алып кайтып утырттык. Башкорт дусларыбыз безгә кунакка килгән чакта шушы гөлләр аларны каршы алып, чәчәк атып утырсыннар иде!

ШАҺИДӘ МАКСУДОВА.

## *Халык мәзәкләре*

### ФАҖИГА

Агай урманнан кайтып килә икән. Шул вакыт капка астыннан зур эт чыгып ташланган моңарга. Урманчы каушап калмаган, биленә кыстырган балтасын алган да этнең маңгаена тондырган.

Эт хуҗасы агайны хөкемгә чакырткан.

Казыйның:

— Ни өчен этне балта сабы белән генә куркытмадың, үткен ягы белән чаптың,— дип соравына агай:

— Эт тешләр өчен арты белән килгән булса, мин дә балтаның сабын гына күрсәткән булыр идем, алай итмәде шул,— дип җавап биргән, ди.

### НИ ӨЧЕН

Бервакыт Хуҗа Насретдиннан:

— Әйт әле, Хуҗа, ни өчен без башта яшен яшьнәвен күрәбез, ә күк күкрәвен бераздан гына ишетәбез? — дип сораганнар.

— Күзләребез колакларга караганда алдарак урнашканга,— дип җавап биргән Хуҗа.

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

*Фәрит Хатипов*

## «ИХТЫЯРСЫЗ» ГЕРОЙЛАР ҺӘМ КЫРЫС ДӨРЕСЛЕК

### I

Соңгы елларда дөньяга чыккан әдәби әсәрләр арасында аеруча шаулы бәхәс куптарганы Аяз Гыйләжевның «Өч аршын җир» повесте булгандыр. Хәзер инде әсәр хакында уртак бер фикер утырды шикелле. Ул, «Дружба народов» журналында русча басылып, бүләккә лаеклы дип табылды, башкала матбугатында уңай бәя алды һәм рус телендә аерым китап булып басылды. Ләкин әүвәлге тискәре фикернең дә әле бераз шаукымы калды булса кирәк. Чөнки шул ук авторның әлеге повестьтан соң язган «Зәй энҗеләре» инде аерым китап хәлендә чыкты, ә «Өч аршын җир» повесте журналдан читкә чыга алмыйча ята бирә. Монысы усал тәнкыйтьтән дә яманрак. Ул иҗат агачын тамырыннан корытырга мөмкин.

Сорау туа: бәя бирү белән эш тәгәлләндеме әллә? Ягъни әсәрнең идея ягыннан зарарсыз булуы исбат ителде, ә файдалы булуы дәлилләнмәде һәм шуңа күрә китап итеп басылмыймы? Чыннан да, бармы соң әсәрнең эстетик кыйммәте, художество яңалыгы? Булса, нәрсәдә ул?

Беренче карашка әллә ни[1] яңалык та юк кебек: колхозлашу чоры, кулак малаеның хәвеф килгәндә үзен-үзе чаккан чаян кебек, байлык-мөлкәтен туздырып, илен-җирен каргап качуы һәм шуңа бәйләнешле көрәш, кичерешләр тасвир ителә монда. Илебез тормышында, крестьяннар язмышында бик мөһим дәвер булганлыктан, бу елларның үтә киеренке, катлаулы, каршылыклы көрәше күп халыкларның әдәбиятында: роман, повестьларында, драма, поэмаларында мена инде 35 ел буена сурәтләнә килә. Шулай да үзенең төсен югалтканы юк әле: вакыт үткән саен теманың яңадан-яңа якълары ачыла бара. Әсәрләрдә кулак тибының да төрлесе күренде.

«Өч аршын җир»дәге баш герой Мирвәли үзенең иҗтимагый хәрәкәте, эш-гамәле белән моңарчы матур әдәбиятта сурәтләнгән кулак типларының берсенә дә якын тормый. Ул, сыйныфташларына кушылып, яңа тормыш төзүчеләргә каршы да көрәшми, хәрәкәтнең башына да килеп чыкмый, хәйлә-мәкер дә кормый, артельне яклап та аваз салмый. Кыскасы, язучы биредә без күрергә күнеккән, кискен бәрелеш-конфликтларга катнашучы, шуның белән әсәр сюжетына киеренкелек бирүче һәм, димәк, шактый отышлы саналган типны алмаган, бәлки үз эченә бикләнгән кулакның шул чор вакыйгаларына бәйләнешле психологиясен сурәтләгән. Икенче төрле әйткәндә, язучы аңлы рәвештә эффектлы, мавыктыргыч вакыйгаларны кираксенмичә, геройның эчке дөньясын яктыртуны мәгъкуль тапкан.

Кичерешнең нигезе монда барыннан да битрәк шәхси милеккә, байлык-мөлкәткә барып тоташа. Моңарчы безнең әдәбиятта башлыча урта халленең каршылыклы уй-тойгылары тасвирлана иде. Биредә исә кулак малаеның мөнәсәбәте сурәтләнә.

Бу мөнәсәбәтне бик туры сызыклы итеп тә күз алдына китерергә мөмкин. Ягъни, бай баласында тагын нинди мөнәсәбәт булсын, билгеле инде, комсызлык, ачкүзлелек, мал-мөлкәткә ябышып яту. Әмма язучы мәсьәләнең катлаулырак ягын яктыртә, милекчелек карашын кешедә була торган башка хис-тойгылар, кичерешләр белән бәйләнештә күрсәтә, бер очтан мәхәббәт, коллектив, туган җир, бәхет проблемаларын да күтәрә. Һәм нәкъ менә шулай итү аркасында, геройның эчке дөньясы тирәнтен ачыла. Безнең бурыч — психологик сурәтнең ни дәрәҗәдә реалистик һәм художество көче белән тасвирлануын күздән кичерү.

---

[1] А. Гилязов. Три аршина земли. Повесть. Москва. Издательство «Советская Россия». 1966 год. Тираж 150 000.

Иң элек милекчелек һәм мәхәббәт йогынтысының очрашуын карап карыйк. Игътибар итегез, Мирвәли үзенә яр итеп кызны байлар арасыннан, ягъни үз тиңнәре тарафыннан сайламый. Ярлы, ләкин аның каравы чибәр, уңган кызга гашыйк була. Күрәсез, кешелек тойгылары исәп-хисаптан алда йөри. Икесе дә берсен-берсе яраталар. Шуңа күрә алар уртак якларны гына беләләр, аерманы күрмиләр. Ләкин эш өйләнешүгә барып терәлгәч, әлеге уртаклык каядыр арткы планга чигенә дә, алга моңарчы искә-оска алмаган социаль тигезсезлек килеп чыга, хәтта хәлиткеч фактор ролен дәгъва итә башлый. Мәхәббәт белән сыйнфый тигезсезлек каршылыкбәрелешкә керә. Я мал, я мәхәббәт, икесенең берсен сайла, икесе дә берьюлы булмаячак, ди Мирвәлигә Шәйхразый бай. Бу конфликтны берәр ничек җимереп кенә хәл итәргә була. Мирвәли мәхәббәтне өстен таба. Байлыктан йөз чөереп, сөйгәне Шәмсегаян белән тора башлый. Алар социаль яктан да тигезләшәләр.

Шул ук вакытта бу җитди адым Мирвәлинең табигатенә-рухына да йогынты ясамый калмады. Кешелекле гүзәл хискә ирек биреп һәм гадел булмаган байлыкка бәйләп торган җепләрне умырып өзеп ташлап, Мирвәли мәгълүм дәрәҗәдә рухи дөньясындагы әшәке катламнардан, кулак өендә утырган юшкыннардан да арынып, чистарып калды, игенчеләр белән бергә эшләгән чагында сеңеп калган әйбәт сыйфатлары үсеп китте. Шуңа күрә дә Таифә әбидә кәҗә савып көн күргән чакларда яшьләр үзләрен иң бәхетле кешеләр дип саныйлар һәм ул көннәрне гомер буена күңелләрендә иң якты истәлек итеп саклыйлар.

Ләкин гаҗәп хәл: шул ук Мирвәли, мәхәббәт һәм байлык бәрелешендә тик йөрәк тавышына гына колак салган һәм ике дә уйламыйча йорт-җирен, дәүләт-милкен ташлап чыккан Мирвәли, кабат байлыкка тиенгәч, аңа теше-тырнагы белән ябыша. Ул малның авылдашларын талап җыелган икәнлеген белсә дә, җавап бирү көне килеп җиткәч, халыкка кайтарып бирергә теләми. Нәрсә булды соң? Әллә Мирвәлине алыштырып куйдылармы? Әсәрдә характер бөтенлеге һәм эзлеклелеге җимерелмиме? Җимерелми. Биредә тик мәгълүм бер социаль тип характерының төрле шартларда төрлечә чагылышы гына, язучының шуны оста тотып алуы гына күренә. Мирвәли кылган гамәлнең теге вакыттагысы да, хәзергесе дә аның өчен закончалыклы, табигый.

Беренчедән, яшь чагында Мирвәли байлыктан мәхәббәт хакына кул селтәгән иде. Ул мәхәббәткә ирешә. Хәзер шуңа тиң булырлык, мал-мөлкәттән баш тарттырырлык бүтән яңа идеал кирәк. Аның тирәсендә бар ул андый идеал. Хәрам байлыкны колхозга илтеп тапшырса, бу — аерым кешегә генә түгел, халыкка җиңеллек, куаныч китерер иде, гомер буе баш күтәрми эшләгән игенчеләргә тернәкләнеп китәргә, рәтле тормышка чыгарга аз булса да ярдәм итәр иде. Бу инде үзенең эчтәлеге белән мәхәббәт идеалыннан чагыштыргысыз зур, аерым кешене генә түгел, күпләрне бәхетле итү, халык бәхете идеалы. Ләкин Мирвәли моны күрми һәм күрә дә алмый. Положениесе ирек бирми.

Икенчедән, егет вакытында әле Мирвәлидә милекчелек психологиясе ул кадәр үк тирән тамыр җибәрмәгән иде. Чөнки ул әле хуҗа түгел иде. Хәзер ул хуҗа. Байлыкка кызыгу толкә төшкән. Умырып алу кыен.

Өченчедән, атасы исән чагында Мирвәли байлыкны үз кулына төшерү чарасын күрмәде. Мирас аңа үзеннән-үзе, Мирвәли ихтыярыннан башка күчте. Ләкин инде бер хуҗа булып алгач, бу үзгәреш Мирвәлигә тагын тиешле йогынтысын ясамыйча гына узмады. Нәкъ Ш. Бабичның «Газазил»ындагы кебек:

**Эчкә кергәч, төк ярылды урталай,**
**Килде чыкты уртадан шайтан малай...**
**Һәр адәмнең кальбенә урнашты ул,**
**Бар иман, вөҗданны аска басты ул.**

Шулай итеп, байлыкка, мал-мөлкәткә тиенү Мирвәлинең рухын тискәре якка үзгәртә, гарипләтә, әшәке холык-сыйфатларның, тойгы-хисләрнең, карашларның үсеп нығуына китерә. Мирвәлинең күңеле аның тормышта тоткан урынына җайлана. Кыскасы, әтисе үлгәч, Мирвәли башта югалтканын да таба: сөйгәне дә бар, мал да бар. Ләкин бу тапканы икенче зур нәрсәне — кешелек сыйфатларын югалтуга сәбәпче була.

Исәп-хисап көне килеп җиткәч, бүтән бертөрле дә юл күрмәгән Мирвәли асыл кием-туннарын «кин йөзле балта белән утын түмәренә салып» тураклый («этләргә тану сөртерлеге дә калмасын»), келәт-келәт, лар-лар торган ашлыкларын көл белән, дегет, керосин белән бутый, мал-туарын агулый.

## II

Дуамаллык, үзсүзлелек, үҗәтлек белән эшләгән шушы эш Мирвәлинең һәм аерууча бер гөнаһы да булмаган Шәмсегаянның моннан соңгы бөтен тормыш юлына йогынты ясый. Димәк, бу — төп геройлар язмышында аеруча әһәмиятле вакыйга. Ләкин шулай булуга карамастан, язучы аны теманың үзәге итеп алмаган. Теманың үзәге — халыкка каршы кылган гамәлең өчен халык алдында җавап бирүнең авыр булуы, вөҗдан газабының тирәнгә китүе. Ә үткәндәге күренешләр бары тик искә төшерү, уйлану рәвешендә генә биреләләр. Ягъни әсәр Мирвәли тормышының иң критик моментында, каршылыклы психологик кичерешләр арасында буталып, шуларның бер очына чыгарга җыенган чагында шушы катлаулы кичерешләрне искә төшерү рәвешендә язылган. Ни өчен шундый форманы кулай күргән язучы?

Ике планлы композиция, ягъни беренче планда үткәннәрне сурәтләү, икенчесендә бүгенге хәлләрне тасвирлау барыннан да бигрәк әсәрнең темасына, төп геройның рухи халәтенә бик тәнгәл туры килә. Ютга

чыкканнан бирле Мирвәли алдында һәр даим бер сорау тора: әгәр инде кайтырга туры килә икән, шулай кирәк икән, авыл ничек каршы алыр аны? Авылдашларына ничек күренер? Тормышындагы бәхет-шатлыкны да, аннан да битәр мул булып килеп торган кайгы-хәсрәтне дә, кыенлыкларны да уртаклашып яшәгән, ләкин бервакытта да уфтанмаган гомерлек юлдашы Шәмсегаянны авылга алып кайтып җирләү алдыннан Мирвәли, телиме, теләмиме, бөтен тормышына йомгак ясарга, анализлап карарга тиеш була. Әсәрдә бик тирән мәгънәле художество детале бар: 58 яшь, 58 километр. 58 яшь — үткән гомер, 58 километр — туып-үскән авылга барасы юл. Әсәрдә алар бер-берсенә контраст куелалар. 58 чакрым үткәч, син 58 еллык гомереңне, гамәлең турында авылдашларың алдында хисап бирергә тиешсең. Димәк, әлеге ике план бер-берсенә бәйләнешсез янәшә ике сызык кына яки берсе икенчесенә фон булып кына бармый икән, бәлки берсе икенчесеннән аерылгысыз икән.

Әйтергә кирәк, югарыдагы сорау бер Мирвәли өчен генә түгел, хәтта бүгенге тәнкыйть өчен дә шактый катлаулы булып чыкты. Барлык тәнкыйтьчеләр дә, шул исәптән төпле, җитди мәкалә язып чыкканнары да, Мирвәлине авылда калдыру белән килешмиләр. Чөнки болай сурәтләгәндә һәммәсен дә гафу итү, кичерү фәлсәфәсе үткәрелә, дип саныйлар. Р. Фәизова моңа каршы чыга кебек. Бөтенесен дә гафу итү идеясенең эзе дә юк, ди ул «Литературная газета»да. Ләкин шунда ук Мирвәли гомергә булмаса да беркадәр вакыт авылдан китеп торырга тиеш иде, ди. Моның белән килешеп булмый.

Чыннан да, беренчедән, авылдашлары Мирвәлигә бөтенесен дә кичермиләр. Ләкин шул ук крестьяннарның табигатенә киң күңеллелек тә сыя бит әле, ягъни бөтенесен дә кичермәү белән киң күңеллелек үзара килешмәүчән төшенчәләр түгел. Мирвәли, В. Гюгоның Жан Вальжаны кебек, гомер буена туган җиреннән читтә, качып яшәргә тиеш түгел иң. Замана башка, җәмгыять башка.

Икенчедән, Мирвәли болай да инде үзен аз җәзаламады. Ул бөтен барлыгы белән игенче кеше. Бары тик ашлык исен тоеп яшәү өчен генә ул эшкә тегермәнгә керә. Авылдашлары игенгә тилмереп торган чагында ашлыкны, терлекне әрәм итү кешелексезлек икәнлеген крестьянның аңламавы мөмкин түгел. Мирвәли моны сизә, һәм шуны хис бик озак еллар буена аның күңеленең, аңының кайсыдыр почмагында бик тирәндә яшеренеп ята. Суд хөкеменнән дә бигрәк әнә шул тойгы аңа авылдашлары күзенә күренергә ихтыяр куймый, аны кечкенәдән аунап үскән басу-кырларыннан читтә тота. Хәтта хатыны үлем ятагында ятканда да аның башында тик бер генә уй: бәлки Казаннан авылга Шәмсегаянны үзен генә җибәреп булыр, яңа больницалы авылдан гына борылырбыз, һич тә булмаса, кеше күрмәгән мәлне җирләп китәрмен. Кыскасы, әле һаман да кайтып кермәү ягын гына каера. Димәк, намус, вөҗдан борчуы шактый тирәнгә төшкән.

Әгәр дә колхозчылар шул утыз ел газапланган кешене авылдан борып җибәрсәләр, бу хәл игенчеләр табигатенә, аларның киң күңеллелегенә, безнең җәмгыятьнең гуманистик асылына каршы килер иде. Мирвәлидә кешеләр турында, авыл турында тик ямьсез, шыксыз тойгылар гына калыр иде. Дөресен әйткәндә, бу юлы китсә, ул кабат әйләнеп тә кайтмас иде. Моңа аның горур характеры ирек бирми. Әсәрдә без бер генә җирдә дә аның әйткән сүзеннән чигүен күрмәдек, аның каравы, үз дигәнчә эшләвен күп күрдек. Аның бәхете дә, фаҗигасе дә шул баш бирмәүчән холкыннан килеп чыга.

Хикәяләүне ике планлы итеп оештыруның башка сәбәпләре дә бар булса кирәк. Иң элек андый форманың тик бер «Өч аршын җир»гә генә хас булмаганлыгы күренә. Р. Тәхфәтуллинның «Йолдызым» (1961), С. Батталның «Сигезенчесе кем?», (1962), Э. Касыймовның «Гомер ике килми» (1963), Л. Леоновның «Рус урманы» (1956), И. Шамякинның «Уч төбендә йөрәк» (1964), Ч. Айтматовның «Җәмилә» (1962), «Җир-ана» әсәрләре, кайбер кинофильмнар («Чистое небо») шул рәвешле төзелгән.

Күренүенчә, алар башлыча соңгы вакытта, 60 нчы еллар тирәсендә иҗат ителгәннәр. 40 нчы елларда, 50 нче еллар башында андый композицион алым ул кадәр күп күренми. Шулай булгач, сәбәпне бәлки соңгы еллардагы яңалык, үзенчәлекләрдән, бүгенге заманның рухыннан эзләргә кирәктер. XX съездан бирле партия иҗтимагый фикерне уятырдай, уйландырырдай байтак мәсьәләләр күтәрде, үткәндәге кайбер гыйбрәтле күренешләргә күзне ачты. Партия күтәргән идеяләр бөтен җәмәгать фикеренә, заман рухына әйләнде. Табигый, алар интеллигенцияне, иҗатчыларны да рухландыралар.

Партиябезнең XX съездыннан соңгы яңа рухны чагылдыручы бердәнбер алым, әлбәттә, ике планлы композиция генә түгел. Ләкин шунысы да бәхәссез, шактый уңайлы, эстетик йогынтылы юл ул. Чыннан да, әлеге әсәрләрнең һәрберсендә диярлек узгандагы хәлләр бүгенге югарылыктан карап, шуңа мөнәсәбәттә чагылдырылалар, ягъни үткән көннәр чынбарлыгына бүгенге көн нуры төшерелә. Шулай итеп, узгандагы вакыйгалар бүгенге заман рухы карашыннан чыгып анализланалар. Теманы эшкәртүдә язучылар элекке традицияләрне дә дәвам итәләр, ләкин шул ул вакытта аларга яңалыклар да өстиләр. Бүгенге көн югарылыгыннан күренә торган мәсьәләләрне күтәрәләр.

Халык көче белән җыелган байлыкның халыкка кайтарылырга тиешлеге А. Гыйләҗев әсәрендә дөрес күрсәтелә. Шуның белән бергәттән әлеге «Өч аршын җир»дә, Ф. Хөснинең «Утызынчы ел»ында, бигрәк тә С. Залыгинның «Иртыш буенда» повестенда кешегә сак мөнәсәбәт идеясе дә уздырыла. Бу авторлар, кулакка каршы көрәшнең кирәклеген тасвирлау белән бергәттән, кайбер очракларда урта хәллене яки рухи

яктан кулак идеологиясе белән бәйләнмәгән игенчеләрне урыннарыннан кузгатуны саксызлык күрсәтү дип бәялиләр. Дөрестән дә тарихта андый хәлләр дә булды...

Язучы сурәтләгәнчә, Мирвәлигә карата башка кулаклар белән бер иштән диярлек карар чыгаралар. Ягъни әгәр дә мәгәр атасы малыннан үзе теләп баш тартса — кагылмаска; моңа әзер түгел икән — байлыгын тартып алып, үзен авылдан сөрергә... Ләкин бүтән кулакларга карата тулысынча дөрес булган карарның икенче яртысы Мирвәлигә карата бик үк гадел булып чыкмый. Чыннан да, Шәйхразый бай малын конфискацияләү урынлы, әмма Мирвәлине урыныннан кубару нигә кирәк булды? Хәйдәр карт әйтә бит:

«— Соңгы елларда атаң хуҗалыгына бөтенләй кулың кермәде. Моны барысы да беләләр. Шуның өстенә, ятим карчыкны да үз яныңа сыйдырдың...»

Димәк, авылдан куылырлык гөнаһысы юк аның.

«— Минне җылы түшәгемнән торгызып салкын урамга чыгарырга кемнең хакы бар иде... Кулак малае булуыма мин үзем гаепле мени». («Совет әдәбияты» журналы. 1963 ел, 6 сан, 25 бит.).

Шәхес культы чорында мондый сораулар куелмый, читләтебрәк үтелә иде. Хәзер куела. Аз гына гаделсезлек күренеше дә яңадан кабатланмасын, тамыры йолкып алынсын өчен куела ул. Һәм монда безнең җәмгыятьнең гуманистик асылы, демократик принципларны һаман ныгыта баруы чагыла.

## III

Читтә яшәгәндә Мирвәли туган авылы өчен күңелендә урын калдырмаган икән, бер үк вакытта ул сөеп алган, мәхәббәт белән яшәгән тормыш иптәше Шәмсегаян өчен дә күңел капкасын бикләп куярга тиеш була. Чөнки Шәмсегаян — туган якны хәтерләтүче, искә төшереп торучы берданбер зат. Авылы белән бергә Мирвәли гүяки Шәмсегаянны да хәтереннән сызып ташлый. Авылын ерак булып күрми, хатынын янәшә булып күрми. Бу — Мирвәли фаҗигасенең яна бер ягы, рухи гарипләнә баруының бер дәлиле.

Чынында исә шундый туң мөнәсәбәткә генә лаеклы кешеме соң Шәмсегаян? Ф. Мусин аны героик сыйфатлардан арындырылган, характерына «беренче чиратта аморфлылык, инертлык, ихтыярсызлык» хас булган, «бәхетсез семья тормышыннан зарланучы» дип бәяли һәм актив, принципиаль, зур ихтыярлы, тирән хисле хатынкызлар тибына полемик рәвештә каршы куелган кеше дип саный. («Совет әдәбияты» журналы. 1964 ел, 5 сан, 128 бит).

Мондый бәянең үзенә күрә чыганагы бар. Озак еллар буена без сәнгать әсәрләрендә, бигрәк тә социаль көрәш вакыйгаларын тасвирлаганнарында, кешенең күркәмлеген башлыча политик сферада күрергә гадәтләнгәнбез. Чөнки биредә рухиәхлакый сыйфатлар мөлдерәмә тулы, якты булып чагыла. Әмма шушы яктылыкта башка матурлыкны, гүзәллекне тоймый башлаганбыз. Димәк, сиземләү, матурлыкны бәяләү үлчәме берьяклырак булып киткән. Реаль чынбарлыкта политик көрәшчеләрдән тыш әле тагын турыдан-туры сәяси көрәшкә катнашмаган, кеше күзенә бик ташланмый торган, әмма җәмгыятьтә бик кирәкле, мөһим эш башкаручы, үз урынында алыштыргысыз тыйнак кешеләр дә бик күп. Җәмгыять прогрессы өчен политик җитәкчеләр эшчәнлеге дә, шул җитәкчеләр күрсәткәнне артык пафоска бирелмичә шау-шусыз гына тормышка ашыручылар эшчәнлеге дә кирәк.

Шәмсегаян политик көрәшче дә түгел, бөтен кеше күрерлек биеклеккә дә күтәрелмәгән. Героик сыйфатларга ия булган шәхес тә түгел. Ләкин гади, тыйнак бер хатынкыз булганы өчен генә, Ф. Мусин раслаганча, ул «рәхимсез хөкем карарына» да лаеклы түгел. Аның үзенең күркәмлеге бар. Алып карыйк аның кешеләргә мөнәсәбәтен. Мирвәлиләр нигезенә кайткач, ире бик каты каршы торса да, Шәмсегаян Таифә карчыкны үзләре янына алдыра, ягъни изгелеккә тик изгелек белән генә җавап бирүне табигый саный. Мөлкәтне дәүләткә тапшыру турында сүз чыккач та ул иң акыллы киңәш бирә, гаделлек кушканча эшләргә өнди:

— Бер мәртәбә ташлап чыктың ич син аны, Мирвәли, — ди.

Янсә менә хезмәткә мөнәсәбәте. Үләренә берничә минут вакыт калгач, Шәмсегаян, яшьлегенең иң татлы ядкәре итеп, кыр эшен искә төшерә, кыен булса да аның бик тә күңелле, йөрәкләрне җилкендерә торган сихри бер куәте турында, сау-сәламәт кешедәй, илһамланып, ләззәтләнеп сөйли:

— Юкка гына безнең бабайлар иң яраткан кошларын сабан тургае дип, иң кадерле, иң күңелле бәйрәмнәрен сабан туе дип атамаганнар шул...

Тәндә яшәү көче күзгә күренеп дигәндәй беткән, сызып барган мәлдә игенчеләр хезмәтенә шулай дан җырлау өчен бу эшкә бик нык гашыйк булу кирәк.

Шәмсегаян образына характеристика биргәндә, Ф. Мусин төгәлсезлек тә җибәрә. Ул аны инерт, ягъни эшлексез, инициативасыз булуда гаепли. Ләкин бу дөрес түгел. Аңа берәү дә балалар бакчасында эшләргә тәкъдим итми. Ул үз ихтыяры белән, хәтта Мирвәли теләгенә каршы килеп, шушы эшкә керә. Бу — шулай ук инициатива. Дөрес, бик үк эре масштаблы түгел, ләкин бит Шәмсегаян масштабка дәгъва итми дә. А. Шамов әсәрендәге Рәүфәнең үз хокукын даулап тавыш бирүе җитди эдым булган кебек, Шәмсегаянның да җәмгыять өчен кирәкле эшкә катнашып китүе бик мөһим күренеш.

Тәнкыйтьче, ни өчендер, Шәмсегаянны «бәхетсез семья тормышыннан зарланучы» итеп күрергә тели. Әмма мәсьәлә киресенчә тора. Мирвәли Шәмсегаянның нәкъ менә зарлана белмәвенә таңга кала.

— ...Күпме юллар үттек без ул чагында синең белән. Кунмаган вокзал, кагылма-

ган шәһәр аз калгандыр. Синең жылы шәлнә төренеп азмы йокладык без. Нигә шул чагында син бер мәртәбә дә зарланмадың икән, — дип гажәпләнә Мирвәли.

Шулай итеп, бу фактлар Шәмсегаянның инерт, ихтыярсыз, зарланучы кеше булуы турында сөйләми, бәлки бик кешелекле, гадел, эш сөючән, ихтыярлы, юкка-барга көязләнми торган, кыенлыкларны сабыр жинә баручы хатын булуын күрсәтә. Бу сыйфатларга ия булуны теләсә нинди хатынкыз үзенә горурлык санар иде. Мирвәли янында ул балкып, нур сибеп торучы жан.

Димәк, моннан бер нәтижә. Геройны якты куе буяулар белән дә тасвирлап була. Ләкин күркәмлекне күрсәтү өчен жете төсләр генә им түгел. Тыйнак герой сыек төсләр белән сурәтләнсә дә бик сылу күренә икән.

Шәмсегаянның матур сынын гәүдәләндерү өчен әйтелгән кадәресе дә бик житкән иде. Ләкин автор әле моның белән чикләнми. Ул Шәмсегаянның рухи сыйфатларының иң күркәмен — туган жиренә, халкына мәхәббәтен, ялкынлы патриотизм тойгысын бөтен әсәрнең үзәгенә куйган. Туган якны өзелеп, чиргә сабышырлык дәрәжәдә сагыну хисе — повестьның сюжетын тудырган төп сәбәп. Озын сәфәргә чыгу да, Мирвәлинең юлдагы уйланулары да ахыр чиктә Шәмсегаянның ихтыярга куймыйча туган-үскән жиргә атлыгуына барып тоташа. Туган илне ярату туган жиргә мәхәббәттән башлана, ягъни ул абстракт төшенчә генә түгел, бәлки бик конкрет, индивидуаль хис итеп торган төшенчә. Димәк, биредә Шәмсегаян образы аркылы туган илгә мәхәббәт идеясе бик көчле художество чаралары, тирән психологик кичерешләр аркылы күрсәтелә икән.

Туган жирнең кадерле булу идеясе, икенче яктан, Карачура кешеләренең сүзләрендә чагыла.

— Өч аршын? Азмы әллә? Кадерле шул ул туган жир! Ай, кадерле... Күпме авылдашлар аның өчен чит жирләрдә башларын салдылар... Каты бәгырьле димә, минем ул жир өчен чын-чынлап даулашырга хакым бар. Өч аршын жир... Күп сорыйсың син, Мирвәли!..»

Биредә фикер, сүзләрнең мәгънәсе ачык әйтелгән. Алар үзләре өчен үзләре сөйләп торалар. Әмма сәер хәл, кайбер иптәшләр әлеге туры сүзләрдән кыек мәгънә чыгардылар, әсәрдән ниндидер өч аршын жир фәлсәфәсе эзләп азапландылар. Кайбер язучыларда туган илнең бер карыш жире дә газиз дигән әйләнмә очрый. Ул чагында аларны тагын да кечерәк фәлсәфә, бер карыш жир фәлсәфәсе өчен тәнкыйтьләргә кирәк булыр иде. Әмма андый логика белән барсаң, тузга язмаган нәтижәләргә килеп чыгарга мөмкин.

Әсәрнең фәлсәфәсе бар, әлбәттә. «Өч аршын жир» әсәре художникның укучыга әйтер сүзе, яңа фикере булганга күрә язылган ул. Ләкин бу фикер кайбер тәнкыйтьчеләр уйлаганча түгел. Геройның зур художество көче белән сурәтләнгән катлаулы һәм гыйбрәтле язмышы, әрнүле кичерешләре аркылы язучы түбәндәгеләрне раслый.

Кешелекле матур тойгы-хисләргә иркен үсәргә юл кую кешенең күңелен никадәр бизәсә, нормаль булмаган тормыш рәвеше кешенең табигатен шул кадәр гарипли, ямьсезли.

Кешенең рухи, мораль, физик сәламәтлеге барыннан да бигрәк туган жир туфрагыннан, халык белән рухи якынлыктан азыклана. Алардан аерылу фажигагә тиң.

Теләсә нинди очракта да, шул жөмләдән катлаулы көрәш шартларында да, кешегә сак мөнәсәбәт күрсәтү — социалистик законлылыкның мөһим таләбе ул.

Ә кайда соң бүтән төрле фәлсәфә? Әлеге яман аты чыккан өч аршын жир фәлсәфәсе? Юк андый фәлсәфә, үзе дә, дәлиле дә юк. Ул ничектер ялгышлык белән генә кайбер иптәшләрнең башында туган. Чынында исә повесть гуманистик идеяләрне раслый.

## IV

Әсәрнең стилен повесть нигезенә салынган ике үзенчәлек: психологик сурәт һәм искә төшерү формасы билгели. Психологик тасвир биредә художестволы идеяне образлы, йогынтылы рәвештә гәүдәләндерүнең мөһим чарасы буларак кулланыла. Шәмсегаянның кичерешләре гелән даими, бер ноктага төбәлгән булса, Мирвәлинең үтә каршылыклы, катлаулы, газаплы. Аның кичерешләренең юнәлешендә тышкы вакыйгаларның роле шактый зур. Язучы аларның кеше күңеленә нинди йогынты ясавын, кайда таба борып жибәрүен күрсәтә. Мирвәлигә бәйле һәм бәйсез булган төрле хәлләр аның күңеленә төрлечә эз сала, бер очракта аның рухи дөньясын баетып жибәрәләр, икенче очракта бөтенләй ярлыландырып, шыксыз итеп калдыралар. Шулай итеп, язучы биредә ижтимагый вакыйгаларның әһәмиятен кеше хисләренә ясаган йогынтысы аркылы, икенче төрле әйткәндә кеше күңелендәге чагылышы аркылы, күрсәтә. Киеренке вакыйгалар аркасында хасил булган психологик кичерешләрне тасвирлау ягыннан А. Гыйләжев монда бөек рус язучыларының матур традицияләрен дәвам иттерә.

Художество детальләре дә бары тик психологик кичереш белән бәйләнештә генә үзләренең асыл сыйфатларын ачып салалар. Аерым тына алып карагалда «Рельслар озак кына гүелдәп, сызланып тордылар» дигән жөмләдә әле искитәрлек артык бернәрсә дә юк. «Сызлану» сүзен гади бер сынландыру дип кабул итәргә мөмкин. Ләкин әсәрдәге контекстта, геройлар кичереше белән бәйләнештә икенче төрле, ягъни тирәнрәк йогынты калдыра ул. Чирле Шәмсегаян, бөркү вагонда ары барырлык хәле калмаганлыктан, медицина кушуына буйсынып, поездлан төшеп кала. Ахыр чиктә ул тормыштан, тормыш поездыннан төшеп кала. Ул кала, поезд китә. Әнә шул вакытта рельслар гүелдәвен художник сызлану дип кабул итә. Ул авыру хатынның рухи халәтенә, күңел сыкравына туры кила, гүя

ки, бу мизгелдә адәм баласы да, җансыз предмет та бер-берсен бик тирәнтен аңлыйлар. Шуңа күрә әлеге сүз табигый, килешле дә, шул ук вакытта экспрессив тирән мәгънәле дә.

Яки менә икенче бер мисал. Больница ишек алдында утырганда Мирвәли хатыны турында болай уйлана: «Юк, монда үләргә ярамый. Һич! Врач белән дә, Шәмсегаян белән дә сөйләшергә кирәк». Тагын автор дәвам итә: «Ул керер, Шәмсегаянга бирешмәскә, нык булырга кушып чыгар. Терелсен».

Сәер яңгырый, дөрес бит? Әйтерсең, үлем кемнең дә булса кушу-кушмавы, ярауярамавы белән исәпләшеп тора. Ихтыярында булса, Шәмсегаян чакырылмаган кунак— үлемне бер чакрымнан куып җибәрер иде. Кыскасы, «монда үләргә ярамый» икәнен ул болай да, «сөйләшмичә», «кушмыйча» да аңлый. Димәк, Мирвәлинең бу хактагы сүзләре, уйлары урынсыз кебек. Әмма үзенче Мирвәли хәленә күеп кара: нәкъ шул урында, шул мәлне әйтелә торган сүзләр алар. Мирвәлинең кичерешен бик төгәл аңлаталар.

Моңарчы әле Мирвәли хатынының чынлап авыруына ныклап ышанып та җитми, авыл һавасын күкрәк тутырып сулагач, арыш исен иснәгәч, терелеп китәр дә, Карачурага кайтмыйча, шушыннан гына борылырбыз, дип өметләнә. Мәңгелеккә аерылышу ихтималын уена да китереп бакмый. Һәм кинәт, шомлы сизенү, башына күсәк белән органдай, аны миңрәүләтеп, исәнкерәтеп җибәрә. Ләкин монда да ул фаҗиганең ачы мәгънәсеннән дә бигрәк мәетне Карачурага илтеп җирләү һәм, димәк, авылдашлар белән очрашу хәвефе турында гына баш вата, икенче төрле әйткәндә, вөҗдан борчуы бер мизгелгә олы кайгыны да каплап тора. Шуңа күрә хатынына монда үләргә «рөхсәт бирми». Шул рәвешчә, әлеге деталь кешенең эчке дөньясының бик катлаулы хәлен күрергә мөмкинлек бирә.

Образ тудыруда төп чара итеп психологик сурәтне сайлаган язучылар гадәттә күңел тибрәнешләрен бик җентекләп, ювелирларча бөртекләп тасвирларга яраталар. Ләкин «Өч аршын җир»нең стиленә психологик тасвирдан тыш әле тагын икенче үзенчәлек тә — искә төшерү формасы да йогынты ясый. Әгәр психологик анализ тәфсыйлле сурәтне кулай күрсә, искә төшерү формасы аңа каршы төшә һәм җыйнак сурәтне таләп итә. Хикәяләүне киеренке ноктадан башлап, аңа кадәрге вакыйгаларны искә төшерү рәвешендә тасвирлаган язучылар аеруча мөһим күренешләргә тукталырга, җегәрлекле, сәллы мәгънәле художество чараларын сайлап алырга һәм шулай итеп әсәрне нык мускуллы, тыгыз тәнле итеп төзәргә яраталар. Бу сыйфат «Өч аршын җир»дә дә тулы чагыла.

«Сүзе кыска иде картның...

Мирвәлинең сүзе аннан битәр кыска булды.

— Ярар.

Ул Шәмсегаянны иртте дә авыл читенә, япа-ялгызы ничарадан-бичара тереклек кылып азапланган ятим карчык Танфә йортына барып урнашты».

Күрәсез, тасвир үтә җыйнак. Хәтта бераз коры сыман. Гүяки, язучы аңлы рәвештә детальләрне читсенә. Ләкин чынында алай түгел. Психологик анализ белән искә төшерү формасы бер-берсенә бәйләнгән кебек, җыйнак сурәт белән детальләр бик тату үрелеп бараләр. Чыннан да, Мирвәлинең өеннән куылуын, шушы мөһим вакыйганы бер-ике сүз белән саран гына аңлаткан язучы урман эчендәге чишмәдән ат сугару күренешен, фуражка белән су ташып эчерү детален шактый иркенләп тасвирлый. Нечкә күзәтүчәнлек белән тотып алынган детальләрдә язучының сәнгатьчә ачышлары, тормышны образлы сыны белән күрү осталыгы чагыла. Моны аеруча мисаллар ярдәмендә күрсәтү җайлы.

«Тимер юл буендагы калкулыкта, **бастырыгын иң өстенә салып**, вәкарь белән генә саескан йөренә».

«Тургайлар **зәңгәр гөмбәзле өйләрендә** рәхәтләнеп чырылдыйлар».

«Моны Мирвәли генә түгел, **ат та** сизде, башын күтәреп, колакларын ялт-йолт уйнатып, **кара күләгәләр эреп яткан куак асларына** карап бара башлады» һ. б.

Бу метафоралар, чын сәнгать әсәренә хас булганча, гадиләр дә, шул ук вакытта индивидуаль яңгырашлы һәм образлы фикерләү культурасы үсешен исбатлый торган матурлык та бар аларда. Өр-яңа образлы бизәкләр әсәргә гомумән бик мул сибелгән, сүзлек составы өлкән буын язучыларыныкы шикелле бик бай.

Билгеле, әсәр композициясендә җыйнак тасвир белән индивидуаль детальләрнең урнаштырылуында мәгълүм бер эзлеклелек, закончалык бар. Җыйнак тасвир, башлыча үткәннәрне искә төшергән бүлекләрдә күбрәк очраса, индивидуаль детальләр бигрәк тә бүгенге көндәге кичерешләрне сурәтләгән бүлекләрдә зуррак урын ала. Бүлекләр аралашып барганлыктан, җыйнак сурәт белән психологик детальләр дә үзара үрелешеп килләр.

* * *

Җыеп кына әйткәндә, әсәр кеше күңеленең күркәм якларын да, ямьсез якларын да, ямьсезләткән сәбәпләрне дә күрсәтә, укучыны уйландырырлык мәсьәләләр яктырта. Болар һәммәсе дә әйбәт сәнгать югарылыгында, үзенчәлекле стильдә тасвирланган. Димәк, тәнкыйть әсәрне бер тавыштан хуплап каршы алырга тиеш иде. Чынлыкта алай булып чыкмады. Кайбер иптәшләр үтә салкын кабул иттеләр һәм бу салкынлыкны повестьта булмаган гөнаһлар белән нигезләргә тырыштылар. Сәбәп нәрсәдә соң?

Дикъкать беләнрәк карасак, менә нәрсә күзгә бәрелә. Безнең иҗтимагый тормышның асылы үсеш, төзү, прогресс бул-

ганлыктан, әдәбият һәм тәнкыйть тә төп игътибарын, табигый, шушы уңай сыйфатка юнәлдерә. Ләкин кайчак аерым иптәшләр дөрес күренештән хата нәтиҗә ясыйлар, ягъни безнең әдәбиятның бердәнбер сурәтләү предметы тик уңай башлангыч кына дип раслыйлар һәм гамәлдә тискәрене гәүдәләндерүгә каршы чыгалар. Тәҗрибәле тәнкыйтьче Х. Хәйри иптәш болай дип яза: «Социалистик реализм иҗтимагый тормышка, халык тормышына ят булган, рухи ярлы кешеләрнең вак хисләрендә казынуга, рухи гариплек эстетикасына каршы». («Казан утлары» журналы. 1965 ел. 10 сан, 134 бит.)

Беренчедән, андый берьяклы караш, ягъни якты күренешләрне генә сурәтләп, караңгы якларга күз йомарга димләгән чакыру бернинди рәсми документларда да беркетелмәгән. Икенчедән, «рухи ярлы кешеләрнең вак хисләрен» тасвирлау белән «рухи гариплек эстетикасы» бер үк түгел. Чөнки язучы түбән күренешләрне тасвирлап та югары эстетик һәм гражданлык идеалын үткәрә ала. Әгәр дә бер үк дип санасак, безгә байтак критик реалист-классиклардан баш тартырга туры килер иде. Өченчедән, бу рәвешле раслау әдәбиятның гражданлык активлыгын, тискәре көчкә каршы көрәшү үткенлеген киметә. Берәүгә дә сер түгел, мәгълүм бер вакытта аерым язучылар, берьяклы лозунгка бирелеп, тормыштан шактый аерылдылар, казанышларны чамасыз кабартып сурәтләделәр һәм үсешкә комачаулый торган реаль житешсезлекләрне күрү сәләтен, бу өлкәдә партиягә, халыкка ярдәм итү сәләтен бөтенләй югалта яздылар. Монда да партия үрнәк күрсәтте. Ул безнең халкыбызның иң матур идеалларын чагылдыра, шул ук вакытта житди иҗтимагый кимчелекләрне дә ачып сала. Чөнки уңай өчен көрәшү аны мактау белән генә чикләнми, бәлки аның юлын тискәре нәрсәләрдән әрчүне дә күздә тота. Кырыс дөреслек һәрвакытта да әдәбиятның сәламәтлеген күрсәтүче билге булды.

Нигездә уңайны яктыртырга чакыруның һәм тискәрене гәүдәләндерүгә каршы чыгуның тагын бер сәбәбе бар. Безнең җәмгыять тормышында массовый уңай күренеш аеруча типик булганлыктан, чагыштырмача аз таралган тискәре күренешнең типиклыгына аерым иптәшләр шикләнеп карыйлар. Әгәр язучы тискәре образ тудыра икән, ул бөтен җәмгыятьнең типик хәлен күрсәтергә дәгъва итә дип уйлыйлар. Чынбарлыкка яла яга дигән сүзләр әнә шуннан килеп чыга. Ләкин монда бернәрсә искә алынмый. Әсәрдә сурәтләнгән бөтен образ-типларның да гомумилек дәрәҗәсе, типның таралу мәйданы бердәй тигез түгел. Берәүләрнеке киң, икенчеләрнеке таррак була. Мәсәлән, Мирвәлинең типик гомумилеген «Агыйдел»дәге Гаяз, Ильяс, Артыкбикә, Имәли, Күчәрбай образларының гомумилегенә һич тә тиңләштереп булмый. Гаязлар, Ильяслар һ. б. киң таралган күренешне гәүдәләндерәләр. Хәтта социаль яктан якынрак торган Низами, Сәхәүләр дә Мирвәлигә караганда киңрәк таралган күренешне гәүдәләндерәләр. Мирвәли исә — индивидуальрәк язмыш кешесе. Тормышта андыйлар ниндирәк урын биләгән булса, язучы аларны шул урында сурәтләгән. Артык та түгел, ким дә түгел.

Шулай итеп, кайбер теоретик мәсьәләләргә ачыклык кертү әдәби әсәрләрне анлауга һәм бәяләүгә генә түгел, әдәбият үсешенә дә уңай йогынты ясаячак.

—●●—

## *Халык мәзәкләре*

### «АКЫЛГА» УТЫРТКАННАР

Карт белән карчык улларын өйләндергәннәр. Ләкин аларның киленнәре бик ялкау булып чыккан. Бер көн бабай кулына чиләк алган да, киленгә үч итеп, сыер саварга тотынган. Карчыгының бик ачуы килеп, үзем савармын дип картының кулыннан чиләкне тарта башлаган. Моны тәрәзәдән күреп торган киленнәре:

— Әткәй! Әнкәй! Бер чиләк өчен нигә шулкадәр тавыш куптарасыз. Бер көн берегез сауса, икенче көн икенчегез савар,— дигән.

### БЕР ҖЫЕЛЫШТА

Бригадир:

— Эх, йөкләмәләребез яхшы иде. Кызганычка каршы, үти генә алмадык.

Колхоз рәисе:

— Кайгырма. Менә хәзер яңасын, тагын да шәбрәген кабул итәбез.

*М. Госманов*

# Олы мирас

*Хөсәен Фәезханов 1821 елда элекке Сембер губернасы Кормыш өязендә Сабачай авылында дөньяга килә. Туган авылында һәм Бәрәскә мәдрәсәсендә беркадәр укыгач, ул, Казанга килеп, атаклы тарихчы, мөдәррис Шиһап Мәрҗанидән дәресләр тыңлый. Зур белемгә омтылган яшь Хөсәен, ирекле тыңлаучы сыйфатында Казан университетына йөри. 1853 елдан университетның шәрык бүлегендә татар, төрек, гарәп, фарсы телләре һәм каллиграфия буенча үзе дә дәресләр бирә башлый.*

*1855 елда шәрык бүлеге башкалага күчерелгәч, профессорларның тәкъдиме буенча, Хөсәен Фәезханов Петербург университетына эшкә бара. Петербургка килгәч, Х. Фәезханов ныклап торып белемен күтәрү өстендә эшли, тиз арада күренекле ориенталист-галим булып җитлегә. В. В. Розен, И. Н. Березин, В. В. Вельяминов-Зернов, А. К. Казимбек, В. В. Григорьев, Б. А. Дорн, П. И. Лерх кебек мәшһүр галимнәр белән хезмәттәшлек итә, шулай ук В. В. Стасов, Ч. Ч. Вәлиханов шикелле прогрессив акыл ияләре белән таныш, фикердәш була.*

*Ярлы, авыр тормыш яшь галимнең сәламәтлеген бик иртә какшата. 1866 елны ул үпкә авыруыннан үлә. Зур омтылышлар белән яшәгән талантлы галимнең күп хыяллары тормышка ашмый кала. Азатлык өчен көрәш һәм прогрессив идеяләр тәэсирендә формалашкан бу олы йөрәкле патриот галимнең эшчәнлеге һәрьяклап өйрәнергә лаек.*

Атаклы мәгърифәтче Хөсәен Фәезхановның эшчәнлегенә караган материалларның күләме соңгы елларда шактый арта төште. Күптән түгел генә аның дүрт-биш яңа хаты табылды. Аларның кайберләре белән җәмәгатьчелегебез танышып өлгерде инде. Шулар өстенә Х. Фәезхановның моннан илле ел элек матбугатта чыгып та хәзергә хәтле фән дөньясына кереп китә алмаган тагын утызлап хаты булуын да онытмаска кирәк. Дөрес, матбугатта басылып чыккан документлар турында «фәнгә кермәгән» дип әйтү беренче карауга килешеп җитмәс кебек. Ләкин биредә мәсьәләнең формаль ягы түгел, бәлки нәтиҗәсе күздә тотыла. Риза Фәхретдинов тарафыннан 1916 елны ук, ягъни Х. Фәезхановның вафатына 50 ел тулу мөнәсәбәте белән «Шура» журналының 14—19 саннарында басылган ул хатлар әлегә хәтле тарихчыларыбыз һәм әдәбиятчыларыбыз тарафыннан тиешлечә файдаланылмыйлар. Мәгәр алар Х. Фәезхановның иҗтимагый карашларын һәм гыйльми йөзен ачуда, хәтта күп кенә фәнни проблемалар тарихын өйрәнүдә дә алыштыргысыз чыганак булып торалар.

Х. Фәезхановның тормыш юлын, эшчәнлеген тиешлечә өйрәнмәү ул хатларның «онытылып» ятуларына сәбәп булса, аларның киң җәмәгатьчелеккә таныш түгеллекләре, үз чиратында, галимнең эшчәнлеген фәнни дөрес билгеләп, аңар гадел бәһа бирүгә дә тоткарлык иткәннәр.

Х. Фәезхановның «Шура»да басылган ул хатларының барысы да, 1856—1866 елларда язылып, атаклы галим Шиһап Мәрҗанигә адресланган; күпчелеге Петербургтан, кайберләре төрле авыллардан. Аларның оригиналлары кайда саклануы хәзергә билгесез.

Документлардан Х. Фәезхановның үз остазы Шиһап Мәрҗанигә карата гаять зур ихтирам саклавы күренә. Шул ук ва-

кытта бу хөрмәт коры нәзакәтлелеккә генә кайтып калмый: шәкерт үзен остаз алдында гади, иреклә, кирәгендә исә кыю да тота белә. Күрәсең, үз нәүбәтендә Мәрҗани дә Фәезхановка карата бик югары фикердә булган.

Беренче карашка бу хатлар хосусый документлар гына булсалар да, аларның эчтәлекләре шәхси мөнәсәбәтләр кысаларында гына калмыйлар. Алардан без киң карашлы ике галимнең заманында озак еллар буе үзләрен борчыган иҗтимагый, гыйльми мәсьәләләр буенча фикер алышып, фән һәм дөнья яңалыкларыннан мәгълүмат уртаклашып яшәүләрен күрәбез.

Х. Фәезхановның олы фән юлына чыгуы аның Петербург университетына күчүе белән бәйле. Анда ул алдынгы рус галимнәре белән якыннан танышып, фән өлкәсендәге барлык яңалыклардан хәбәрдар була башлый. 1856 елны Мәрҗанигә ул болай дип яза: «Аурупада һәркайда басма китап булса, шуны ике ай эчендә алмак мөмкин. Монда магазиннарда фиһрист (каталог, библиография) китаплар бар, һәртөрле китап басылса, тәмам Фәрангстанга (Европага) мәгълүм буладыр. Көтепханәләрдә булган китапларның каталоглары басылмыштыр... — дип, гомуми мәгълүмат биргәч, конкрет мисал да китерә. — Хвольсон [1] дип бер мәшһүр галим катында «мәгъриб китабы Аурупада булмаса кирәк», — дип сөйләдем. Дәрхаль бер каталог китабы алып карады да: «Голландия дарелфөнүн көтепханәсендә бер нөсхә бар, шуннан башка йирдә юк», — диде» (№ 2) [2].

Гыйльми каталогларның файдалы булуын аңлаган һәм көнчыгыш телләрен яхшы белгән Фәезханов рус ориенталистларының игътибарларын җәлеп итә — алар аны каталог төзү буенча эшкә чакыралар. «Бу көннәрдә, — дип яза ул икенче бер хатында, — Академиядәге мөселманча китапларга каталог ясамага, тасвирламага шарт кылып, якын арада башламакчы буламын» [3].

Каталог төзү эшенә Фәезханов 1865 елның башында тотынган булырга тиеш: «Бу араларда икенче бер тоткарлык булып, рисаләмезне тәртип кылырга вакыт юк. Академиядә булган китапларга каталог тәртип итмәк илә шөгыльләндем». (№ 25).

Әйтергә кирәк, моннан 100 ел элек Х. Фәезханов төзегән ул каталоглардан, гәрчә алар кульязма килеш калсалар да, ориенталистлар озак вакыт файдаланалар.

Фәезханов халык кулында йөргән кульязма китапларның яңаларын табу, аларны гыйльми учреждениеләр яисә аерым шәхесләр өчен сатып алу эшенә бик актив катнаша. Чит илләрдә басылган китапларны булдыру чараларына да керешә ул. Төркиядә басылганнарын алдыруда Петербургтагы төрек илчеләреннән дә файдалана (№ 3) [4]. Н. Исәнбаттәге кульязмада мондый сүзләр бар: «Мөгаҗҗәм-әл-бөлдан» (китабы) Германиядә басылып ятадыр. Иншә-алла, бер елдан басылганын алырсыз».

Үзе тапкан яисә сатып алган китаплар өчен генә түгел, ул икенче берәүләрнең табышы өчен дә ихлас күңелдән сөенә: «Шәрхәл-әсар лит-тәхавине» тапкан икәнсез, мөбарәк булсын!.. Без ошбу тәбәррек нугай [5] йиремезне юкка гына яманлыймыз. Менә нинди газиз китаплар табыладыр» (№ 20).

Әгәр әһәмиятле әйбер табылды исә, ул җиң сызганып эшкә керешергә әзер, андый вакытта Академия исеменнән дә сөйли башлый: «Якут [6] «Мөгаҗҗәм-әл-бөлдан»ы Казанда күрдем дип боермышсыз. Бу хәбәр безем өчен олуг шатлык. Алкиндамы? [7] Бөтенме? Төзекме? Нинди юл илә

---

[1] Хвольсон Д. А. (1819—1911) — Петербург университеты профессоры; борынгы яһүд һәм классик гарәп телләре, шулай ук тарихи чыганаклар буенча зур белгеч.

[2] Һәр өзек саен журнал санын, битләрен кабат китереп тормас өчен, хатларның «Шура»да басылуын һәм журнал куйган тәртибе буенча номерларын гына күрсәтәбез. Аңлаешсыз архаик сүзләрнең иң авырлары хәзерге телдәге мәгънәдәшләре белән алыштырылды, яисә бик характерлы атамаларның тәрҗемәләре җәя эчендә бирелде.

[3] Өзек Нәкый ага Исәнбәттә саклана торган Ш. Мәрҗани кульязмалары тупланган китаптагы күчермәдән алынды.

[4] 1964 елгы археографик экспедиция вакытында Фәезхановның туган авылы Красная Горкада (Сабачай) пенсионер Г. Хәбибуллин тапшырган хатта да шундый ук мәгълүматлар бар. Ул хатның оригиналы Казан университеты китапханәсендә 1968 т. номеры белән саклана.

[5] Х. Фәезханов Идел буе татарларын шулай «нугай» дип атый.

[6] Якут ибн Габдулла әр-Руми әл-Хәмави (1179—1229) — атаклы гарәп галиме, сәяхәтче, географ; «Мөгаҗҗәм-әл-бөлдан» («Илләр сүзлеге») исемле энциклопедик характердагы әсәрнең авторы.

[7] Алкиннар — Казандагы татар байлары.

алмак мөмкин? Мирза[1] васыйтасилә хат языймы? Яки Академия исеменнән сорыймы? Яки анда шәкертләр вә мулла-лардан яздырмак яхшыракмы? Бу китапны өйрәнү өчен махсус Казанга бару һичнәрсә түгел. Сатарлык булсалар, бик фахиш хата булмаса, кыйммәт биреп алыр идек» (№ 10).

Бу китап белән Академия галимнәре дә бик якыннан кызыксыналар, махсус командировка белән Фәезхановны Казанга «йебәрмәк фикер кылалар» (№ 11).

Хатлардан Фәезхановның остазы Мәрҗанигә русча тарих китапларын сайлауда, кирәкле әдәбиятны үзендә булдыруда зур ярдәм күрсәтүе беленә. Н. Исәнбәттә саклана торган хатта мондый сүзләр бар: «Вельяминов[2] Касыймски ханлары тарихының икенче кисәген сезгә һәдия кылды», — дип, аны һәм башка китапларны да җибәрәчәген әйтә (№ 6). Шулай ук рус гыйлем дөньясында барган фәнни бәхәсләр, яңалыкларны да язып, кайбер күренекле шәхесләр турында характеристика бирергә дә онытмый ул: «Оренбургта булган Григорьевны безнең дарелфөнүнгә профессор кылдылар. Гомум көнчыгыш тарихыны дәрес кылачак. Үз сәнгатене яман белмидер, күрәм»[3] (№ 20).

Күбрәк гомум шәрык язма истәлекләре өстендә эшләгән һәм аларны яхшы белгән Х. Фәезханов татар халкының рухи культура мирасына караган ядкарьлекләр турында да якыннан кайгырта. Күренекле татар укымышлысы Әбүнасыйр Курсави әсәрләре турында үзенең бик югары фикердә булуын әйтеп, аларны бастырып чыгару мәсьәләсен куя һәм бу эшкә Ш. Мәрҗанине дә җәлеп итәргә тырыша (№ 9, 24).

[1] Мирза Александр Казимбек (1801—1870) — профессор, элек Казан университетында, 1849 елдан Петербург университетында гарәп, фарсы телләре укыткан; Х. Фәезхановның остазы һәм дусты.

[2] В. В. Вельяминов-Зернов (1830—1904) — академик, көнчыгыш халыклары, шул исәптән, татар тарихын өйрәнүдә гаять зур эшчәнлек күрсәткән галим. Аның «Исследования о касимовских царях и царевичах» исемле дүрт томлы әсәре бүгенгә хәтле иң нигезле, ышанычлы хезмәтләрнең берсе булып исәпләнә. Бу китапны төзүдә автор Хөсәен Фәезханов җыйган татарча һәм шәрык телләрендәге башка чыганаклардан файдаланган.

[3] В. В. Григорьев (1816—1881) — Россия Академиясенең корреспондент-әгъзасы, көнчыгыш халыклары тарихына багышланган йөзләгән фәнни хезмәт авторы.

Фәезхановның татар тарихына караган истәлекләр турында күп уйлавы очраклы хәл түгел иде, әлбәттә. XIX йөзнең беренче яртысы һәм урталарында татар халкының тарихы белән кызыксыну бик көчәя. Галимнәр Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы чорына караган эпиграфик һәйкәлләрне интенсив рәвештә өйрәнә башлыйлар. Тикшерүчеләрне казанышлар белән бергә уңышсызлыклар да көтә: беркем дә берничек аңлый алмаган «сәрле» сүзләр табыла. Комга терәлгән көймәне Фәезханов кузгатып җибәрә. Болгар ташларындагы әлеге сәер сүзләрне ул беренче булып чуваш теле фактлары ярдәмендә дөрес укып, гыйльми ачкыч таба.

Бу вакытларда Ш. Мәрҗани дә борынгы язмаларны җыеп йөри. Ул хакта Петербург галимнәре дә яхшы белгән булырга тиеш, һәм алар Фәезханов аша аны да эшкә җәлеп итәргә тырышалар: үтенечләр язып, ярдәм итүләрен сорыйлар (№ 6, 13). Бу яктан 1860 елда язылган бер хат бик характерлы: «Бу көндә Асаре кадимә (Археология) җәмгыятенең кятибы Вельяминов илә әңгәмәләшкәндә Казан вә аның әтрафында булган иске әсәрләр хакында сүз чыкты. Сезнең мәсҗеденездә булган таш язуындан Ильминский нөсхә алып җәмгыяткә йибәргән имеш. Ләкин кирәгенчә кылып йиткермәгән. Әүвәлән, бу ташның кайдан монда төшүе хакында Казан әһалисе арасында булган риваятьне язмаган. Икенчедән, «бу ләүхәне» сүзен «булучыны» дия «булмак» фигыленнән исемләшкән фигыль дип аңлатып саташтырган. Вельяминов ошбу ташны яхшы карап язуыңыз хакында сездән... илтимас кылды», — дип, автор Мәрҗанидән ташның тулы тасвирламасын сорый (№ 14).

Бу сорауларга каршы Ш. Мәрҗани язган җаваплардан өзекләр В. В. Вельяминов-Зерновның китапларында басылса да, ул хатларның тулы тексты кайда саклануы билгесез иде. 1965 ел ахырында Ленинград шәһәрендә булганда Ш. Мәрҗани хатының 1860 елда язылган оригиналының тулы тексты табылды. Х. Фәезханов әйтүенчә, ул җаваптан «Җәмгыять кятбы... бик разый булган» (№ 6).

Югарыдагы фактлардан узган гасырның 50—60 елларында ук Петербург ориенталистларының Ш. Мәрҗанине яхшы белгән булулары күренә. Монда Х. Фәезхановның белеме, тырышлыгы, сәләте генә түгел, Казанда яшәгән күренекле рус галимнәре дә тиешле роль уйнаган булырга

кирәк. «Готвальд[1] элеккечә сәламәтме? Сезгә (аның) ихтирамы зур иде. Үткән ел килгәндә, гел сезнең җәнабыгызны олылап сөйләп йөрде» (№ 10), — дип яза тагын бер хатында Х. Фәезханов.

Х. Фәезхановның җирле тарихка карагән материаллар белән кызыксынуы эпиграфика өлкәсендә генә калмый. Ул татарча тарихи әсәрләрне эзләп табарга тырыша, алар турында Мәрҗанидән сорый: «Русиялеләр Казанны яулап алганларында мөселманнарның галимнәре юк идеме? Китап вә гыйльми әсәрләре һич калмадымы? Ханнарның көтепханәләре булмадымы?» (№ 14). Бу сорауларга каршы конкрет җавапта Мәрҗани нәрсәләр язгандыр, хәзергә билгесез әле. Әмма аның «Мостафадәл-әхбар...» исемле зур тарихи хезмәтендә ул сорауларның барысы да кузгатылып, Мәрҗани аларга җавап бирергә тырыша. Димәк, Фәезханов үзенең шундый һәм башка сораулары белән Мәрҗани әсәрләренең композицион төзелешенә, эчтәлегенә әзмекүпме тәэсир ясаган булып чыга. Гомумән, Петербургта яшәгән Фәезхановның Мәрҗанигә файдасы күп була, аны Мәрҗани үзе дә тәкъдир итеп телгә ала.

Ләкин Фәезханов тарих өлкәсендә гади практик, бары материал җыючы булып кына калмаган. Кайбер хатларында ул гаҗәп тирән теоретик мәсьәләләрне күтәреп чыга. Мәсәлән, татар халкының килеп чыгышы — этногенезы буенча аның тарафыннан әйтелгән фикерләр әле бүген дә үзләренең гыйльми әһәмиятләрен югалтмаганнар.

Үз халкының этногенезы белән фәнни нигездә кызыксыну татарларда узган гасырда башлана. Фәезханов белән Мәрҗани исә бу өлкәдә гыйльми төпле фикер әйтүче татар укымышлыларының беренчеләре иде.

Билгеле булганча, татар халкының вәкилләре үзләренең бабалары дип болгарларны таныганнар. Элеккедән калган язма истәлекләр, шәҗәрәләр, риваятьләр шуны күрсәтә. Үзләрен «шәүкәтле Чыңгыз-хан нәселе» дип исәпләүче татарлар да юк түгел иде, әлбәттә. Мондый хәл татарча язылган тарих әсәрләрендә дә беркадәр чагыла. Дөрес, «татар-монголчылык» теориясенең вакыт-вакыт өстенлек итүендә рус официаль тарих гыйлеменең дә ролен онытып җибәрергә ярамый: патша политикасын яклаучы тарихчылар, билгеле традицияләргә һәм карашларга таянып, Казан татарларын «монгол империясе ярчыгы» дип күрсәтеп килделәр. Татар буржуаз милләтчеләре исә моны ике куллап күтәреп алып, «Чыңгыз бабай шөһрәте» белән масаеп, үзләренең кара ниятләрен гамәлгә ашыруда файдаланырга тырыштылар. Бу тенденция бигрәк тә XX гасыр башында, татар буржуазиясе реакционлашкан чорда киң таралган иде.

Хөсәен Фәезханов бу мәсьәләләрдә нинди позициядә торган соң?

Югарыда Фәезхановның Идел буе татарларын «татар» дип атарга теләмәве һәм «нугай» сүзен куллануы күренгән иде. Әйе, ул татар исеменнән качкан, хәтта татар телен дә шул чордагы башка әдипләр һәм укымышлылар кебек үк «төрки лисан», «төрки тел» дип атый. Төп сәбәп, безнеңчә, Х. Фәезхановның Казан татарларын илбасар «монгол-татарлар» белән бутарга теләмәвеннән килгән булырга тиеш. Ә көнчыгыш халыклары арасында исә Казан татарларын «нугай» дип йөртү традициясе бар иде. Фәезханов менә шул терминны, шартлы рәвештә, үз хатларында да куллана.

Әмма Казан татарларының болгарлардан чыгу мәсьәләсенә килгәндә исә, Фәезханов үз сүзләренә ышанган хәлдә фикер йөртә: «Мәмләкәте Болгар, хосусән авыллар ни славян, ни төрек (түгел), бәлки фин булмак кирәк», — дип сөйләгән фикеремне сезләр (ягъни Ш. Мәрҗани — М. Г.) кабул күргән идегез. Әлбәттә, араларында төрекләр булмыш, бәлки таифәи мөтәгалләбә (җиңүче, яулап алучы кабиләләр) төрекләр булмак дөресрәк шикелле. Ошбу фикеремне Григорьевка һәм сөйләдем, ул да мәгъкуль күрде. Үзенең әүвәлге фикереннән кайткан имеш. Ул заманнарның тарихларыны тикшерү соңында, аларның (болгарларның) славян булулары хакыйкатьтән ерак диядер. Сезләге рисаләсендә славян булмакларыны куәтли иде... «Җәмигъ-әт-тәварих» (китабы) риваятьләренә күрә кыпчак төрекләре Хәзәр (Каспий) диңгезе буйларына каләр җәелеп, аннан Идел илә үрләп, финнарны кысрыклап, Болгарда хөкүмәт нигезләгән булсалар кирәк. Чөнки фин теле илә төрек теле арасында мөнәсәбәт бар. Милләте галибәгә (җиңүче милләткә), төрекләр мөселман булганнарында да, вә аннар васыйтасилә финнарга да ислам дине кергән вакытта, әкренләп фин теле төркигә алмашынмыш

[1] И. Ф. Готвальд (1813—1897) — Казан университетында гарәп һәм фарсы телләре укыткан профессор.

булмак кирәк... — дип, гомум гипотеза тәкъдим иткәч, автор берничә мисал да китерә: — әгәр тау ягыны чувашлар, ә Казан артыны чирмешләр дисәк; әмма ислам кабул итмәгән финлар, хәзерге чувашлар вә чирмешләр, үз телләре илә калсалар да, төркилек бик күп. Хәтта чуваш телен төрек теленә үзгә тел димәк тә мөшкел. Якын араларда чуваш лөгаты китабы алдым. Андан мәгълүм буладыр ки: дүрттән өче «төркидер». Ләкин төркие-мовәллад («ясалма төрекләр», икенчел төрекләр) булганлыкларындан күп авазлар үзгәргән... Әмма чирмеш телендә өчтән бер кадәре генә «төрки» булып, башкасы финни (сүзләр)дер...» (№ 20, 22).

Күрәсез, Х. Фәезхановның татар этногенезына карашы заманына күрә гаять төпле һәм шактый тирән булган. Дөрес, аның кайбер гипотезалары искереп өлгерде инде. Ләкин Фәезханов фикерләренең алтын орлыгы үзенең гыйльми кыйммәтен бүген дә югалтмаган. Ул түбәндәгедән гыйбарәт: Болгар дәүләте, күп кенә беркатлы тарихчылар уйлаган кебек, бер телдә сөйләшүче халыкларны гына түгел, бәлки берничә башка телле кабиләләрне эченә алган, һәм татар халкының милләт булып оешуында төрле компонентлар катнашканнар.

Мондый фикернең узган гасыр урталарында ук татар тарихчысы тарафыннан әйтелгән булуы бик әһәмиятле, чөнки ул төрле шовинистлар, милләтчеләр тукыган «саф канлылык», расачылык теорияләренә нигездән каршы килә.

Югарыда китерелгән документлардан икенче бер мөһим нәтиҗә дә чыга: этногенез мәсьәләсендәге бу айнык һәм дөрес карашка Х. Фәезханов белән бер үк вакытта Шиһап Мәрҗани дә килгән була («фикеремне сезләр кабул күргән идегез...»). Әйе, Ш. Мәрҗани үзенең «Мостафадәл-әхбар...» исемле хезмәтенең беренче томында шундый ук фикерләрне тагын да нигезлерәк документлар, көчле логик дәлилләр белән кабатлый.

Билгеле, Фәезхановның халык этногенезы буенча болай төпле фикер йөртә алуы аның тарих теориясе мәсьәләләрендә, ягъни тарих фәненең философиясендә, чоры өчен гаять көчле булуын күрсәтә. Әйе, аның мисалларын без Мәрҗанигә язылган хатлардан да табабыз. Мәсәлән, «Вафиятәл-әслаф...» исемле био-библиографик энциклопедия өчен материал җыючы остазына ул гел вакыйгалар тасвирлау белән генә чикләнеп калмыйча, фәннәрнең тарихына кереп, аларның эволюциясен дә күрсәтергә киңәш бирә: «Сезнең тарихыгызны[1] бу көннәрдә вакыт табып укыдым. Күп яхшы табам. Ләкин (мин) фәкыйрь батырчылык итеп бер фикер әйтә белерем: минем фикеремчә, бу тарихыңызда гыйлем тарихыны ачыграк бәян итмәкенез, ягъни һәрбер гыйлемнең нидән вә кемләрнең тырышлыклары илә башланып, вә ничек киңәеп вә үсеп, вә никадәр дәрәҗәләргә йиткәнлеге, вә ни сәбәптән инхитат (регресс) тарафына киткәнлеген ачык вә тулы язмак кирәк иде. Ул фәнләргә ни сәбәптән ихтыяҗ төште, вә ни сәбәптән (аларны) үстерделәр; бу гыйлемләрнең «базарлары сәүдәле» булырга тагы нәрсәләр (сәбәп) булды вә каю заманда «сәүдәле» булдылар; кясәд булмакларына (регресс кичерүләренә) сәбәпләр ниләр булды, вә бу гыйлемләргә кемләр күп хезмәт иттеләр, вә әүвәлге дәрәҗәләрендән ни кадәр меңгерделәр» (№ 11, 13).

Бүгенге телгә, хәзерге атамаларга күчерсәк, бу — тарихи вакыйгаларны, фактларны тикшергәндә аларны барлыкка китергән, үзгәрткән һәм юкка чыгарган иҗтимагый-социаль шартларны, объектив һәм субъектив сәбәпләрне дә исәпкә алу дигән сүз була. Ә бу — тарихка материалистик караш.

* * *

Югарыда әйтелгәннәрнең барысын да игътибарга алганда, Х. Фәезхановның мәктәп-мәгариф мәсьәләләре буенча төзегән мәшһүр проекты да очраклы яки гадәттән тыш күренеш дип уйлау дөрес булмас иде. Ул проектка да Фәезханов, үз чорының алдынгы улы буларак, тиешле интеллектуаль әзерлек һәм ярыйсы гына куәтле аргументлар белән килә. Сүзне Фәезхановка бирик:

«Бөтен хаҗәтләре вә зарур шәйләре йитештерелеп, Казанда бер олуг мәдрәсә ачылыр. Хәзинә хисабына уларак 60—70 шәкерт тәрбияләнер вә анлар өстенә дәрес тыңлаучылар кабул кылыныр. Гимназиядә укылмакта булган барлык фәнләр укылу өстенә голүме шәргыя вә гарәбия (шәригать гыйлемнәре вә гарәп теле) дә укытылыр. Аурупа телләре, җәгърафия вә тыйбб (медицина), табигыять рус лисаны илә, андан башкалары төрки лисан илә укытылыр.

[1] Сүз Мәрҗанинең «Мөкаддимә» исемле китабы турында бара.

Монда ике йөздән алты йөзгә кадәр хак алучы ике-өч дәрәҗә мөдәррисләр булыр. Мәдрәсәдә ун сыйныф булып, әүвәлгә өч сыйныфта бөтен укучылар төрки, фарсый, гарәби, руси лисаннлар вә моның өстенә дә җәгъфрафия, бәгъзе һәндәсә (геометрия), мәшкы кыйраәт укылыр». Аннан соң, Фәезханов фикеренчә, «сыйныфлар икегә аерылып, бер бүлеге ислам голәмәсе юлы булып», анда дини дәресләр өстенә «әзме-күпме фельдшерлык дәрәҗәсендә латыйнча вә тыйбб өйрәтелер». Ә «икенче шәгъбәдә (дөньяви бүлектә — М. Г.) сарыф гимназия ысулынча дәрес итәләр. Андан чыкмыш шәкертләр тугры университетка керергә хаклы булыр...»

Шулай гомум мәсьәләләргә тукталып, максатны сөйләп узгач, Х. Фәезханов мәдрәсәне тәэмин итү буенча да үз планнарын күрсәтә: «Бу мәдрәсәнең еллык 25 000 сум кадәр хәражаты булса кирәк. Аның чарасы болай булыр: мәдрәсә тарафыннан дәүләт сәясәте һәм дәүләт эшләренә караган бер журнал чыгарылыр... Журнал бәһасы дүрт тәңкә кадәр булып, һәр мәхәллә бер нөсхәдән алырга мәҗбүр кылыныр. Оренбург духовный собраниесе карамагында 5000 кадәр мәхәллә булса, моннан 20000 тәңкә хасил булыр. Басмак чыгымнарыннан соң аздан моның ярымы — 10000 сум калыр. Хәзер һәр никахтан 9 тиен аладыр иделәр; шул, моннан соң 25 тиен алыныр. Андан йиде-сигез мең тәңкә хасил булса кирәк», — дигәч, автор хөкүмәттән һәм халыктан ярдәм булуына да өмет белдерә (№ 15)[1].

Китерелгән өзекләрдән Х. Фәезхановның заманы өчен нинди олы хыяллар белән яшәве ачык күренсә кирәк. Шул ук вакытта проект авторының кайбер мәсьәләләрдә naив, хәтта чикләнгән булуы да ярылып ята. «Бу шәкертләр университеттан чыктыклары соң ислам диненә бик күп хезмәтләр күрсәтә алырлар», дигән сүзләр моңа яхшы дәлил булалар.

Әмма ул караңгы чорны, татар дөньясында хөкем сөргән үтергеч фанатизм сөремен исәпкә алганда, идеалистик чикләнгәнлекләре булуга да карамыйча, Фәезхановның гаҗәп кыю адым ясавы һәм чордашларыннан гаять югары торуы бәхәс тудырмаса кирәк.

Фәезханов үз проекты турында хатларда язып кына чикләнми, таныш-белешләре, галим-голәмә, шул исәптән, мөфтилеккә дәгъва итеп йөрүче Сәлимгәрәй морза Тәфкилев белән дә киңәшләшә. Алда торган киртәләрне ачыграк күрә башлый: һәр яңалыктан «кяфырлык», күтүче тәкәдәй кире татар руханилары белән бер сафка патша самодержавиесе сатраплары да килеп басалар. Соңгыларының татар руханилары психологиясен исәпкә алып, алар кабул итмәслек шартлар куюы ачыклана. Ул рус теле — «урысчылык» белән өркетү. Русча укытуның кирәклеге хакында үзе бер дә икеләнмәгән Фәезханов шуны сизеп ала һәм дәресләрнең күпчелеге «русча укылыр, юкса дәүләт ярдәм итмәс; хосусан, русча тел укылмаганда, мондый мәдрәсәне ачарга рөхсәт тә бирмәс», — дип, булачак киртәне дә, аны җиңү юлларын да күрсәтеп уза (№ 22).

Ләкин шул хатта ук Фәезхановның үзенең элекке кайбер позицияләреннән мәҗбүри чигенгән булуы да ачыклана: «Без әүвәлдә тәмам гимназия гыйлемләрене өйрәтеп, гимназия шәкертләре вә мөгаллимләре файдаланган имтияз (привилегия) илә файдаланмак юлыны нигез итеп торткан идек, соңра ул фикердән кайттык. Аның файдасы юк, имеш, чөнки үз арамызда фән укытырлык әзерлекле адәмләремез юк», — ди. Өстән генә карaганда, бу көчле генә аргумент булып яңгырый. Әмма төптәнрәк уйласаң, аның нигезе чамалы: Х. Фәезханов, Г. Мәхмудов һ. б. шулар кебек билгеле шәхесләр булачак татар гимназиясенең нигез ташларын куюда ул хәтле үк ярдәмсез хәлдә калмаслар иде шикелле.

Фәезханов проектына беренче ударны клерикаль татар руханилары ясый. Һәм, безнең уебызча, бу мәсьәләдә С. Тәфкилев тә ярыйсы гына тискәре роль уйнаган булырга тиеш. Беренчедән, мөфти булыр өчен тырышып йөргән, патша хөкүмәтенә ялынычлы кешенең реакцион эчке эшләр министрлыгы ни кушса, шуны эшләве бәхәссез иде. Икенчедән, бөтен Россия руханилары белән эш итәргә ниятләгән Тәфкилевнең әллә нинди «урыс ышкулы» ачуда катнашып, үзен бөтен «әһле-ислам» дөньясына каршы куюга хәтле барып җитүе бик шөбһәле.

Биредә тагын бер моментка тукталып

---

[1] Р. Фәхретдинов бу хатның кайчан язылган булуын билгеләп алмыйча, аны 1860—61 елларга нисбәт итә. Ләкин башка хатларның эчтәлекләрен тикшерү нәтиҗәсендә, аның 1864 елда язылган булуы ачыкланды.

узу кирәк булыр. Гыйльми әдәбиятта[1] Фәезханов проектына Ш. Мәрҗани дә каршы чыккан диган фикер яшәп килде. Ләкин ул караш документлар белән расланмый. Хәтта киресе килеп чыга. Мәсәлән, 1864 елның ахырларында Фәезханов Мәрҗанигә болай яза: «Мин бу мәдрәсә хосусында булган ышанычым анларныкыннан көчлерәк дип беләм. Анларның тилерүләре көндән-көн ошбу ышанычымны куәтлидер. Ләкин бу хосуста сезләрне (ягъни Ш. Мәрҗанине — М. Г.) катнаштырып, сезләргә ифтира (яла) кылулары өчен уңайсызланам. Бу эш хакында сезнең фикерегез кайсы тарафта икәнлеге һичкемгә әйтелгәне юк иде. Мәгәр дә хаҗи мирзага (С. Тәфкилев — М. Г.) яздым: «Дамелла узгәләр сөйли торган нәрсәләрнең һичберендән курыкмый, бәлки руслар илә аралашу күп булыр, ва анларның табигыят, рыязыятта бездән өстенлекләре күрелеп, анларга яхшы мөнәсәбәт артык килү кирәк булыр диярдер. Чындан да, бу фикер игътибарга лаекъ», — дип» (№ 24).

Бу өзектән, беренчедән, Фәезханов проектына каршы татарлар арасында да бик көчле оппозиция тууын күрсәк, икенчедән, Ш. Мәрҗанинең Фәезханов белән бер позициядә булуын, шуның өчен аңар эләккәләвен дә беләбез. Җәяләр эчендә генә искәртик: Мәрҗани өстенә яла ягуда да мирза Тәфкилевнең катнашы булмады микән? Ни өчен Фәезханов проектка Мәрҗанинең катнашлы булуы турында бер «хаҗи мирзага» гына язуы турында әйтә? Мәрҗани өстенә төшкән ударларның чыганагын эзләү тугел микән бу?

* * *

XVIII—XIX гасырлар — мөселман көнчыгышында торгынлык хөкем сөргән, аның каравы мулла-мөнтагайлар өчен киң мөмкинлекләр биргән фанатизмның чәчәк аткан чоры, иң караңгы дәвер иде. Заманында халыкара дан казанган шәрык культурасы бөтенләй сулып, бөтен сфераларда да регресс үз тамгаларын сугып өлгергән иде. Моны Фәезханов та чоры өчен ярыйсы гына дөрес сиземли алган: «Бәлаегазимдерки, күп тарих китапларының нөсхәләре ялгыш язылмыштыр. Моның сәбәбе соңгы гасырда безем галәмәе-ислам тарих илә күп төпченмии, бәлки табылмыш нөсхәләр надан куллардан чыкмыштыр. Мин, шул кадәр китаплар укып, «мәнә дөрес!» диярлек нөсхә тапканым юк» (№ 13).

Иске мөселман көнчыгышының цитадәле булган Бохарага карата да Фәезханов мөнәсәбәте бик характерлы; бер хатында Мәрҗанигә: «Нәҗип[2] Бохарада череп калмаса ярар иде», — дип яза (№ 23). Яки икенче бер мисалны алыйк: «Нәҗиптән озын хат алдым. Башы фарсыча язылып, «Бохара» исеме телгә алынгандан соң хәтта икешәр мәртәбә «шәриф» «мөкаддәс» дип кабатлап куйган. Соңра төрки гыйбарәләре белән язып, Бохарада вә анда булган әхвәлаттән биниһаять зарланып, киресенчә язган. Әүвәлдә ул хат бохаралылар кулына төшеп, әмирнең начар чаралары булыр дип фикер итеп тә, соңра нугай кулы илә Россиягә йөбәреләчәге билгеләнгәч, ачы теллелек вә мыскыллауны арттырып та җибәргән булса кирәк. Чөнки ул бичара (мин) фәкыйрьнең мәзәк һәм көлү ысулы илә Бохараны мыскыл итеп язган хатларым сәбәпле җәфа чикмештер. Чөнки Бохарада фәлән мулла Петербургта бер кемсә илә хат йөртешә вә төрле хәбәрләр язышa, имеш, дип мәшһүр булып, хәтта кайберләре әмир кулына төшеп, — бәхеткә, ул хатларда күп мыскыллау сүзе булмаган тәкъдирдә дә — 39 таяк ашавы хак имеш. Бу хосуста күп тафсиль язмыш» (№ 13).

Мөселман мәдрәсәләрендә гомер кичереп белем алган кешенең «Бохараи-шәрифкә» болай айнык карый алуы, әлбәттә, аның иҗтимагый аңы бик нык үскән булуын күрсәтә. Әмма Фәезхановның торгынлыкка карата тискәре мөнәсәбәте бер Бохарадан көлүләре белән генә чикләнми, ул наданлыкның, томаналык, фанатизмның бөтен формаларыннан ачык җирәнә.

Халыкның ишаннарга ышанып йөрүләренә карата да Фәезхановның ирониялe мөнәсәбәте игътибарга лаек: «Безем ишан мулла Хәбибулла[3] мәхдүм, ходай теләп

[1] История Татарской АССР, 1 том. Рус телендә. Казан, 1955 ел, 272 бит; М. Гайнуллин. Каюм Насыров и просветительское движение среди татар. Рус телендә. Казан, 1955 ел, 34—35 битләр.

[2] Мөхәммәтнәҗип Баймөрат улы (1829—1866) — Ш. Мәрҗани һәм Х. Фәезхановларның шәкерте, әшнәсе, озак еллар Бохарада укыган.

[3] Хәбибулла Әлмөхәммәт улы Сафаҗаи (1829—1894) — Хөсәен Фәезхановның шәкерте; Бохарада укып кайткач, остазының киңәше буенча, туган авылына кайтып мәдрәсә ачкан һәм муллалык иткән. Красная Горкада табылган Фәезханов хаты шушы кешегә адресланган.

Сабачайга кайтса, (үз) ягымызда бер үрнәк булырлык гыйлем сөюче булачак, имеш. Чөнки «мишәр» таифәсе «ишан» аталган затларга бик турылыклы булалар. Мәрхүм «Оры» Хәбибулла ишанның аяк баскан йирләрене үбәләр вә Орыга барганларында кабереңең тупракларын ашыйлар, имеш. Безем тарафымызның күпчелеге «Колаткы» Җәгъфәр ишанга турылыклы иделәр. Мулла Хәбибулла бәхетенә ул һәм үткән ел мәрхүм булыптыр. Хәзер урыны буш, килсен дә утырсын, яхшы кәсеп һәм эш итәр» (№ 20).

Икенче бер урында: «Авыл муллаларының күпчелеге бәдху (эшәке холыклы), надан вә хәрамхурлар», — дип гомумиләштереп тә куя (№ 24).

Мондый сүзләрнең Мәрҗанигә адресланган хатларда язылуы кайберәүләребез өчен сәеррәк булып тоелыр, чөнки соңгы вакытларда әдәбиятта Мәрҗани бары «чалмалы мулла» буларак кына танытылып килде. Әмма Мәрҗани өчен мондый фикерләр бик гадәти генә булсалар кирәк, чөнки шәкертнең хәзрәт алдында «чыгырыннан бөтенләй чыгып» киткән моментлары да бар.

Узган гасыр урталарында университет нәшриятында басылган коръәннәрдә хаталар китеп, зур җәнҗаллар кубуы, киләчәктә андый ялгышларны булдырмас өчен хөкүмәт тарафыннан махсус комиссия билгеләнеп, аның башына Ш. Мәрҗанинең куелуы беркадәр мәгълүм. Бу мөнәсәбәт белән 1860 елның августында Фәезханов үз остазына мондый кыю һәм кискен сүзләрне яза: «Коръән мәсьәләсе ничек булып калды? Сезнең вакытыңыз заигъ булуы өчен үкенеч вә көенеч; куйсаңыз булмас идеме? Шуңа сарыф кылачак вакытыңызны моннан соң тарихи әсәрләреңезне тәмам итүгә сарыф кылсаңыз яхшы булмасмы иде?» (№ 13). Биредә комментарий артык булыр.

Фәезханов эшчәнлегеннән өйрәнгәндә тагын бер зур мәсьәләне ачыклап китү мөһим булачак. 1850—60 елларда Россиядә киң җәелгән революцион-демократик хәрәкәтләргә карата ул нинди позициядә торган? Әлбәттә, үз чорының иң күренекле ориенталист галимнәре белән якыннан аралашып, алар белән уй-фикер алышып яшәгән, һәм революцион хәрәкәтләрнең учаклары булган Казан, Петербург кебек үзәкләрдә озак-озак гомер кичергән кеше мондый актуаль мәсьәләләрдә бөтенләй битараф позициядә кала алмагандыр. Хөсәен Фәезхановның күренекле казакъ галиме Чокан Вәлихановка язган хатларында безнең фикерне расларлык моментлар юк түгел. Ләкин алар ул документларда кирәгенчә ачылып җитмәгәннәр әле.

1861 елгы патша реформасы нәтиҗәләре прогрессив җәмәгатьчелектә протест тудыра. Казан, Петербург университетлары студентлары һәм алдынгы галимнәр бу хәрәкәттә зур активлык күрсәтәләр. Патша хөкүмәтен дә пассивлыкта гаепләп булмый, билгеле: төрмәләр тулып, Себергә эшелоннар озатыла. Петербург университеты вакытлыча ябыла, югары уку йортларыннан прогрессив укытучыларны эштән куалар. Бу давыллы вакыйгалар Фәезхановны да читләтеп узмыйлар. 1862 елның январенда ул болай дип яза: «Бу сәнә безем мәдрәсәи-кәбирәмездә кайбер тәртипсезлекләр булганлыктан (ул) билгесез срокка падишаһ әмере илән ябылды. Безләр заштат калдык» (№ 17). Ни өчен Фәезханов штаттан тыш калган, монда берәр конкрет сәбәп бармы, һәм нинди сәбәп — бу киләчәктә хәл ителергә тиешле мәсьәләләрнең берсе.

Хөсәен Фәезхановның Мәрҗанигә язылган һәм «Шура»да басылган хатларының эчтәлекләре югарыда күрсәтелгән проблемалар белән генә чикләнмиләр. Аларда галимнең шәхси тормышына караган материаллар шактый булу белән бергә, авторның татар теле белеме өстендә нәрсәләр эшләве турында да әлегәчә игътибар ителмәгән мәгълүматлар күп. Мәсәлән, монарчы без Фәезхановның 1862 елны литография ысулы белән басылып чыккан «Краткая грамматика татарского языка» исемле китабын гына белә идек. Хатлардан исә Фәезхановның 1864 ел көзендә «гайреләргә тәкълид итми», мөстәкыйль рәвештә, язып бетерү алдында торган бер китабы булуы һәм аның өстендә эшләвен дәвам иттерүе ачыклана (№ 24, 25). Бу бик әһәмиятле факт. Шулай ук Фәезхановның башка әсәрләре булуы турында да Мәрҗанинең монарчы игътибарсыз яткан бер хатында мәгълүматлар бар. Шәкерте һәм дусты Фәезхановның вафаты мөнәсәбәте белән, 1866 елның ноябрендә аның Кәлимулла исемле укучысына язылган ул хатның фотокопиясе 1915 елгы «Мәрҗани мәҗмугасы»нда басылган. Шәкерте Фәезхановның вакытсыз вафаты өчен бик кайгыруын белдереп, кыска гына гомер эчендә аның халкына файдалы эшләр эшләп өлгерүен билгеләгәч, Мәрҗани болай яза:

«...Анын мәдрәсә хосусында тәхрир кылган бер рисалән мосәвведәсе (караламa китабы) бар иде, аны эшкәртеп бастырмак ниятендә иде. Бичара, эшкәртергә вакыты булмагандыр. Шул рисалә җуелмаса икән. Мин үзем аны эшкәртеп, бастырмак ниятендә булыр идем. Ичмасам, нөсхәләре күп булсын өчен биш-алты күчермә яздырыр идем. Бичараның хезмәте һәм иҗтиһады зангъ булмаса икән. Ул бик яхшы, бик файдалы нәрсә иде. Гавам халык шаушулы ялган хәбәрләр (таратып) теләсәләр ни сөйләсеннәр; наданлык, дошманлык сәбәпле юк нәрсәләр яла итеп шаулыйлар... Минем үз уемча, егерме ел Бохарада дәрес укып йөреп, монда кайтып егерме сәнә дәрес иткән кешеләр шуны игътибар берлә укып тикшерсәләр, аталары-бабаларына насыйп булмаган гыйлемлекләр хасил итәрләр ирде. Ни кылмак кирәк, надан, көнче (кеше), дөреслекне тынламыйча, дошманлыкны ныгытыр өчен ялган-яла ягадыр. Хаклыкны (үзләренә) дошман санныйдыр... Мөмкин булса, тизлек илә мәрхүмнән калган китапларны, исемләрен язып алып, тулы каталог ясап, мөмкин булса, баягы рисаләсене вә шуңар мөнәсәбәтле аерым кәгазьләрдә булган язмаларны һәм безгә йебәрәсез. Элегрәк үзе төзегән бер җыентык булса кирәк иде; янә татар телендә язган нәху вә сарыфы булса кирәк иде. Болгар вә Казан хакында мәкаләләре булса кирәк иде...»

Х. Фәезхановның шәхси сыйфатларын, анын ни хәтле намуслы, олы җанлы кеше булуын күрсәтә торган бер өзек китерик: «Халем гаять зәгыйфтә. Университет начальствосы хыялыма килмәгән лотыф вә мәрхәмәтләр иттеләр. Кышның күп өлешен хезмәткә йөрмәвемдән күз йомуларыннан тыш бер сәбәп илә биш айга, беренче апрельдән беренче сентябрьгәчә, отпуска бирделәр. Андан өстен өч йөз (сум) ярдәм бирделәр. Бу хосуста үтенү генә түгел, бәлки хыял итү дә хәтеремә килгәне юк иде.

Бу авырудан бигрәк вәсвәсә вә хыяллар, вә гел ваем чигү һәрбер чирдән дә авыр икән. Әгәр әһлиямнең (хатынымның) яхшы хезмәте һәм юатулары булмаса иде, хыялдан беткән булыр идем. Илаһи, дөньяда вә ахирәттә йөзе ак булсын! Бу кадәр минa авыр хәлемдә хезмәт кылдыки, аз хатын бу кадәр сабырлы булыр...» (№ 28, хат 1866 ел 13 мартта язылган).

Моннан соң Ш. Мәрҗани Фәезхановтан тагын бер хат ала. Күп тә узмый вафат хәбәре килә: шул елның 28 нче августында ялкынлы йөрәк тибүеннән туктый. Университет тарафыннан бирелгән отпусканың срогы чыгарга өч кенә көн калган була.

Фәезханов иҗатын киң планда өйрәнер өчен, аның басылып чыккан билгеле әсәрләреннән тыш, архивларда саклана торган мәгълүматларны да интенсив рәвештә тикшерергә кирәк. Шулай ук халык кулында саклана торганнарын җыю эшенә дә кызурак тотынырга тиешбез. Андыйлар әле дә күп булырга охшый, соңгы елларда табылган кайбер истәлекләр шуны күрсәтәләр, һәм бу юлда галимнең якташлары, кардәшләре дә ярдәм итәрләр дип ышанасы килә. Хөсәен Фәезханов эшчәнлеген менә шундый төрле характердагы тарихи чыганаклар нигезендә, аның үзе яшәгән катлаулы чорда казаныш тапкан иҗтимагый фикер яңалыкларына һәм бөтен Россия күләмендә канат җәйгән азатлык өчен көрәш хәрәкәтләренә бәйләп, күпьяклап өйрәнсәк кенә марксистик дөрес нәтиҗәләргә ирешербез.

Г. Халит

# БЕР БӘХӘС УңАЕ БЕЛӘН

Татар әдәбияты тарихын өйрәнү өлкәсендә сугыштан соң игътибарга лаеклы байтак кына эш башкарылуы бәхәссез. Шулар арасында Тукай тормышын һәм иҗатын тирәнтен, киңрәк итеп тикшерү юнәлешендә дә әһәмиятле тәҗрибәләр ясалды инде. Шуңар күрә: «Т у к а й н ы  ш а г ы й р ь итеп өйрәнү, поэзиясенең «серенә төшү»не әйтеп тә тормастан, иҗатының идея юнәлеше, шагыйрьнең фикер иясе буларак үзенчәлеге дә безгә бик үк ачык түгел икән әле»[1], дип, гомумән күңелсез бер нәтиҗә ясарга кирәкме икән?

Дөресен әйткәндә, Тукайдан башка татар әдәбиятында реализм һәм халыкчанлыкның ничек тамыр җәюен, үсүен күз алдына китерү бик кыен икәнлеген без торган саен тулырак аңлый барабыз шикелле. Чөнки бу тарихи хакыйкать кенә түгел, ә бүгенге чынбарлык та. Тукай традицияләре барлык тере тамырлары белән безнең аңыбызда, хисебездә, әдәбиятыбызда, сәнгатебездә һәм, ниһаять, тормышыбызда яшәүләрен, дәвам һәм тәрәккый итүләрен раслый торган фактлар тулып ята. Менә шуларның барысын күз алдына китергәннән соң, шагыйрьне, күптән инде үз заманының тарихи чикләрен үтеп, яңа чорларга күчә барган һәм безнең заман кешеләре арасында да яшәгән итеп хис кылу бик табигый. Бәлки, шуңар да аның шәхесенә һәм иҗатына бәйле сүз-фикерләр һәм эзләнүләр аеруча бер игътибар, күтәренке кызыксыну, хәтта эмоция белән кабул ителә торгандыр. Моның шулай икәнлеген Тукайның тууына 80 ел тулу уңае белән «Социалистик Татарстан» газетасы һәм «Казан утлары» журналы битләрендә чагылган бәхәс, фикер алышулар тагын бер мәртәбә ачык күрсәтте. Башта шуны әйтәсе килә: «Социалистик Татарстан» газетасының Тукай һәм Җәлил традицияләре тирәсендә кузгатып җибәргән бәхәсе бик урынлы һәм кирәкле иде. Хикмәт — бу ике шагыйрь мирасы татар әдәбиятының үткәненә, бүгенгесенә һәм киләчәгенә һичбер вакыт аерылмаслык булып бәйләнгән булуда гына түгел, ә шул мирасның коммунизм төзүче кешеләргә һәм идея, һәм сәнгать ноктасыннан юлдаш булуын, ничек хезмәт итүен ачып бирүдә һәм бүгенге поэзиябезнең гражданлык сыйфатын тагын да югарырак күтәрү өчен көрәшнең мәгънәсен, максатын конкрет аңлауда. Хәзерге татар поэзиясендә традиция һәм новаторлыкны, яңалыкны аңлау ничек булырга тиеш, дигән сорау күпләрнең игътибарын җәлеп итүе очраклы түгел иде. Әмма шуның белән бергә, бу сорауның төп максаттан аерымрак, читтәрәк калуы шикелле берьяклылык та күзгә ташланды. Шуның бер мисалы итеп, мәсәлән, «ирекле шигырь» тирәсендә кыздырылган тартышларны күрсәтергә мөмкин. Моннан, әйтерсең лә, бүгенге татар поэзиясенең олы юлы һәм яңалыгы — «ирекле шигырь» генә һәм аннан башка шигъри мөмкинлекләр калмаган, дигән бер урынсыз сорау килеп чыгуы да гаҗәп булмас. Шул рәвешчә, Тукай һәм Җәлил традицияләренең киң мәгънәсендә идея һәм сәнгатьчә кыйммәтен, байлыгын үзләштереп, поэзиядә алга табан кыю адым ничек булырга тиеш, дигән сорау күпләрне борчып, көн тәртибендә кала әле. Шулай булмыйча мөмкин дә түгел, чөнки ул бик зур мәсьәлә. Аны бер-ике бәхәс белән генә хәл итеп булмый.

Шуның шикелле үк, «Казан утлары» журналы (1966 ел, 3 сан) битләрендә И. Нуруллинның «Шагыйрьне өйрәнү юлында» дигән мәкаләсе уңае белән кузгатылган бәхәсләр дә билгеле һәм билгесез хакыйкатьләрне урынлы-урынсыз кузгату һәм кабарту итеп кенә каралмаска тиеш. Дөрес, Нуруллин мәкаләсендә аеруча кискен булып яңгыраган һәм күпертеп куелган кайбер тезислар башка киңрәк һәм әһәмиятлерәк мәсьәләләрне читкәрәк этәрде, күптән билгеле хакыйкатьләрне кабатларга мәҗбүр итте. Әмма ничек кенә булмасын, халык шагыйре Тукайның тормышын, иҗатын һәм татар әдәбияты үсешендә тоткан урынын тагын да тирәнрәк итеп, аерым бер җаваплылык һәм игътибар белән өйрәнү, тикшерү дәвам итәргә тиеш, бу юлда күп эшлисе бар әле. И. Нуруллин мәкаләсе, безнең карашыбызча, нәкъ шундый максатны күздә тотып язылган.

Бу мәкалә, барыннан да элек, Тукайның дөньяга карашында иң әһәмиятле урыннарның берсен алып торган революцион-демократик идеяләрне ничек аңларга кирәклекне кабаттан көн тәртибенә куйды һәм аларны тагын да төгәлрәк билгеләү юнәлешендәге фикерләрне кузгатуга сәбәп

---

[1] И. Нуруллин. Шагыйрьне өйрәнү юлында. «Казан утлары» журналы, 1966 ел. 3 сан. 124 бит.

булды. Моның шулай икәнлеген М. Абдрахманов, К. Фасеев («Социалистик Татарстан» газетасы, 1966 ел, 24 май) һәм Р. Нафигов («Казан утлары» журналы, 1966 ел, 8 сан) иптәшләрнең Нуруллинга җавап рәвешендә язган мәкаләләрендә ачык күрергә мөмкин. Алар, бертавыштан, егерменче йөз башындагы революцион-демократик идеяләрнең аерата Тукай дөньяга карашындагы ролен кимсетеп, кечерәйтеп күрсәтү дөрес түгеллеген искәртәләр. «XX йөз революцион демократиясенең эчтәлеге инде бик нык үзгәрә, байый. Яңа шартларда революцион демократия (либераль-буржуаз демократия түгел) азатлык өчен көрәштә пролетариатның союзниклары булган крестьяннар һәм шәһәр хезмәт ияләре интересларын гәүдәләндерде. Ә көрәш царизмны, крепостнойлык калдыкларын бетерү бурычы белән генә чикләнмәде, бәлки һәртөрле эксплуатацияне, димәк капитализмны да, юкка чыгаруны күздә тотты. XX гасыр башындагы революцион-демократлар дип без әнә шундый позициядә торучыларны атыйбыз...» дип язалар М. Абдрахманов һәм К. Фасеев. Шундый ук тезисны уртаклашып, Р. Нафигов та татар революцион демократиясенең самодержавиегә һәм буржуазиягә каршы көрәштә пролетариатка, большевикларга зур теләктәшлек күрсәткән бер көч икәнлегенә басым ясап сөйли.

Революцион демократиянең мәгънәсе һәм эчтәлеге шундый тарихи әһәмияткә ия булган. Димәк, аның күренекле бер вәкиле саналган Тукайның дөньяга карашы да, әдәби эшчәнлеге дә үзенең әһәмиятле яклары белән, беренче нәүбәттә, самодержавие һәм капитализм изүенә каршы актив көрәшкә күтәрелгән киң халык массаларының уй-теләкләренә тоташкан иде. Ә моны инде һичбер төрле формада шик астына кую яки дәгъва кылу мөмкин түгеллеген хәзер әйтеп торасы да юк. Әлбәттә, революцион демократия төшенчәсен Тукай шикелле художникка карата ялангач социологик яки философик эталон итеп куллану белән генә чикләнеп калырга ярамый. Сүз монда фәкать аның иҗтимагый-политик карашларын формалаштырган бер тарихисыйнфый чыганак турында гына бара. Тукай иҗатын тикшергәндә, шагыйрь һәм демократик революция, шагыйрь һәм халык кебек үзәк мәсьәләләр үзләренең бөтен колачы белән куелырга, шулар яктылыгында Тукайның халыкчанлыгы, реализмы һәм әдәби осталыгы ачылырга тиеш. Шагыйрь иҗатында, һәм гомумән егерменче йөз башындагы татар әдәбиятында, 1905—1907 еллы революция күтәргән демократик идеяләрнең тирән булып тамыр җибәрүе, һичшиксез, аның бөтен тормыш юлын һәм эшчәнлеген хәл иткән төп факторларның, этәргеч сәбәпләрнең иң әһәмиятлесе булды.

Тукайның революцион-демократик идеяләр белән сугарылган халыкчанлыгын һәм реализмын күрсәтү юнәлешендә безнең әдәбият фәне байтак уңышлы ачышлар ясады инде. Шул ук И. Нуруллинның «Тукай эстетикасы» (1956), «XX йөз башы татар әдәбияты» (I кисәк, 1962; II кисәк, 1964) һәм «Тукай иҗаты» (1964) кебек хезмәтләрендә һәм быел басылып чыккан «XX йөз башы татар әдәбияты» дигән зур монографиясендә шундый ачышларның матур үрнәкләрен, нәтиҗәле мисалларын күпләп очратырга мөмкин. Бәхәс кызуында кайбер иптәшләрнең, И. Нуруллин үзе электә яклаган концепциясеннән чигенә, аңа ревизия ясый, дип шелтә белдерүләрен уртаклашу кыен. Моннан берничә вакыт элек И. Нуруллин, мәсәлән, болай язган иде: «Шулай итеп, 1905—07 елгы революция дәвамында татарларда да революцион-демократик иҗтимагый фикер формалашты. Бу исә татар әдәбиятының критик реализм юлыннан китүенә этәргән хәлиткеч факторларның берсе булды. Чынлап та, революцион демократик карашлар яктылыгында язучылар әдәбиятның иҗтимагый роле, чынбарлыкка мөнәсәбәте, иҗат принциплары мәсьәләсен яңабаштан карап чыгарга, яңача аңларга тиеш булдылар»[1].

Шөбһәсез, бу тезисларда бик дөрес фикерләр әйтелгән һәм бүген дә И. Нуруллин аларны тулысы белән яклаганлыгына шик белдерерлек дәлил юк. Егерменче йөз башындагы революцион демократияне И. Нуруллинның соңгы, бәхәсле мәкаләсендә берьяклырак аңлатылган гомуми тарихи-социологик бер мәсьәлә белән аның әдәбиятка турыдан-туры бәйләнештә әйтелгән югарыдагы фикерләрен бер бизмәнгә салып үлчәргә кирәкми. Әмма һәр ике очракта да Нуруллинның революцион-демократик идеяләрне гомумән егерменче йөз башында алдынгы татар әдәбияты формалашуга, ә хосусан Тукай иҗаты үсешенә хәлиткеч йогынты ясаган фактор дип караганлыгы бик ачык. Монда бертөрле дә шикләнерлек урын күренми. Ә менә кайбер чыгышларда революцион демократияне әдәбиятка мөнәсәбәттә эталонга, догмага әйләндерү сыман бер тенденция барлыгы сизелә. Моны И. Нуруллин хезмәтләрендә дә берникадәр төсмерләп була. Аның Тукай иҗатындагы революцион-демократик идеяләр ничек өстенлек ала баруын күрсәтергә омтылышы бер педантлык принцибына әверелеп, туктаусыз кабатланып торуы мәсьәләне артык гадиләштерү, хәтта примитивлаштыру булып тоела башлый: «Җыеп әйткәндә, 1906 елның икенче яртысында һәм 1907 елда Тукай, конституцион иллюзияләрдән арынып, революцион-демократик позициягә басты». «Шулай итеп, Тукайның 1906—1907 еллар поэзиясендә халыкчанлык принциплары җиңеп чыкты». «Шулай итеп, Тукайның 1906 елның икенче яртысы һәм 1907 елны эченә алган иҗатында критик реализмның нигез ташлары салынды»[2].

Бәхәскә тәкъдим ителгән мәкаләсендә дә Нуруллин шул ук фикерләренә ышанычлы булып кала, билгеле. Без монда фәнгә хилаф нәрсә дә булса күрергә теләмибез. Язучының дөньяга карашындагы һәм иҗатындагы үзгәрешле, сикерешле нокталарны,

---

[1] И. Нуруллин. XX йөз башы татар әдәбияты. I кисәк. 1962 ел, 40 бит.

[2] И. Нуруллин. Тукай иҗаты. 1964 ел, 75, 87, 104 битләр.

этапларны конкрет итеп һәм дәлилләп билгеләүнең, күрсәтүнең әһәмияте зур. Ләкин бу очракта Нуруллин биргән схеманы тулаем кабул итүе дә кыен. Чөнки аның ахырына кадәр уйланып җитмәгән урыннары күренә. Шулардан берсе — революцион-демократик позициягә басу өчен, Тукайның конституцион иллюзияләрдән арынуын мәҗбүр итеп кую. Аеруча Тукай иҗатын бәяләгәндә, И. Нуруллин революцион-демократияне кайчакта шундый бер какшамас һәм тел-теш үтмәслек догмага әйләндерә ки, хәтта ул шагыйрьнең «Олуг юбилей мөнәсәбәте илә халык өмитләре» дигән атаклы әсәре «б е р д ә н б е р очрак булуы һәм ул шигырьнең Тукай дөньяга карашын чагылдырмавы турында» катгый рәвештә сүз алып бара һәм, ниһаять, «Олуг юбилей...» шигыре язылуга карамастан, яңа революцион күтәрелеш елларында да Тукай, конституцион иллюзияләрдән азат булып, революцион-демократик позициядә нык басып торды дип, кистереп әйтә алабыз»[1], дигән нәтиҗәгә килә. Димәк, Нуруллин фикеренчә, революцион-демократик караштагы торган язучы һәртөрле каршылык һәм иллюзияләрдән азат булырга тиеш икән. Чынлыкта исә һәм Тукай, һәм аның күп кенә алдынгы замандашлары 1905—07 елгы революциядән соң да конституцион иллюзияләрдән арына алмадылар. Яхшы патша, яхшы конституция һәм яхшы манифест иллюзияләре крестьяннар һәм шәһәр ярлылары арасында бетмәгән шикелле, интеллигенция арасында да бик көчле иде әле. Шулай ук бик күптәннән килә торган мәгърифәтчелек романтикасы да, ягъни җәмгыятьне һәм кешеләрне культура һәм сәнгать аша, акыл һәм әхлак тәрбиясе белән үзгәртү хыяллары да татар язучыларының революцион-демократик карашларына дошман булмадылар. Революцион демократия дигәч тә, аны конституцияләргә, Думаларга һәм мәгърифәткә табынулардан тәмам азат бер идеологик платформа, программа дип аңларга кирәкми. В. И. Ленин революцион-демократик хәрәкәтнең һәм идеяләрнең бик катлаулы һәм каршылыклы булуын күрсәткән иде. Революцион демократия төшенчәсен канунлаштыру һәм аны үз чорына, аны чагылдырган иҗтимагый-сыйнфый катлауларга хас төрле каршылыклардан арындырып карау һич мөмкин түгел. Шулай ук Тукай иҗатындагы халыкчанлык һәм критик реализм принципларының өстенлек алуын, җиңеп чыгуын билгеләгәндә дә, бер-ике ел кысаларына катгый рәвештә кертеп бикләү белән генә мәсьәләне хәл итеп булмый. Бу, әлбәттә, үзенә бер бәхәс һәм детальләштерү таләп итә торган тема. Монда тик искәртү белән генә чикләнергә туры килә.

Шушы уңай белән күтәрелгән тагын бер мәсьәлә — Тукайның алдынгы карашлары формалашуда рус телен үзләштерүенең, рус демократик әдәбиятына һәм революцион публицистикасына юнәлеш алуының әһәмияте. Моның тирәсендәге шау-шуга сәбәп булган нәрсә дә — И. Нуруллинның үзе ясаган схемага сыймаган кайбер фактларны кисеп ташларга яки читкә этәрергә теләве генә. Чынлап караганда, монда шаушу күтәрерлек җитди бернәрсә дә юк. Мона кадәр ныклап расланган һәм күпчелеккә билгеле хакыйкать, ягъни әдәбиятка килгәндә үк инде шагыйрьнең алдынгы рус матбугатыннан азыклануын һәм тәрҗемә итүен аның дөньяга карашыннан, иҗатыннан аерылгысыз бер факт итеп карау, әлбәттә, бәхәссез булып калачак. Хәтта үз замандаш язучыларының иң зур күпчелегеннән аермалы буларак, Тукайның гражданлык идеяләре һәм шагыйрьлеге бик тиз арада өлгерә баруда әнә шул хакыйкать әһәмиятле урыннарның берсен алып торган диярга бөтен нигез бар.

И. Нуруллинның Тукай һәм аның замандашлары иҗатына багышланган хезмәтләрендә татар әдәбиятын тикшерүдәге догматизм һәм социологизм чиренә каршы булган һәм әдәби процессны җанлы фактлар аша күз алдына бастыра торган омтылыш ярылып ята. Хәтта бу яктан ул әлләдән-әле сизелеп торган мавыгучанлыктан да, тенденциозлыктан да тыела алмый. Мин моны кирәкле, яхшы мәгънәсендә аңлыйм. Менә шундый сыйфат безнең күп кенә әдәбият белгечләребезгә һәм тәнкыйтьчеләребезгә җитенкерәми. Әмма шуның белән бергә, догматизмга, социологизмга һәм эмпиризмга каршы көрәш ачып та, кайчакта Нуруллинның шул ук чирләрдән үзенең дә бик үк котыла алмаганлыгын искәртергә туры килә. «Кыскасы, шагыйрь үзе ул турыда уйлаганмы, юкмы, анысы башка мәсьәлә, әмма поэмадан объектив рәвештә чыга торган идея түбәндәгегә кайтып кала: хезмәт ияләре дошманнарга каршы рәхимсез көрәш алып барганда гына, бәхеткә ирешә алачаклар»,— дигән нәтиҗә ясый И. Нуруллин Тукайның «Шүрәле» әкияте турында («Тукай иҗаты», 112 бит). Нәрсә соң бу? Бу — әнә шул алдан әзерләнгән догмадан, ягъни һәр очракта да шагыйрьне «революцион-демократ» иттерү максатыннан, килеп чыккан бер уйдырма гына. Әгәр дә хәзер Тукай сурәтләгән һәм Шүрәлене бик авыр хәлдә калдырган Кырлай егете Былтыр исән булса, биллаһи, ул үзен бу рәвештә көчләп «революционер» итүдән көләр генә иде. Кызганычка каршы, сәнгать әсәрен һәм художникның анда гәүдәләнгән максатларын билгеләү, бәяләү шикелле нечкә мәсьәләләрдә мондый тупас «операцияләр» ясау безнең практикада еш очрый әле.

Язучының иҗатын һәм шәхесен шомартып, бизәп күрсәтү булмаска тиешлекне, һәрвакыт тарихи дөреслеккә һәм реаль фактларга таянып эш итәргә кирәклекне таләп итүе белән И. Нуруллин хаклы. Шулай ук аның Тукай әсәрләрен, шагыйрь турындагы истәлекләрне матбугатка чыгару һәм файдалану практикасындагы бозуларга, «ясауларга» борчылуы һәм ачулануы да бик урынлы. Андый мәгънәсезлекләргә моннан соң юл куелмаска, зур саклык белән, тарихи һәм фәнни гаделлек

[1] И. Нуруллин. XX йөз башы татар әдәбияты. 1966 ел, 179—180 битләр.

белән эш ителергә тиеш дигән таләпне хуплаудан башка бернәрсә дә әйтеп булмый. Әмма тарихи дөреслек дигәч, аны ниндидер чиге-чамасы һәм бүгенге таләп-максатларыбызга һичбер бәйләнеше булмаган абсолют бернәрсә дип тә аңларга ярамый, билгеле. Тарихның чүплек башында яткан һәм шунда гына ятарга тиешле әллә никадәр фактлары бар. Әгәр аларның һәммәсен туздырып, казып һәм өстерәп чыгарсаң һәм кабат өеп куйсаң да, Тукай әйтмешли, чүп һаман чүп булып кына калачак. Бигрәк тә тарихта һәм халык күңелендә үзләренең иң әлек якты эзләре, яхшы эшләре белән урын алган шәхесләр турында хөкем йөрткәндә, алар тормышында, эшчәнлегендә очраган «чүп-чарларны», киңрәк мәгънәсендә — кимчелек һәм каршылыкларның урынын, чамасын бик белеп үлчәргә кирәк. Бер кашык деготь бер мичкә балны боза, дигән гыйбрәтле сүзләр юкка гына әйтелмәгән.

Конкрет алганда, Тукай шәхесен, тормышын һәм иҗатын тикшерүдә дә, барыннан элек, тарихи объективлык өстенлек итәргә тиеш. Ә тарихи объективлык — ул чүп савыты яки уйдырмалар капчыгы түгел, ә дөреслекнең иң кирәкле, иң әһәмиятле сыйфатлары һәм фактлары дигән сүз. Әмма моның белән әле без тарихи объективлыкны үзенең һәртөрле каршылык һәм кимчелекләреннән тамам чистартылган хәлдә генә аңларга да чакырмыйбыз. Шуның шикелле, Тукай һәм аның заманын, замандашларын бәяләгәндә, тикшергәндә дә, тарихи объективлык үзенең әһәмиятле каршылыклары, уңай һәм кире яклары белән алынуын телибез һәм таләп итәбез. Бер караганда, бик элементар һәм гади булган бу диалектик хакыйкать аңыбызда һәм гыйльми практикабызда һәрчак бик төгәл генә бер нормага әйләнеп җитмәгән шикелле.

Безнең әдәбият фәне Тукайны, аның заманын һәм замандашларын гел кире яки гел уңай яктан гына күрсәтү кебек берьяклы тенденциоз карашлардан байтак югары күтәрелде инде. Анда чын, яхшы мәгънәсендәге тарихи объективлык өстенлек итүен күрмәү урынсыз киреләнү генә булыр иде. Байтак вакытлар хөкем сөргән һәм әдәбиятның тецкәсенә тигән, аның бәгырен суырган вульгар социологизм күптән инде тәхетеннән бәреп төшерелде. Ләкин ул бирешергә һәм үз позициясен калдырырга теләми. Әледән-әле үзенең ярык күсәкләрен селкеп, болгап ала, кизәнә. Тукайга карата да аның шундый кыланышлары тәмам беткән дип булмый.

Шагыйрьнең дөньяга карашында һәм гомумән иҗатында чагылган каршылыкларны күрү, күпертү яки күрмәскә тырышу тенденцияләренең бүген ниндидер капма-каршы төс алганлыгын раслау читен. Монда сүз фәкать шуларга охшаш аерым очраклар, фактлар турында гына барырга мөмкин. Хәзер инде беркем дә Тукай гел чыгышсыз каршылыклар, саташулар корбаны гына булган яки, киресенчә, алардан бөтенләй азат һәм өстен торган «әүлия» дип тә хөкем итәргә уйламыйдыр. Чөнки тарихи барыш һәм фәнни үсешебез мондый карашларның чынбарлыктан ерак догмалар икәнлеген күрсәтәләр. Әмма, шуның белән бергә, теге яки бу әдәби мәсьәләне һәм язучыны өйрәнүдә, бәяләүдә катгый нормалар һәм рецептлар тәкъдим итү дә фәнни иҗат кысаларына сыймаячак.

Без монда Тукайның каршылыклары нидән гыйбарәт икәнлеген сөйләү максатын куймыйбыз. Моңа кадәр чыккан хезмәтләрдә аларга билгеле урын һәм бәя бирелде инде. Шунда ук бу бәхәс уңае белән телгә кергән дингә мөнәсәбәт мәсьәләсе дә чагылыш тапкан иде. Әмма Нуруллинның һәм аның белән бәхәсләшкән авторларның бу мәсьәләгә кагылышлары үткен, хәтта ниндидер принципиаль төсмер алганлыктан, аны читләтеп үтү дә урынсыз шикелле. Тукайның дингә мөнәсәбәте каршылыклы һәм аны күрми китү мөмкин түгел, дигән билгеле хакыйкатьне искә төшереп, үзенчә исбатлаганнан соң, Нуруллин мондый бер нәтиҗә ясый: «Күрено ки, әхлак мәсьәләсенә гаять зур игътибар биргән безнең демократ язучыларыбыз да дингә арка белән борыла алмыйлар иде. Бу аларның дөньяга карашында тарихи сәбәпләр белән аңлатыла торган каршылык иде. Сүз арасында шуны да әйтик: мәсьәләне әнә шул рәвешле куюэдәбият тарихындагы күп кенә кыен һәм четерекле мәсьәләләрне шактый җиңел хәл итәргә мөмкинлек бирә» («Казан утлары» журналы, 1966 ел, 3 сан, 123 бит).

Нуруллинның бу тезисы, татар демократик әдәбиятында чагылган дини караш һәм тойгылар кешеләрнең әхлагын яхшырту һәм сыйныфларны үзара татулаштырып, бәхетле тормышка алып чыгу утопиясеннән аерылгысыз, дигән мәгънәне эченә ала. Мондый карашларның ул чорда булуын кире кагу мөмкин түгел, әлбәттә. Әмма мәсьәләнең иң әһәмиятле ягы андамы соң? Моның тирәсендә сүз кыздыруның кирәге юк шикелле. Тик шуны гына әйтергә мөмкин: безнең алдынгы эшлекләребезнең дини реакцияне һәм дин исеменнән һәртөрле рухи һәм материаль изүләрне фаш итеп чыгулары аларның дингә ышануларына караганда күчлерәк, прогрессиврак һәм әһәмиятлерәк булуын тагын бер мәртәбә искә төшерергә туры килә. Бу яктан караганда да, Тукай шикелле, дингә һәм дин әһелләренә каршы халыкта нәфрәт тәрбияләгән икенче бер татар язучысын күрсәтүе кыен кебек. Әлбәттә, Тукайны турыдан-туры атеист дип атарга маташу — тупас фальсификация, урынсызга күпертү. Моны һич тә гафу итәргә ярамый. Әмма шагыйрьнең халык интересларын һәм кеше азатлыгын яклап, дини коллык һәм капитал изүе белән көрәшкә чыгуы — гаҗәп тә зур кыюлык иде. Менә шул ягы белән Тукай үзенең һәртөрле дини ышанычларыннан күп югары күтәрелде һәм халыкка якын булды. Болай дию белән, без мәсьәләне гел бер яссылыкта һәм бер яктылыкта гына куярга өндәмибез. Аны бөтен катлаулылыгы һәм каршылыгы белән алып караганда, тарихи объектив орлыгы иң элек нинди

жирлеккә төшеп, нинди җимеш һәм нәтиҗә бируен күрергә кирәк.

Бер Тукайның гына түгел, күпләгән татар язучыларының тормыш һәм иҗат фактларын бөтен байлыгы һәм тәгаллеге белән өйрәнү эше әле тиешле дәрәҗәгә куелмаганлыгы — барыбызны да борчыган нәрсә. И. Нуруллинның моңа басым ясап сөйләве бик вакытлы һәм урынлы. Р. Нафигов та моны куәтләп, бу өлкәдә барлык мөмкинлекләрне эшкә җигәргә, файдаланырга чакыра, кул тимәгән әллә никадәр кыйммәтле фактик материалларның архивларда һәм аерым кешеләрдә күмелеп ятуын искә төшерә. Әмма ахырына кадәр тикшерелмәгән һәм алда бик зур булып ачылып китүе мөмкин булган фактлар инде «юк» дип кисеп куюдан да сакланырга кирәк. Мондый ашыгыч нәтиҗә фән белән сыеша алмый. И. Нуруллинның, Тукай цензура, полиция һәм жандармерия күзәтүе астында тормаган, дип мөһер сугуы бик соңга калып әйтелгән гипотеза гына. Чынлап та, моңа кадәр матбугат битләрендә күренгән һәм Р. Нафигов мәкаләсендә китерелгән документлар бер Тукай гына түгел, аның шикелле безнең күпләгән алдынгы әшлекләреләребез патша ялчыларының өзлексез күзәтүе, кысрыклавы, янавы, куркытуы астында торганлыкларын исбатлыйлар. Минемчә, моңа карата бәхәс кузгату урынына бу тарихи фактларны нык лап тикшерү һәм барлау белән шөгыльләнү күбрәк, мәгънәлерәк нәтиҗә бирер иде. Югыйсә алар, ул документ һәм фактлар, үзләренең тырыш тикшерүчеләрен һәм дөрес хөкем итүчеләрен көтеп яталар.

Күбебезнең эчен пошырган һәм хәтта ниндидер бер чиргә әйләнгән нәрсә — күренекле язучының тормышына һәм иҗатына бәйле фактны тиешле дәрәҗәдә тикшерми-нитми файдаланырга омтылу яки файдалану. И. Нуруллинның моңа карата да шелтә белдерүе һәм борчылуы бик урынлы. Мәсәлән, төрле вакытларда сөйләнгән сүзләр һәм язылган истәлекләр бар. Аларның сыйфаты да, дөреслеге дә төрле дәрәҗәдә. Ә без исә тотабыз да аларны ниндидер тарихи һәм фактик дөреслеккә ия булган документлар, чыганаклар иттереп, фәнни тикшеренүләрнең нык лы дәлиле дәрәҗәсенә күтәрә башлыйбыз. Соңгы елларда Тукай һәм башка язучылар турында замандашларының истәлекләрен җыю һәм матбугатка чыгару активлашып бара. Бу — гомумән мактаулы эш. Ләкин тагын да киңрәк колач бирергә кирәк. Ләкин болар арасында заман үтү белән бик тоныкланган, үзгәргән, бозылган, арттырылган һәм хәтта уйдырмага әйләнгәннәре дә бар. Мәсәлән, М. Гайнуллин «Дөреслекне төгәл яктыртыйк» («Казан утлары» журналы, 1966 ел, 7 сан) дигән мәкаләсендә профессор Г. Клячкинның сугыштан соң чыккан истәлекләрен Тукайны өйрәнүдә ышанычлы һәм дөреслекне төгәл яктырткан чыганаклар дип тәкъдим итә. Әмма дикъкать белән карасаң, аңарда Тукайны бик тә югары күтәрүне максат иткән «шагыйрәнә ялган» кычкырып тора. Профессор Клячкинның Тукайны үлемнән коткару өчен чын күңелдән тырышуына да һәм үлем түшәгендә яткан шагыйрьнең кәефен күрергә теләвенә дә без ышанабыз. Ләкин «Колокол»ның аерым номерларын, Герценның «Белое и думы»сын, Чернышевскийның «Что делать?» кебек әсәрләрен, ягъни махсус рәвештә революцион-демократик әдәбиятны җыеп китерүенә бик шикләнәбез. Чөнки шундый авыр хәлдә яткан шагыйрьгә врач булган кешенең мондый бүләкне тәкъдим итүе табигый түгел. Ә шуны «һәр ялтыраган алтын» дип дәгъва кылучыларның: «Менә бу китерелгән документлар һәм истәлекләр Тукайның никадәр киң карашлы, белем даирәсенең никадәр бай булуын раслыйлар...» дип исләре китүгә хәйран каласың. Бу — җитди мәсьәләгә җавапсыз караудан яки һәр «кызыл сүзгә» алданудан башка бернәрсә дә түгел. Шулай ук И. Нуруллин Тукайның Уральск чорына яисә Астраханьга баруына бәйле кайбер истәлек һәм фактларга карата шик белдерә икән, моңда фәнни саклыкны, уяулыкны һәм тарихи дөреслекне кайгыртудан бүтән нәрсә юк.

Тукай тирәсендә башланган бәхәстән нинди нәтиҗә чыгарырга мөмкин соң? Гомумән татар әдәбиятын, аның үткәнен һәм бүгенгесен, аерым язучыларның иҗатын һәм тормышын өйрәнүгә булган таләпләр көннән-көн үсә. Бу юлда кыю фикер һәм бәхәсләрнең мәйданга чыгуы табигый һәм зарури. Мондый ихтыяҗны чикләү яки туктату мөмкин түгел. Чөнки яхшы бәхәс — чын һәм җанлы фәнни фикер өчен догматизмга каршы көрәшнең бер төре. Безнең әдәбият фәненең әле әллә никадәр күтәрелмәгән яки күтәрелеп тә тиешенчә яктыртылмаган, эшкәртелмәгән һәм хәл ителмәгән бик кызыклы, әһәмиятле мәсьәләләре бар. Моннан соң шуларга да ныграк игътибар ителсен иде.

# ТУКАЙНЫҢ ТӘРҖЕМӘИ ХӘЛЕ ХАКЫНДА БЕРНИЧӘ СҮЗ

Тукайның Кушлавычтан Уральск чорына кадәрге тормыш юлы «Исемдә калганнар»да язылган инде. Газизә Зәбированың да энесе Тукай тормышына багышланган ике мәкаләсе бар. Аларның берсе «Совет әдәбияты» журналының 1936 елгы 7 санында басылган иде. Соңыннан ул «Тукай турында замандашлары» исемле истәлекләр китабына да кертелде. Икенче мәкалә исә 1961 елда «Азат хатын» журналының апрель санында чыкты. Бу ике мәкаләдә Габдулла Тукайның Кушлавычтан башлап Казанга килгәнче узган тормышы турында сөйләнелә.

Шагыйрьнең Уральскидагы тормышы турында, Газизә Зәбировадан башка да, күп кенә иптәшләр язды. Шулар арасыннан Габдулла Кариев, Шәриф Каюмов, Камил Мотыйгый истәлекләрен күрсәтеп үтәргә мөмкин. Бу истәлекләрне игътибар белән укыганда, шул нәрсә күзгә ташлана. Авторлар, Тукайның тәрҗемәи хәленә кагылышлы вакыйгалар турында язганда, байтак төгәлсезлекләр, фактик ялгышлар җибәргәннәр.

Камил Мотыйгыйның «Мәшһүр шагыйрь Габдулла Тукаев турында хатирәләрем» исемле язмасын алыйк. Ул болай башлана: «Мин бик яхшы беләмен ки, иң әүвәл Габдулла Тукаев үзе шикелле яшь кенә Мөхәммәтгали исемле бер ятим бала берлә Уральскига Галиәсгар Госманов исемле бер байның өенә килеп төштеләр»[1].

Инде Тукайның апасы Г. Зәбированы тыңлап карыйк. Аның «Тукай хакында истә калганнар» исемле мәкаләсендә шундый юллар бар: «Габдулла килгән кыштан соңгы җәен җизниләр Казанга барып килделәр. Аннан кайтканда, үзенең якын тиешлеләреннән Мөхәммәтгали һәм Фәйрүзә дигән ике ятим кардәшләрен алып кайттылар»[2].

Күрәсез, Мөхәммәтгали исемле ятим бала Уральскига Тукай белән бер үк елны килмәгән икән.

Бераз астарак К. Мотыйгый болай ди: «Шул вакытта Уральскида мәзкүр байның җәмәгате Газизә апа, мәрхүм Тукаевка бераз якын тиешле булганга күрә, аларны авылдан тәрбия кылырбыз дип чакырткан дип сөйләнде».

Сүз монда Тукайның әтисенең бертуган сеңелесе Газизә Усманова турында бара. Шулай булгач, Газизә апа «бераз якын тиешле» кеше генә буламыни инде?!

«Бераздан соң,— дип дәвам итә К. Мотыйгый,— өй хуҗасы Галиәсгар Госмановның бирдәнбер зирәк Габдулла исемле бик шук һәм бик кадерле генә угыллары үлеп киткәч, үз өйләреннән боларны (сүз Тукай белән Мөхәммәтгали турында бара — Х. З.) бөтенләй мәдрәсәгә торырга күчерделәр».

Бу сүзләрнең берсе дә дөрес түгел. Беренчедән, Г. Госмановның улы Габдулла түгел, ә Гобәйдулла исемле иде. Икенчедән, Габдулла Тукай Уральскига Гобәйдулла үлеп бер ел узганнан соң килә һәм мәдрәсәдә торырга Г. Госманов вафат булгач кына күчә.

Камил Мотыйгыйның «Ул (Тукай — Х. З.) инде русчадан да сабак ала башлап, Әхмәтшаһ Сиражетдинов исемле, мөселман балаларына русча укытучы учительга йөри башлаган иде. Аннан, ни өчендер, бөтенләй тәмам итмәенчә чыкты», дигән сүзләре дә чынбарлыкка туры килми. Габдулла Тукай татар балалары өчен ачылган өч еллык бу мәктәптә аны тәмамлаганчы укый.

Югарыда китерелгән фактлар халык шагыйре Габдулла Тукайның тәрҗемәи хәлен өйрәнүнең торышы канәгатьләнерлек дәрәҗәдә булмавын күрсәтә. Шагыйрьнең тулы тормыш юлын дөрес яктырту галимнәребез алдында торган мөһим бурычларның берсе булып саналырга тиеш.

*Х. ЗӘБИРОВ*[3].

[1] Г. Тукай турында замандашлары. 1960 ел. 62 бит.

[2] Шунда ук, 41 бит.

[3] Хөсәен Габдрахман улы Зәбиров — Тукайның апасы Газизә Зәбированың туганы; хәзерге вакытта «Татнефтьпроект»ның Казан бүлегендә баш инженер булып эшли.

# СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ

## ХУДОЖНИКНЫҢ ЭЗЛӘНҮЕ

Илдар Әхмәдиевның тормыш юлы озын да, катлаулы да түгел: 1935 елда Казанда эшче семьясында туган, ул елларда туган һәр кешенеке шикелле Илдарның да бала чагы авыр елларга, сугыш чорына туры килә. Малай чактан ук ул художество мәктәбенә йөри. Черек күлдә урнашкан бу мәктәпнең салкын һәм ярым караңгы бүлмәләрендә малайлар, бер-берләре белән ярыша-ярыша, сәгатьләр буе рәсем ясыйлар. Илдарны кечкенә генә уңыш та, кечкенә генә җиңү дә дәртләндереп җибәрә һәм ул үзенә хас бер хиреслек белән яңадан бәләкәй мольбертны артына баса.




Сабан туе.

Еллар үтә. Илдар Казан художество училищесын тәмамлый. Тын океан флотында диңгезче булып хезмәт итә. Хәрби хезмәт аңарда ихтыяр көче һәм үз-үзенә карата таләпчәнлек сыйфатлары тәрбияли. Илдар иҗат эшен дә ташламый: флотта чыгарыла торган «Сугышчан вахта» газетасы өчен рәсемнәр, плакатлар ясый, фоторәсемнәр төшерә, очерклар яза. Хәрби хезмәттә узган еллар эчендә Илдар шактый бай иҗат тәҗрибәсе туплап өлгерә, рәсем сәнгатенең төрле өлкәләрендә эшләп, йөзләрчә әсәрләр иҗат итә, художник буларак үз почеркын таба.

1959 елда Илдар Әхмәдиев туган Казанына әйләнеп кайта. Армиягә киткәнче үк «Чаян» журналында сатирик рәсемнәре белән катнаша килгән художник шунда ук киеренке иҗат эшенә чума, Татарстан китап нәшрияты художниклары арасында иң актив авторларның берсенә әйләнә. Бик аз бер ара эчендә ул төрле язучыларның иллегә якын китапларын рәсемнәр белән бизи алды. Алар арасында Г. Әпсәләмовның



Каз өмәсе.

«Алтын йолдыз», Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романнары, Х. Туфанның «Юкмыш бабай малае» әкияте кебек зур күләмле һәм катлаулы эчтәлекле әсәрләре дә бар иде.

Гадәттә, Илдар көн саен сәгатьләр буе гел рәсем ясау белән генә шөгыльләнә. Ләкин никадәр генә киеренке эшләмәсен, аның күпчелек хезмәтләре чын сәнгатьчә югарылыкта башкарылган була. Дөрес, кайбер рәсемнәрдә ашыгып эшләү нәтиҗәсендә килеп чыккан кимчелекләр дә күренеп куйгалый. Күрәсең, художник үзе сайлаган образның эчке хасиятләрен төшенеп җитә алмаган очракларда шулай килеп чыгадыр. Ләкин мондый хәлләр Илдар иҗатында торган саен сирәгрәк очрыйлар, үз иҗатына ул торган саен таләпчәнрәк карый бара. Кичә эшләнгән рәсем бүген инде аны канәгатьләндерә алмый һәм ул яңадан эшкә утыра, бетмәс-төкәнмәс эзләнүләрен дәвам итә. Эзләнү — кыюлык, тәвәккәллек дигән сүз, ә тәвәккәллек исә ике яклы була. Бирегә Илдарны тумыштан килә торган сәләте коткарып кала, шул аңа сәнгать чигенең теге ягына, буш формализмга тәгәрәргә ирек бирми.

Үз эшенә җитди карап, сәнгатьтәге төрле жанрларның үзенчәлекләрен яхшы белү И. Әхмәдиевка сурәтләү телен баетырга һәм төрләндерергә, һәр басманың



Студентлар.

үзенә генә хас сәнгатьчә бизәк чаралары табарга ярдәм итә. Мәсәлән, сатирик темаларны хәл иткәндә аның почеркы бераз чәнечкеле-кискен төс ала. Инде балалар өчен чыгара торган китапларның рәсемнәрен ясаганда Илдар кулланган буяулар йомшаграк, ягымлырак була, сызыклар нәфисләнә, ә төсләр ачыклана төшәләр. С. Гыйльметдинованың «Ринат» һәм Р. Фәйзуллинның «Рәсем ясыйм» исемле китапларындагы рәсемнәр нәкъ менә шулай эшләнгәннәр дә инде. Ч. Айтматовның повестьлары җыентыгын бизәү өчен художник үзенә бертөрле — Көнчыгыш сәнгате рухына якын чишелеш таба алган. Ә менә Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар»ы өчен ул кырыс төсләрдән акварель рәсемнәр ясаган. Бирәдә инде художник җитди, ул, язучы белән бергә, әсәрдәге бөтен вакыйгаларны үз күңеле аша кичерә, дулкынлана һәм бу дулкынлану аның рәсемнәрендә дә чагылыш таба. Аз сызыклар һәм тыйнак төсләр аша художник зур тарихи-революцион теманы ачып биргән. И. Әхмәдиевның «Иикмән» дип исемләнгән рәсемнәр сериясе бар. Шул сериядән «Продотряд» исемле бер рәсем «Зур Идел» күргәзмәсендә дә күрсәтелде һәм югары бәя алды.

Вакытының һәм көченең зур өлешен Илдар «Азат хатын» журналын бизәүгә бирә. Ул журналның сәнгатьчә үз йөзен булдыру турында хыяллана һәм шуңа омтыла да. Бу яктан караганда, журналның 1964 һәм 1965 еллардагы ноябрь саннарының тышлык рәсемнәре аеруча игътибарга лаеклы.

Күптән түгел яшь художникка мастерской бирелде һәм ул, бөтен энергиясен биреп, үзенең күптәнге хыялларын тормышка ашыру эшенә керešте. Илдар әсәрләрен игътибар белән рәк караган кеше художникның тарихи-революцион темалар өстендә яратып эшләвен һәм бу зур теманы катлаулы психологик сурәтләр аша ачарга омтылуын күрер. Шул ук вакытта ул татар халкының тормыш-көнкүреше белән бәйле орнамент-бизәкләү композицияләре иҗат итү юнәлешендә дә эзләнә. Художник үз әсәрләренең тагын да ачыграк, тулырак фикерле, көчлерәк тәэсирле булуларына омтыла. Мондый эзләнүләр художниктан даими рәвештә профессиональ культурасын күтәрә баруны таләп итәләр. И. Әхмәдиевның «Яшь Тукайның портреты» һәм «Сабантуй» исемле соңгы әсәрләре бу яктан да зур игътибарга лаек. Яшь художникның зур осталык сорый торган олы темаларга мөрәҗәгать итүен хупларга гына кирәк.

Хәзер Илдар Әхмәдиев «Зур Идел»нең киләчәктәге күргәзмәсенә әзерләнә. Аның игътибар үзәгендә — В. И. Ульянов тормышының Казанда үткән чорын һәм татар халкының туй йолаларын җанландыру.

А. ФАЙНБЕРГ,
сәнгать белгече.

# ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА ШАГЫЙРЬ

## ШАГЫЙРЬНЕҢ ИҖАТ ШАТЛЫГЫ

Шундый чишмәләр була. Син аларның яр читендәге вак ташларга бәрелеп челтерәвен дә, тал-куаклар арасыннан нинди тизлек белән акканлыкларын да тоймыйсың. Алар, җир куеныннан алган моңнарын тирәнрәк яшереп, юри шулай тын гына, салмак кына агалардыр шикелле. Нури Арсланов шигырьләрен укыганда, ни өчендер, шундый чишмәләр күз алдына килеп баса. Моның сәбәбенә шагыйрьнең теге яки бу җыентыгына тупланган шигырьләре белән тулырак һәм якынрак танышканнан соң гына төшенәсең. Аның күпчелек шигырьләре вакыйгаларны өстән-өстән генә сөйләп чыгуга, фикерне турыдан-туры әйтеп бирүгә түгел, хис һәм тойгыларның эчке яңгырашына, эмоциональлегенә корылган. Сүзебезне раслар өчен, үзенчәлекле бу шагыйрьнең Татарстан китап нәшриятында быел басылып чыккан «Дилбәр» исемле җыентыгындагы кайбер шигырьләренә мөрәҗәгать итик.

Менә «Ак таңнар» шигыре. Анда түбәндәге юллар бар:

**Тып-тын һава алмаз бәскә тулган,**
**Керфекләрдә көмеш чаткылар...**
**Әнә төнен түбәләрдә кунган**
**Күгәрченнәр канат кактылар.**

Әлеге шигъри юлларны укыганда, кешеләрнең йөзләренә, керфекләренә көмеш чаткылар сирпегән таңның гүзәллеген, шул таң кочагында елмаеп уянган шәһәрнең матурлыгын, сихри ямен үз күзләрең белән күргәндәй буласың. Туган җиргә, Тукайлар һәм Сәйдәшләр моңы тирбәлгән үзәннәргә, тыныч иртәләрне сөенеп каршылаган Казан урамнарына карата булган мәхәббәтең тагын да үсә, көчәя. Шагыйрь, икенче төрле итеп әйткәндә лирик герой, күңелендә туган хисләр һәм кичерешләр синең үз хисләрең, үз кичерешләрең булып әверелә. Шуңа күрә шигырьнең соңгы юлларын тагын бер тапкыр кабатламый булдыра алмыйсың:

**Нинди юмарт январь бураннары,**
**Нинди матур бездә ак таңнар!**
**Тынып яткан Казан урамнары**
**Ап-ак кардан чәчәк атканнар.**

Нури Арсланов иҗатында туган җир һәм Ватан, ирек һәм тынычлык, яшьлек һәм мәхәббәт темалары шактый урын алып тора. Аның бу темаларга багышлап язган шигырьләрендә замандашларыбызга хас матур сыйфатлар гәүдәләнә. Ул сыйфатларның берсе һәм иң күркәме — илгә, халыкка үз-үзеңне аямыйча хезмәт итү, тормышта кешеләр бәхете өчен янып яшәү. Лирик геройның һаман да яшьлек сафында калырга, күңелендәге куаныч, шатлык хисләрен һәрвакыт башкалар белән уртаклашырга теләвен белдереп, «Бәйрәмдәге уйлар» шигырендә автор болай ди:

**Минем һаман әле яшьләр кебек**
**Ялт итәсем килә.**
**Үз шатлыгым белән бик күпләрне**
**Шат итәсем килә.**

Шагыйрь ул, барыннан да элек, кеше күңеленең сердәше, аерылгысыз һәм тугрылыклы юлдашы булырга тиеш. Шулай булмаганда, укучы аның беренче зат исеменнән сөйләгән сүзләрен, уй-фикерләрен үзенеке итеп кабул итмәячәк. Нури Арсланов моны бик яхшы аңлый. «Бәйрәм хөрмәтенә», «Минем шатлыгым», «Йөрәк», «Түзем», «Күз карасы кебек», «Сак була күр» һәм башка шундый шигырьләрендә авторның укучы белән аерылгысыз бәйләнештә торуын күрәбез. Җылы, ягымлы хисләр нигезендә туган бу бәйләнеш аларны берберсенә якынайтканнан якынайта.

**Ул сөя җир яшеллеген,**
**Күктәге кояш нурын,**
**Ул сөя күңел яшьлеген**
**Һәм тормыш матурлыгын.**
**Кемгә кирәк соң буш йөрәк,**
**Талпынмаса, янмаса?!**
**Йөрәк яхшы — янса көйрәп,**
**Сөюдән туялмаса,—**

ди Н. Арсланов «Йөрәк» шигырендә. Бу поэтик юлларда җиргә һәм тормышка бөтен күңеле белән гашыйк булып яшәүче бик күп замандашларыбызның фикере чагыла.

Нури Арсланов — җыр жанры өлкәсендә актив эшләүче шагыйрьләребезнең берсе.

Җыентыктагы алтмышка якын оригиналь әсәрнең егермедән артыгы «Җырлар» бүлегендә басылган. Аларның тематикасы шактый киң. «Зоя», «Казан иртәсе», «Ник кордаш түгел», «Ак юл сезгә», «Хыялый төндә», «Билгесез солдат кабере янында», «Планетам минем» кебек җырларда совет кешесенең батырлыгы, рухи байлыгы, мораль сафлыгы, планетаның иминлеген, җирдәге барлык халыкларның якты киләчәген яклап көрәшүче дусларыбызның бердәмлеге тасвирлана. Бу шагыйрьнең җырларын, ноталарын да урнаштырып, аерым китап итеп бастырып чыгарганда бер дә начар булмас иде. Композиторларыбыз тарафыннан көйгә салынган күп кенә җырларның бу җыентыкта булмавын да искә алсак, моның кирәклеге үзеннән-үзе сорала.

Татар укучысын классик поэзия үрнәкләре, рус һәм башка милләт әдипләренең яңа әсәрләре белән таныштыруда Нури Арслановның өлеше шактый зур. Пушкин, Лермонтов, Байрон, Шелли, Райнис һәм башка шагыйрьләрнең күп кенә шигырьләре белән татар укучылары Н. Арсланов тәрҗемәсе аша танышты. Ул тәрҗемәләрнең кайберләрен әлеге җыентыкка кертеп, нәшриятның матур әдәбият редакциясе бик дөрес эшләгән. Югыйсә, бездә шагыйрьнең күңел салып, күп көч куеп эшләгән тәрҗемәләренә аның җыентыкларында урын бирү бөтенләй диярлек практикага кертелмәгән. Киләчәктә бу кимчелек, һичшиксез, бетерелер дип ышанырга кирәк.

Җыентыктагы тәрҗемә шигырьләр турында сүз чыккач, тагын шуны әйтеп китәргә кирәк. Бу тәрҗемәләр, ни өчендер, оригиналь әсәрләр белән аралаштырылып бирелгәннәр. Алар бер тирәгәрәк тупланып, җыентыкның ахырында аерым бүлек итеп бирелгән булсалар, яхшырак булыр иде. Яңа җыентыкларын әзерләгәндә шагыйрь моны исендә тотарга тиеш.

Инде әйтеп үткәнебезчә, Н. Арсланов шигырьнең музыкальлегенә, күңелендә туган уйларын, фикерләрен гади һәм тыйнак итеп әйтеп бирү өчен сүзләр сайлауга зур әһәмият бирә. Ләкин шул ук вакытта ул кайбер гөнаһлардан да азат түгел. Кайбер шигырьләрнең исемнәренә генә игътибар итик. «Бәйрәмдәге уйлар», «Уйлар, хыяллар», «Хыялый төн», «Бәйрәм хөрмәтенә», «Шагыйрь һәйкәлен ачканда», «Һәйкәл янында», «Мәҗлес җыры», «Кара-каршы җырлар», «Пушкин җырлары» шикелле сүз тезмәләре җыентыктагы шигырьләрнең исемнәрендә үк еш кабатлана. Боларга тагын шигырь юлларындагы:

**Тик үз җаным тыныч түгел минем,**
**Тынычлыкны артык сөйгәнгә...**

яки

**Ул җиргә тынычлык тели,**
**Тик үзе тынмый бер дә,—**

рәвешендәге кабатлауларны да өстәсәк, шагыйрьнең әле тел байлыгыннан тиешенчә файдаланмавын күрәбез.

Болар, әлбәттә, бик тиз төзәтергә мөмкин булган кимчелекләр. Алардан арыну өчен Нури Арслановның поэтик тәҗрибәсе дә, талант көче дә җитәрлек. Аның шигъри чишмәсе яңа көйләргә бай. Киләчәктә шагыйрь ул көйләрне безгә тагын да мулрак, тагын да көчлерәк ишеттерер дип өметләнәбез.

Рәшит ГӘРӘЙ.

*Халык мәзәкләре*

**ОЕШКАН ТОКМАЧ**

Бер килен токмач пешерә белми икән. Аның токмачы чукмар-чукмар оешып бета торган булган. Ире, кунакларга хатынының эш рәте белмәвен сиздерәсе килмичә, өсталгә аш китереп куюю белән:

— Эх, яратам да соң шушы оешкан токмачны,— диган булып, табантагы чукмар-чукмар оешкан камырларны үзе җыеп ала барган. Моны күреп, килен куанып киткән.

— Алай бик яратсаң, әле казанда менә мондыйлары да калды,— дип йодрыгын күрсәткән.

# ЮБИЛЯРЛАРНЫ КОТЛЫЙБЫЗ!

*Быелгы сентябрь әдәби бәйрәмнәр ае: без өч язучыбызның юбилейларын билгеләп үтәбез. Юбилярларыбызның өчесе дә татар совет әдәбиятын үстерүгә күп хезмәт куйган, үзләренең әсәрләре белән киң катлау укучылар арасында популярлык казанган танылган каләм осталары, өчесе дә, нигездә, проза әдәбиятында эшләүчеләр. Тик яшьләре генә төрлечә.*



*Һәрвакыт көр күңелле, яшь йөрәкле өлкән язучыбыз Идрис ага Туктарга 70 яшь тулды. Ул бай һәм озын иҗат юлы үткән. Аның беренче әсәрләре ярты гасырлап элек — 1923 елда басылып чыга. Үз әсәрләрендә Идрис ага патша армиясендәге солдатлар, революциягә кадәрге Россиядәге эшчеләр һәм шахтерлар тормышын сурәтли, гражданнар сугышы геройларын, совет халкының коммунизм төзү өчен көрәшен күрсәтә. Өлкән язучыбыз үзенең 70 еллыгын «Ике егет» исемле яңа романы белән каршылады.*



*Габдрахман ага Минский әдәбият мәйданына романтик ашкынулар белән тулы шаулы, давыллы елларда — егерменче елларның икенче яртысында килә. Һади Такташ, Гадел Кутуйларның замандашы һәм каләмдәш дусты була, алар бер идеаллар, уртак уй-хисләр, теләкомтылышлар белән яшиләр. Алда без юбилярларыбызның өчесе дә, нигездә, проза әдәбиятында эшләүчеләр, дидек. Габдрахман Минскийга карата бу сүзләр якынча гына туры килә. Күпләгән повесть һәм хикәя-*

*ләр язу белән бергә, ул дистәләрчә сәхнә әсәрләре, киносценарийлар, публицистик мәкаләләр авторы да.*

*Үзенең 60 еллыгын Габдрахман ага Минский яңа повесть төгәлләп каршылый.*



*Юбилярлар арасында иң яше — Атилла Расих. Аңа нибары 50 генә тулды. Бүген ул татар проза әдәбиятын алга әйдәүче, аның беренче сафларында атлаучы әдипләребезнең берсе. Соңгы берничә ел эчендә генә дә Атилла Расих әдәбиятыбызның казанышы булырлык «Язгы авазлар», «Ике бүйдак» кебек романнар иҗат итте. Без аның киләчәктә дә әдәбиятыбызга берсеннән-берсе яхшырак әсәрләр бирәчәгенә шикләнмибез.*

*Кадерле язучыларыбыз!*

*Күп меңләгән укучыларыбыз исеменнән Сезне иҗат бәйрәмегез белән котлыйбыз! Сезгә озын гомер, сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары теләп калабыз!*

**«КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕ**

## КИТАП КҮЗӘТҮ

# КОЯШНЫ КАРШЫЛАП

Әдәби очеркның әдәбиятта һәм тормышыбызда тоткан урыны хакында сүз куертып торуның хаҗәте юк. Ләкин без, кулына каләм-кәгазь тоткан кешеләр, очеркның көн кадагына сугып баручы гаять тә кирәкле һәм әһәмиятле жанр икәнлеген бик шәп аңлаган хәлдә дә, аңа мөнәсәбәттә ниндидер ваемсызлык саклап яши бирәбез. Соң, Татарстан җирлегендә гомерләрен «халыкка хезмәткә» дигән бөек һәм изге максатка багышлап, авыр сәфәргә чыккан йөзләгән олы һәм кече язучылардан — әдип һәм шагыйрьләрдән — кемнәр генә бу иң үткен, иң үтемле коралны күтәреп алган да, аның тәэсир көчен чын сәнгать әсәрләре яңгырашы дәрәҗәсенә җиткерә барып, кешеләрнең акыл һәм күңеленә шушы юл белән дә бер өзлексез рухи азык биреп килә? Андыйлар булса да, аларның исәбенә чыгу өчен бер кулның бармаклар саны да җитәр шикелле.

Шагыйрь Әдип Маликовның, матур-матур шигырь һәм поэмалар иҗат итүе белән бергә, художестволы очерклар яза башлавын һәм бу жанрда бер-бер артлы ике китап чыгаруын [1] хуплап каршы алмыйча мөмкин түгел. Һәм һич күпертмичә, һич авырсынмыйча әйтик: Әдип Маликов прозага читләтебрәк караучы яисә аны бөтенләй үги бала сыман күрүче кайбер шагыйрьләр өчен генә түгел, бәлки роман, повесть, хикәя жанрларында иҗат итүче һәм бер уңайдан художестволы очеркны тарсынмыйча җитәкләп алып барырга тиеш булган бик күп прозаиклар өчен дә үрнәк булырдай адымнар ясады.

Шагыйрь прозасы. Нинди икән ул? Шагыйрь күңелен тормышның кайсы яклары, нинди күренешләре һәм ниндиерәк кешеләр дулкынландырган да, йөрәгендә илһам чаткылары кабызып, күргән-белгәннәрен бүтәннәргә сөйләмичә булдыра алмас дәрәҗәгә җиткергән икән? Һәм ул безгә, үзенең укучыларына, аларны ни рәвештә сөйләп бирде, проза теле белән әйтсәк, безнең күңелләргә үтү өчен ниндиерәк юллар сайлап алды икән?..

Ә. Маликовның төпләнеп утырган җире, хәер, утырудан битәр, туктаусыз йөрергә, эзләнергә, ашкынып яшәргә мәҗбүр иткән җире — Әлмәт. Аның поэзиясен һәм менә инде очеркларын да туендырган төп чишмә — «кара алтын» чыгаручылар тормышы, аларның фидакарь хезмәте. Ә нефтьчеләр дөньясы хакында без азмы-күпме булса да беләбез инде: республикабызның бу яклары бертуктаусыз үзгәрештә, гөрләп үсештә, кыскасы, тормыш кайнап тора монда. Ләкин тормыш дигәнебез, утлы учак өстендә утырган казан кебек, үз алдына йомылган, бүтән дөньядан аерылган хәлдә кайнап тормый, әлбәттә. Нефтьчеләр дөньясы күзгә күренгән һәм күренмәгән бихисап җепләр белән бүтән якларга, бүтән тормышларга бәйле. Гомумән, бу дөнья гаҗәп бай һәм катлаулы бәйләнештә яши. Әнә бит бу якларда берсеннән-берсе матур никадәр шәһәр, ничәмә-ничә поселок салынды һәм салынып ята, йөзләрчә чакрымнарга нинди һәйбәт юллар сузылган, ә ил байлыгы «кара алтын» җир тәнендәге сансыз артерияләр буйлап кайларга гына таралмый...

Шулай, мондагы кешеләр, «үз туфрагым — үз байлыгым» дип, бер җирдә генә казанып ятмыйча, туган илнең муллыгын, бәхетен һәм киләчәген чын ирләрчә кайгыртып, фидакарь һәм мөкатдәс хезмәттә яналар. Алар катнашы белән һәм алар ярдәмендә республикабызның төньяк-көнчыгыш почмагында — гүзәл Кама буйларында да җир маеның бай чишмәләре табылды һәм файдаланыла башлады. Ул гына да түгел, Татарстан нефтьчеләре үз араларыннан иң батыр, иң сәләтле ирләрне Ерак Себер җирләренә — кырыс Лена буйларына һәм очсыз-кырыйсыз Төмән сазлыкларына — озатып, анда да чиксез байлыклар табуда булыштылар. Безнең өчен шунысы куанычлы тагы: әнә шул батыр йөрәкле, корыч ихтыярлы кешеләргә ияреп, тынгысыз йөрәкле язучы да атлады.

---

[1] Ә. Маликов. Без кояшны юлда каршылыйбыз. Татарстан китап нәшрияты. 1964 ел.

Ә. Маликов. Кембригә юл салучылар. Татарстан китап нәшрияты. 1965 ел.

Әдип Маликов тарафыннан дөньяга чыгарылган ике китапның исемнәренә генә игътибар итик: «Без кояшны юлда каршылыйбыз» һәм «Кембригә юл салучылар» дип аталганнар алар. Автор исемнәрне китапларның җисеменә бик тә туры китереп куйган. Һәм бу китапларны укыган һәр кеше моны аларның эчтәлегендә дә аермачык тоячак: автор тормышның ритмын һәм үсеш юлларын тирәннән аңлап, вакыйгаларны җанлы, образлы сөйләм белән сурәтләп бирә. Минемчә, Ә. Маликов прозасына иң әүвәл шушы сыйфатлар хас. Әйе, аның геройлары кояш нурларыннан посып, кулагәдә ятучы типлар түгел, бәлки һәрвакыт юлда, хәрәкәттә булган, кояшны һәрвакыт шатлыклы елмаеп, аны һәрвакыт аяк өстендә каршылаучы тынгысыз һәм көчле рухлы кешеләр.

Автор, әсәрләренең жанр үзенчәлеген ачыграк күрсәтү өчен булса кирәк, әлеге исемнәренең беренчесе астына: «Бер сәяхәт язмалары» дип, икенчесенә: «Себергә сәяхәт» дип, җәяләр эчендә искәртеп куйган. Бу хәл шушы ике китапның жанр ягыннан бер-берсенә бик якын, бик охшаш булуына ишарә итә. Өстән караганда, автор хаклыдыр кебек. Беренче китапта без укытучы Мансур һәм аның ике нәни дусты Раушан белән Әлбиналарнең, туган якларын өйрәнү өчен, Кама буйларыннан үзәк нефть районнарына таба сәяхәттә йөрүләрен күрсәк, икенчесендә автор үзе Татарстаннан ерак Лена буйларына нефть эзләргә киткән якташларының хәл-әхвәлләрен белешеп сәфәр йөреп кайта. Шулай да, әсәрләренең корылышы нигезендә охшаш нәрсә ятса да, аларның һәр икесен дә «сәяхәтнамә» дип атау дөрес булырмы икән?

«Без кояшны юлда каршылыйбыз» әсәрен алып карыйк. Монда гаять кызыклы һәм тормышчан вакыйгалар, аерым эпизодлар һәм детальләр бик күп. Сәяхәтчеләр Алабугадан Чаллы, Түбән Кама, Зәй аша Әлмәт шәһәренә сәяхәт иткән чакларында бу калаларның һәркайсында төрле холыклы, төрле язмышлы кешеләр белән очрашалар. Алар бөтенесе дә реаль чынбарлыктан алынганнар, һәм язучы аларны беркадәрле күтәренке тонда, шома гына тел белән сурәтләп, күз алдына китереп бастыра. Арадан Алабуга разведка конторасының турбина цехы мастеры Александр Беляев («Степа абый»), Чаллы шәһәре янында Камадан су алгыч станциянең лаборанткасы Валя Луковецкая, Түбән Кама шәһәренең беренче нигез ташын салучылардан Энәс Сәхабетдинов, Зәй поселогында яшәүче язучы Сөббух Рафиков, Әлмәттән нефтьче инженер Тәлгать Бикчурин кебек кешеләрнең портретлары аеруча җылы һәм тәэсирле язылганнар. Ләкин бу кешеләрнең сурәтләре нихәтле генә җылы һәм тәэсирле бирелмәсеннәр, аларның характерлары үсештә күренми, бертөрле торгынлыкта алына, һәм алар, эпизодик образлар буларак, экрандагы кинокадрлар шикелле, берсен икенчесе алмаштырып үталәр. Реаль тормыштан алынган бу геройлар әсәрнең вакыйгалар тезмәсенә, ягъни сюжет үсешенә дә әллә ни йогынты ясый алмыйлар. Әмма, аның каравы, әсәрдәге төп персонажлар — сәяхәтчеләр чын мәгънәсе белән җанлы әдәби образлар югарылыгында торалар. Болары — язучының хыял җимеше, һәм ул аларны бик яратып, йөрәк җылысын өреп иҗат иткән.

Укытучы Мансур һәм аеруча Раушан белән Әлбинә үзләренең романтик омтылышлары, һәр нәрсә белән тирәннән кызыксынулары һәм кешеләргә мөлаем һәм эчкерсез мөнәсәбәтләре белән укучыда бик әйбәт тәэсир калдыралар. Бу геройларның характерлары да торгынлыкта алынмыйча, вакыйгадан вакыйгага үстерелә килә, аларның уй-кичерешләре тирәнәя, нечкәрә, ә теләк-омтылышлары үскәннән үсә, зурая бара — сәяхәт азагында без бу өч геройның рухи дөньялары шактый ук баеп, нурланып калуын сизәбез. Әсәрнең башы, ахыры бар, беркадәр бүселгәнрәк булса да, кызыклы һәм озын гына сюжеты бар, һәм иң әһәмиятлесе, үсештә сурәтләнгән җанлы геройлары бар. Менә ни өчен аны һич шөбһәләнмичә «повесть» дип атарга мөмкин. Русларда, мондый типтагы әсәрнең жанр билгесен төгәлрәк күрсәтеп, «очерковая повесть» диләр шикелле.

Әсәрнең эстетик тәэсир көче әдәби повестьларныкына якын булганга күрә дә, аны укучылар яратып каршы алды, ул әдәбият җәмәгатьчелегенең дә игътибарын җәлеп итте һәм але бик күптән түгел Мәскәүдә балалар Үзәк нәшриятында рус телендә дә басылып чыкты[1]. Әлбәттә, повестьта инде барысы да әйбәт, җыйнак, пөхтә эшләнгән дип булмый, анда камилләштерәсе яклар байтак әле. Мәсәлән, язучы үзенең төп геройларын маҗаралы хәлләр белән кирәгеннән артык мавыктырмыйча, аларны төрле бәрелешләр, төрле киртәләр аша да уздырса, ягъни характерларын көрәш җирлегендә ача барса, повестьның әдәби-эстетик яңгырашы тагын да көчәер иде.

Монда бер уңайдан повестьның рус теленә тәрҗемәсе хакында да сүз әйтмичә ярамас. Тәрҗемәче К. Семеновның каләме шома гына икән, ул повестьны артык, әһәмиятсез детальләрдән, бүселеп торган урыннардан арындырган, вакыйгаларны җай гына, иплә генә образлы-поэтик тел белән сөйләп бирә алган, гомумән, тәрҗеманең стиле ярыйсы гына әйбәт. Шуның белән бергә, повестьның русча вариантын укыган чакта, эчне пошырган урыннар да очрады. Моны мин әсәрнең эчтәлегенә кертелгән үзгәртүләргә карата әйтәм. Тәрҗемәче, мәсәлән, Зәй поселогында яшәүче язучы С. Рафиков белән очрашу эпизодын ни өчендер төшереп калдырырга кирәк тапкан. Ә бит оригиналда повестьның бу өлеше укучыда гаҗәеп җылы тәэсир калдыра. Аннан соң, тәрҗемәдә сәяхәтнең маршруты да (димәк, әсәрнең сюжет коры-

[1] Э. Маликов. Мы солнце встречаем в пути. Перевод с татарского К. Семенова. Детгиз. 1965 г.

лышы да, житди үзгәрешкә дучар ителгән. Оригиналда сәяхәтчеләр тормыштагыча бик табигый рәвештә Алабугадан Чаллыга һәм Түбән Камага, аннары боларны үткәч кенә Зәй поселогына юл тотсалар, тәрҗемәдә алар, ничектер, Чаллы һәм Түбән Кама шәһәрләрен читләтеп, Алабугадан туп-туры Зәйгә барып эләгәләр һәм монда ясалма күл ярының бетон плитәсендә сәер язу күреп, аның иясен табу нияте белән әлеге шәһәрләргә кире кайтып, маҗара кылып йөриләр. Повестьның сюжет корылышына көчләп тагылган бу үзгәртү андагы вакыйгаларның табигый ялганышын боза, шуның нәтиҗәсендә аңа байтак кына ясалма мотивлар килеп керә. Күрәсең, авторга, повестьның бөтенсоюз аренасына чыгуын истә тотып, тәрҗемәче белән якынрак, тыгызрак һәм таләпчәнрәк мөнәсәбәттә торырга кирәк булгандыр.

Инде «Кембригә юл салучылар» китабына килик. Монысында да без кыю йөрәкле, корыч ихтыярлы кешеләр—Ерак Себер җирләренең бетмәс байлыгын үзләштерүчеләр белән очрашабыз. Ә. Маликов алар турында сокланып сөйли һәм без Лена буенда кембри нефтенә юл ачкан Виталий Ефименко һәм Георгий Соколов, аларга ярдәмгә килгән Татарстан егетләре бораулаучы Исхак Гыйләҗев һәм Мәхмүт Мөхсинов, гомерен Лена елгасында уздырган маякчы эвенк карты Сердиткин һәм аның чая кызы Виктория, Ерак Себернең бер поселогында гаҗәеп бай тарих музее корып җибәргән укытучы Марков кебекләрнең язмышлары, фидакарь хезмәтләре белән танышкач, аларга сокланмыйча булдыра алмыйбыз.

Автор, Себер якларына барып, безгә бик күп, бик кызыклы хәлләр, вакыйгалар һәм күренешләрне күңелгә сеңәрлек итеп тасвирлап бирә. Гомумән, Ә. Маликовның кулъязмаларын һәркем — балалар да, олылар да — яратып укыячак. Шуның белән бергә, әсәрнең сәяхәтнамә генә булуы — жанр тарлыгы — авторның иҗат мөмкинлекләрен бик нык чикләгәнлеге турында да әйтмичә китәргә ярамас. Ә. Маликов Себергә ясаган сәфәреннән нибары үзе күргән, үзе ишеткәннәрне генә яза, ягъни ул вакыйгалар эчендә катнашмый һәм катнаша да алмый. Ул нибары күзәтүче-информатор гына. Бу исә киң планда һәм тирән итеп сурәтләнергә лаеклы геройларны статик хәлләрендә, торгынлыкта алырга мәҗбүр итә. Язучы, үз геройларының рухи һәм интеллектуаль дөньяларын ачып, күрсәтеп бирү урынына, алар хакында хәбәр итү белән генә чикләнә. Мәсәлән, әсәрнең башында гаять тә җанлы, энергияле һәм эрудицияле кеше рәвешендә тәкъдим ителгән бораулау мастеры Владимир Чернозубов бераздан бөтенләй төшеп кала, аны тик Себердә эшләүче иптәшләре генә ара-тирә искә алгалыйлар. Ә бит бу кеше художестволы очеркның уртасыннан атлардай тип. Азакта сәяхәтче, Лена нефтьчеләренең тормышыннан кызыклы гына эпизодларны сөйләп, укучыны шактый ук мавыктырып алганнан соң, кинәттән вакыйгаларны өзеп куя... Ни өчен? Чөнки Әдип Маликов, иҗат командировкасы бетеп, кире үзенең Әлмәтенә кайтып китәргә тиеш...

Шулай да, жанр тарлыгыннан килгән әнә шундый чатаклыклары булса да, бу сәяхәтнамә бай, матур тормышыбызның яңа якларын образлы, пөхтә сөйләмдә ачып бирүе белән, һичшиксез, бүгенге очеркларыбыз арасына игътибарга лаеклы өлеш булып керер.

Бу китаплар шагыйрь Әдип Маликовның зур прозага таба ясаган беренче һәм уңышлы адымнары. Алар авторның прозада да үткен күзле, тапкыр телле һәм романтик рухлы художник булуын раслыйлар. Ләкин Ә. Маликов болар белән генә чикләнмәс һәм бүгенге бай прозабызга тагын да зуррак, тагын да күркәмрәк өлешләр өстәр дип, өметләник. Менә, мәсәлән, тынгысыз йөрәкле бу шагыйрь Ерак Себер якларында янәдән бер булып, ләкин бу юлы инде анда озаграк вакытка тукталып, сәфәр кылып кайтса, зур эшләр башкара алыр иде кебек тоела. Чыннан да, ул элеккеге танышлары белән кабаттан очрашып, күзәтүче булып түгел, үзе дә герой булып алар тормышында кайнаса, үз сүзләре белән әйтсәк, алар белән бергә кояшны көн дә аяк өстендә каршыласа, һәм әнә шул романтик тормыш материаллары нигезендә, ләкин реаль фактлардан югарырак күтәрелеп, гомумиләштерелгән образларга, ышандыргыч көчле характерларга мул булган зуррак күләмле проза әсәрләре язса, начар булыр идемени? Бу теләккә хөрмәтле укучылар да кушылыр дип уйлыйм мин. Шагыйрь һәм прозаик Әдип Маликов моны үзенең укучыларыннан социаль заказ дип кабул итсә икән.

Эдуард КАСЫЙМОВ.

# МӨСЛИМДӘ ШУЛАЙ ЭШЛИЛӘР

*Хәзер — газета-журналларга язылуның иң кызу чоры. «Союзпечать» агентлыкларында һәм элемтә бүлекләрендә эшләүче иптәшләрнең эше иң тыгыз һәм киеренке чак. Менә шул тыгызлык, киеренкелек аркасында подписка квитанциясендә шактый күп төгәлсезлекләр дә ясала торган вакыт бу. Аннары, квитанциядә хата китү нәтиҗәсендә, подписчиклар үзләренә тиешле газета яки журналны вакытында ала алмыйча аптырашалар. Әмма бу хәл бөтен җирдә дә шулай түгел. Партия, комсомол оешмалары көчле һәм элемтә эшчеләре тәҗрибәле булган урыннарда газета-журналларга яздыру бик уңышлы, тәртипле рәвештә үткәрелә, чөнки анда бу эштә җәмәгать тәртибендә матбугат таратучылар бик зур ярдәм итә. Моның шулай икәнлеге «Союзпечать»нең өлкә бүлеге инструкторы В. Суркова мәкаләсеннән дә бик ачык күренә. Түбәндә без шул мәкаләне урнаштырабыз һәм аның «Союзпечать» агентлыкларында, элемтә бүлекләрендә эшләүчеләргә, җәмәгать тәртибендә матбугат таратучыларга ярдәме тияр дип уйлыйбыз.*

Без аларга шундый күнеккәнбез, бер генә көн, нинди дә булса сәбәп аркасында, үзебезгә тиешле газета яисә журналны укый алмый калсак та — зарыгып көткән кадерле кунагыбыз килми калгандай тоела. Һәм бу бик табигый. Илебездәге һәм чит илләрдәге яңалыкларны, үзгәрешләрне әнә шул газета-журналлар китерә бит инде безгә. Язучыларның яңа әсәрләре дә беренче булып шул ук журнал һәм газеталарда басылып чыга. Кыска гына итеп әйткәндә — безне дөньядагы хәлләр белән таныштырып баруда, заман сулышын тоярга ярдәм итүдә газета-журналларның әһәмияте сөйләп бетергесез зур.

Менә шушы әһәмияте әйтеп бетергесез булган вакытлы матбугатны тарату эшен «Союзпечать» һәм почта работниклары башкара. Алар никадәр күбрәк, активрак эшләсә — газета-журналлар халыкка шулкадәр күбрәк тарала. Әмма, күпме генә тырышсалар да, алар барлык теләгән кешеләрдән дә подписка кабул итә алмыйлар. Алар бары тик «Союзпечать» агентлыкларына һәм почталарга килгән кешеләрдән генә подписка кабул итәләр. Ә бит, һич тә сер түгел, үзе тегe яки бу газета яисә журналны укып барырга бик теләсә дә, җитешә алмавы, хәтере начарлыгы, авыру булуы аркасында аңа языла алмый калучылар да күп була. Моның шулай икәнлеге подписка срогы үткәннән соң зинһарлап, тегe яисә бу газета-журналга яздыруны үтенеп, «Союзпечать» нең өлкә бүлегенә килә торган күп санлы хатлардан бик ачык күренә.

Менә шундый җитешә алмый кала торган кешеләрне вакытында газета-журналларга яздыруда «Союзпечать» һәм почта работникларына җәмәгать тәртибендә матбугат таратучы иптәшләр бик зур ярдәм итә алалар һәм күп урыннарда чыннан да шулай эшләнә. Әмма бар җирдә дә тиешенчә түгел. Партия, комсомол оешмалары һәм учреждение,

предприятие җитәкчеләре эшлекле булган, үз эшчеләренең һәм хезмәткәрләренең культура-политик үсеше турында да чын-чынлап кайгырткан урыннарда вакытлы матбугат бик күп тарала. Әлеге оешмалар һәм учреждение, предприятие җитәкчеләре эшне үз агымына куйган җирләрдә исә хәлләр алай мактанырлык булмый.

Бу кечкенә генә мәкаләдә без вакытлы матбугатны таратуда алдынгы урынга чыккан Мөслим районы «Союзпечать» агентлыгының эш тәҗрибәсе хакында кыскача гына сөйләп үтмәкче булабыз.

Әйе, Мөслим районы агентлыгы «Союзпечать»нең өлкә бүлегендә иң алдынгы агентлыкларның берсе булып тора. Мәрзия Шиһаповна Садриева җитәкчелек иткән бу агентлыкта район буенча тарала торган газета-журналларның гомуми саны 26623 данә тәшкил итә. Бер «Казан утлары» журналы гына да районга 583 данә алына һәм аны алучыларның бөтенесе дип әйтерлек бер елга язылган. Район буенча алына торган газета-журналлар 1000 кешегә 832 данә, шул исәптән бер авылга 827 данә, туры килә. Бу бик куанычлы хәл, чөнки мөслимлеләр газета-журналларны башка районнарга караганда күбрәк укый, дөньядагы хәлләр турында күбрәк мәгълүмат ала дигән сүз бу.

Мөслим агентлыгы мондый нәтиҗәгә ничек ирешә соң? Барыннан да элек, бу эштә әйдәп баручы партия райкомы булды. Матбугат тарату мәсьәләсе райком бюросында тикшерелеп, аны уңышлы башкарып чыгу өчен план төзелде. Аннары ул план райондагы җәмәгать тәртибендә матбугат таратучыларга (алар районда 76 кеше), партия, комсомол оешмаларына, почталарга җиткерелде. Аннары: «Бер йорт та газета-журналсыз калмасын» дигән девиз белән матбугат таратучылар эшкә керештеләр. Район газетасы һәм колхоз радиоузеллары аша әледән әле теге яки бу газета яисә журналның характеры турында белешмәләр бирелеп, аларга язылу шартлары аңлатылып барылды. Җәмәгать тәртибендә матбугат таратучылар өй борынча йөреп, аңлату эше алып бардылар һәм бер үк вакытта халыктан подписка да кабул иттеләр. Болай эшләүнең нәтиҗәсе аеруча зур булды, чөнки, әлеге дә баягы, почтага барырга вакыты булмаган кешеләр дә, матбугат таратучы өенә килеп кергәч, бик теләп язылалар иде.

Мөслим районындагы җәмәгать тәртибендә матбугат таратучылардан партоешма секретаре Г. Сабиров һәм укытучы М. Фәтхуллин иптәшләр аеруча зур тырышлык күрсәттеләр. Аларның беренчесе 199 хуҗалыкка 130, икенчесе 209 хуҗалыкка 160 данә газета журналлар таратты.

Мөслим матбугат таратучылары колхозчылар җыелышлары һәм аерым бригада җыелышлары вакытында да халыкка газета-журналларга язылу кампаниясе баруын искәртеп, аңлатып бардылар һәм моның да билгеле бер дәрәҗәдә нәтиҗәсе булды. Авыллардагы почта работниклары исә газета-журналлар турындагы аннотацияләр, рекламалар һәм листовкаларны да бик киң файдаландылар. Бу мәсьәләдә Шуган (начальнигы Е. Кривошеев) һәм Михайловка (начальнигы М. Галимов) элемтә бүлекләре аеруча тырышлык күрсәттеләр һәм нәтиҗәдә Шуган элемтә бүлегендә 1817, Михайловка бүлегендә 1758 данә газета-журнал таратылды.

Кайбер район авылларында почталарны вакытында халыкка тарату эшендә тиешле тәртип юк. Почтальоннарның акрын кыймылдаулары аркасында, газета-журналлар кайчакта икенче көнне генә подписчикка тапшырыла, ә кайчакта бөтенләй югалып кала. Мөслим районы авылларындагы почта бүлекләрендә бу эш тә җайга салынган һәм почтальоннар газета-журналларны һәр йортка вакытында китерәләр. Менә шушы естән караганда бик гади генә булып күренгән хәл дә подписка вакытында уңай тәэсир итә, чөнки подписчик үзе язылган газета-журналның вакытында киләчәгенә шикләнми.

●

Сүзебезне йомгаклап тагын шуны әйтәсе килә: колхоз идарәләре, совхоз дирекцияләре, предприятие һәм учреждение җитәкчеләре квартал саен, ай саен производство алдынгыларын акчалата яисә әйбер белән бүләклиләр. Республикабызның күп кенә колхоз һәм совхозларында шуның урынына соңгы елларда хезмәт алдынгыларын «Казан утлары» журналына еллык подписка белән бүләкләү гадәткә әйләнеп бара. Безнеңчә, бу бик матур башлангыч, чөнки хезмәт кешесе журнал аша әдәбият-сәнгать әсәрләре белән танышып, рухи азык ала. Бу — хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләүнең мөһим чарасы булып тора һәм бу башлангыч киләчәктә тагын да киңрәк колач алыр дип ышанырга кирәк.

**В. СУРКОВА,**
«Союзпечать»нең Татарстан өлкә
бүлеге инструкторы.

## ХӨРМӘТЛЕ УКЫТУЧЫ!

1967 нче елга «СОВЕТ МӘКТӘБЕ» журналына язылу дәвам итә. Без сине, хөрмәтле укытучы, үзеңнең журналыңа язылырга һәм аны даими рәвештә укып барырга чакырабыз.

Журналда башлангыч, сигезьеллык һәм урта мәктәп укытучылары, класс һәм мәктәп җитәкчеләре, өлкән пионервожатыйлар, тәрбиячеләр, халык мәгарифе бүлекләре мөдирләре, инспекторлары, гомуман, барлык мәгариф работниклары өчен көндәлек эшләрендә ярдәм булырлык материаллар урнаштырыла, алдынгы мәктәпләрнең, укытучыларның, класс җитәкчеләренең һәм тәрбиячеләрнең уңай тәҗрибәсе киң яктыртыла.

«СОВЕТ МӘКТӘБЕ» журналында коммунистик тәрбия, хезмәткә өйрәтү, аерым фәннәрне укыту буенча методик эшкәртмәләр, укыту планнарына һәм программаларына аңлатмалар, татар мәктәпләрендә рус теле һәм әдәбиятын, чит ил телләрен укыту турында методик мәкаләләр, шулай ук укыту рус телендә алып барыла торган татар мәктәпләренең тәҗрибәсен гомумиләштерүче материаллар басыла.

Журналда «Мәктәп һәм семья», «Врач киңәшләре», «Фән һәм техника яңалыклары», «Планета буйлап» дигән һ. б. бүлекләр дә бар. Бу бүлекләрдә урнаштырылган материаллар укытучыларның белемнәрен киңәйтүдә һәм ата-аналарга бала тәрбияләүдә ярдәм итә. «Консультация» бүлегендәге материалларда укытучыларның күп санлы сорауларына җаваплар бирелә.

**ЯЗЫЛУ БӘЯСЕ:**

бер елга — 3 сум,
алты айга — 1 сум 50 тиен.

Урыннарда журналга подписка алмасалар, акчагызны түбәндәге адрес белән җибәрегез:

*Казань, Куйбышева, 17/25, областной отдел „Союзпечати". Для подписки на журнал „Совет мәктәбе".*

Теге яки бу сәбәп белән аңлашылмау чыкса, редакциягә белдерегез:

Безнең адрес: *Казань, почтамт, п/я 58. Редакция журнала „Совет мәктәбе"*

*„Совет мәктәбе" журналы редакциясе.*

# Яңа китаплар

### Гамир Насрый

**САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР**

*Бәясе 87 тиен.*

Гамир Насрый — нибары кырык өч ел гына яшәсә




дә, шактый зур әдәби мирас калдырган язучы. Аның дүрт дистәгә якын сәхнә әсәре бар; матбугат битләрендә бик күп шигырьләр, жырлар, хикәяләр һәм очерклар бастырган әдип ул.

Тууына илле ел тулу уңае белән Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган «Сайланма әсәрләр»ендә Гамир Насрыйның «Кушнарат», «Кушамат» исемле комедияләре, «Кадерле минутлар» пьесасы, «Яшел эшләпә» водевиле, «Кайту» һәм «Котлыбаев тәнкыйть итә» хикәяләре һәм утызлап жырлары урнаштырылган. Бер сүз белән әйткәндә, жыентык Гамир Насрый иҗатын шактый тулы күз алдына китерерлек итеп төзелгән һәм ул язучының әсәрләрен сәхнәгә куярга теләүчеләр өчен дә бик кулай материал булыр.

### Илдар Юзеев

**ПОЭМАЛАР**

*Бәясе 13 тиен.*

**Нигә икән**
**Яшьлек елларында**
**Сөйгән ярлар авыр табыла?**
**Ә мәхәббәт уты бер кабынса,**
**Сүрелмәслек булып кабына.**




**Бер-береңә булмый туры карап,**
**Аңлашалмый йөдәп бетәсең,**
**Серләреңне ачып бирү өчен**
**Уңайлы бер вакыт көтәсең.**

Шагыйрь Илдар Юзеевның бу яңа жыентыгына урнаштырылган «Миләүшә» исемле поэмасы менә шушылай башланып китә дә, һаман саен вакыйгалары куера барып, укучының күңелен тәмам үзенә жәлеп итеп ала һәм әсәр укылып беткәнче аны киеренке хәлдә тота. «Миләүшә»дән тыш, И. Юзеевның бу жыентыгында тагын ике поэмасы («Таймас», «Өчәү чыктык ерак юлга») басылган. Моңарчы беркайда да басылганнары булмаган әлеге поэмаларның өчесе дә, И. Юзеев каләменә хас булганча, нечкә лиризм белән сугарылган. Поэмалар жиңел укыла һәм мавыктыргыч сюжетка корылганнар.

### Зәки Нури

**ЕЛМАЯБЫЗ ҺӘМ КӨЛӘБЕЗ**

*Бәясе 17 тиен.*

Бик күп шигырь жыентыклары авторы, шагыйрь Зәки Нуриның әле күптән түгел генә дөньяга чыккан



яңа китабы «Елмаебыз һәм киләбез» дип атала. Чәнечкеле шигырьләр, мәсәлләр, фельетоннар һәм шаярулардан торган бу китапның жисеме дә исеменә бик туры килеп тора: жыентыктагы теләсә кайсы әсәрне алып укысаң да — елмаймыйча янсә көлмичә калып булмый. Бер генә мисал китерик:

**Мактанды күсе кыюлык**
**белән:**
**«Мәче муенына кыңгырау**
**элэм!**
**Ант итеп әйтәм, бу житди**
**сүзем!» —**
**Дигәндә мәче юк итте үзен.**

Рәдиф Гатауллин

## ГӨЛЛӘР СУ СОРЫЙ

*Бәясе 8 тиен.*




Рәдиф Гатауллин соңгы елларда әдәбият мәйданына чыгып, үз фикерләрен шактый нык итеп әйтә башлаган яшь шагыйрьләрнең берсе. Моңарчы үзенең матур-матур шигырьләрен вакытлы матбугат битләрендә генә бастырып килгән бу яшь шагыйрьнең инде менә беренче китабы да дөньяга чыкты. «Гөлләр су сорый» исемле ул жыентыктагы шигырьләрне укыгач, күңелдә шундый тәэсир кала: яшь шагыйрь Рәдиф Гатауллин тормышны белеп яза, укучыны уйландыра торган итеп яза һәм үзенчә яза:

**Башта сине мин**
**сөймәдем әле,**
**Тик ошадың миңа.**
**Ятлар: «Син сөясен**
**аны»,— диде**
**һәм ышандым моңа.**
**Бернәрсә дә сиздермәдем**
**сиңа,**
**Сиздерделәр ятлар.**
**һәм синнән дә бер көн**
**«сөям» сүзен**
**Китерделәр ятлар.**
**Без беркайчан да күрешеп**
**сөйләшмәдек.**
**Утлар инде янды.**
**...Ятлар бирде безгә бу**
**сөюне,**
**Ятлар кире алды.**

*(«Ятлар бирде, ятлар алды», 39 бит.)*

Резеда Вәлиева

## КАНАТЛЫ ЖАЙДАК

*Бәясе 9 тиен.*

Резеда Вәлиеваның кече яшьтәге мәктәп балаларына адресланган бу китабына шактый зур күләмле, жинел укыла торган «Канатлы жайдак» исемле поэма һәм шигырьләр тупланган. Китап художник В. Зеленский тарафыннан бик әйбәт иллюстрацияләнгән.




Ибраһим Нуруллин

## ТУКАЙ ТУРЫНДА ХИКӘЯЛӘР

*Тиражы 10 000 данә. Бәясе 32 тиен.*

Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Ибраһим Нуруллин, Габдулла Тукай ижатын фәнни өйрәнү белән бергә, сөекле шагыйребезнең якты образын матур әдәбият әсәрләрендә мәңгеләштереп калдыру буенча да тәжрибәләр алып бара. Байтак еллар элек без аның «Тукай Петербургта» исемле пьесасын укыган идек. Соңгы елларда И. Нуруллин Габдулла Тукайга ба-




гышланган күп кенә хикәяләр язды. Ул хикәяләрнең кайберләре белән укучылар таныш инде. Алар үз вакытында «Совет әдәбияты» журналында, «Социалистик Татарстан», «Татарстан яшьләре», «Комсомолец Татарии» газеталарында басылып та чыктылар.

Быел, Габдулла Тукайның тууына 80 ел тулуга багышланган тантана көннәрендә, Татарстан китап нәшрияты Ибраһим Нуруллинның халык шагыйре турындагы хикәяләрен укучыларга аерым китап рәвешендә тәкъдим итте. Жыентыкта 10 хикәя тупланган. «Күзге жилләр исәр алдыннан», «Гарифов ничек Тукаевка әйләнде», «Сабыйлык үче», «Ике Апуш», «Карахмәт», «Фабрикант һәм шагыйрь», «Шомлы төн», «Чуар киез итек», «Ирек тәме», «Башкала белән саубуллашканда» дип исемләнгән ул хикәяләр халык шагыйре Габдулла Тукайның тормышын, ул яшәгән һәм ижат иткән чорны тагын да тирәнрәк, ачыграк аңларга ярдәм итәчәкләр.

Китап яхшы тышлыкта чыгарылган, художник Н. Хантемиров ясаган рәсемнәр белән иллюстрацияләнгән.

# Укучылар сүзе

## «Казан утлары»

Бер дустым бар Казан шәһәрендә —
Бүләк итте «Казан утларын».
Куаныч бар минем йөрәгемдә
Булган өчен шундый дусларым.

Сәхрәләрдә арып су көткәндәй,
Көтеп алам хәзер журналны.
Сусаган гөлләргә су сипкәндәй,
Баса минем рухи сусауны.

Күп яктылык бирә ул халыкка:
Киң җәелә аның нурлары.
Илнең матурлыгын ныграк чәчеп,
Балкып торсын «Казан утлары».

**Мөбинә ТАҺИРОВА.**
Мәскәү.

●

«Казан утлары»ның һәр номерын мин игътибар белән укып барам. Соңгы вакытларда яшьләр поэзиясенә игътибар көчәйде — бу безнең өчен бик шатлыклы.

Журналның май санында басылып чыккан поэзия әсәрләреннән миңа Рәшит Гатауллин шигырьләре ошады: ягымлы лирикасымы, артык катлаулы булмаган фәлсәфәсеме — нәрсәсе беләндер бу иптәш бик әйбәт тәэсир калдырды.

Ләкин шул ук санда басылган З. Шәйхулов, Е. Уткиннарның шигырьләре поэзиягә яңалык китермиләр кебек. Уртача гына шигырь тәэсире калдырдылар.

...Яшьләр поэзиясе турындагы бәхәсләр соңгы арада басыла төште. Без, укучылар, аны бик кызыксынып күзәтеп бардык, ул бәхәсләр бер тирәдәрәк барды бугай: һаман шул Фәйзуллинның «Нюанслар иле»... Ләкин чын мәгънәсендә тәнкыйтьләнергә тиешле күп әсәрләр бәхәс ышыгында калды, безнеңчә.

Йөрәкнең тибешен үзгәртерлек, хисләргә резонанс ясарлык шигырьләр укыйсы иде.

**Разиль ВӘЛИЕВ,**
Казан университетының журналистика
бүлеге студенты.

●

«Казан утлары»нда басылган проза әсәрләрен бик яратып укыйм.

А. Расихның «Ике буйдак», Ф. Хөснинең «Минем тәрәзәләрем», Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр», Ш. Маннурның «Муса» кебек әсәрләре миндә көчле тәэсир калдырган иде.

Быелгы елда роман, повестьлар азрак басыла дисәм киләп.

Без, журналны укучылар, түземсезлек белән яңа әсәрләр көтеп калабыз. «Казан утлары»на тирән мәхәббәтебезне юллыйбыз.

Тәхәви МӘКСУТОВ.
Башкортстан,
Борай районы.

●

Кадерле редакция!

Шушы шигырь юлларым сезгә, хөрмәтле язучыларыбызга, Татарстаннан читтә яшәүче укучыгызның кайнар сәламе, рәхмәте булсын!

Мин телимен күптән, күптән инде
Сиңа барып башым иярга.
— Чәчкән нурың өчен сиңа, Казан
Чын күңелдән рәхмәт, диярга.

Без тыңладык синнән килгән моңны
Таулар, тайга, дулкын аркылы.
Йөрәгемә «Казан утлары»
Төньяк балкыш булып балкыды.

Бер барырмын.
Каршыларсың, Казан,
Сиңа барып башым иярмен.
Синнән ерак татар исеменнән
«Һәммәсе өчен рәхмәт!» диярмен.

Мәҗит КӘРИМОВ,
офицер.
Львов өлкәсе.

—●●—

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЖУРНАЛ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Татарстан язучылары союзы правлениесенең киңәйтелгән утырышында 22 июль көнне «Казан утлары» журналының быелгы 3, 4, 5, 6 нчы саннарында басылган әсәрләр турында фикер алышу булды. Утырышта чыгыш ясаган иптәшләр әдәбиятның бүгенге торышына, андагы уңай һәм кимчелекле якларга үзләренең мөнәсәбәтләрен белдерделәр, күп кенә практик тәкъдимнәр керттеләр. Журналга гомуми күзәтү ясаган **Л. Ихсанова** фикерләре дә, нигездә, шул юнәлештә барды.

— Шуны әйтергә кирәк, — диде ул, — без инде журналны примитивлыкта, басылган әйберләрнең художество ягыннан түбән булуында, зәвыксызлыкта гаепли алмыйсыз. Журнал югары зәвыклы укучыларның таләпләрен канәгатьләндерә алырлык. Менә А. Гыйләҗевның «Бәрәү» повесте басылып чыкты. Туган җирне ярату, гади крестьян хезмәтенә мәхәббәт һәм, шуның белән бергә үк крестьянның үз хезмәтеннән тәм тапмый башлавы, җирдән күңел сүрелү фактларының сәбәпләрен ачарга тырышкан автор. Дөреслекне күзгә карап әйтергә курку, үз иминлегеңне саклар өчен дәшми калу никадәр аянычлы хәлләргә китерүен дә язучы ышандырырлык дәлилләрдә сурәтләп бирә.

Әсәрнең уңышлы якларын күрсәткәннән соң Л. Ихсанова авторның тиешле урыннан алдарак нокта куюын, кайбер фактларны ахырына кадәр ачыкламавын тәнкыйть итте. Аннары И. Газиның «Канатланыр чак», Г. Гобәйнең «Корьән серләре» повестьлары, Г. Мөхәммәтшинның «Изге Галиәкбәр» хикәясе, С. Батталның «Чирмешән якларында» исемле шигъри романы, С. Сөләймpraovаның «Язылмаган җырлар» поэмасы һәм башка шагыйрьләрнең шигырьләре, яшьләр иҗаты хакында сөйләде, И. Нуруллинның «Шагыйрьне өйрәнү юлында» мәкаләсен тәнкыйтьләде.

Аннан соң «Казан утлары» журналының җаваплы редакторы **Р. Мостафин** тыңлаучыларны журналның алдагы эш планы белән таныштырды.

— Быел безнең редакциядә проза әсәрләренә урожайлы ел булмады. Танылган язучылардан зур җитди әсәрләр көткән идек. Ләкин ул әсәрләр сыйфатлары ягыннан журналны канәгатьләндерә алмадылар. Хикәяләр мәсьәләсендә дә шундый ук хәл. Шуның аркасында кайвакыт бик үк пешеп җитмәгән әсәрләрне дә басарга мәҗбүр булдык. Материаллар күп, ә сыйфат ягыннан югары таләп белән килгәндә алар юк дәрәҗәсендә аз булып чыга.

И. Нуруллинның Тукайга карата дискуссия тудырган мәкаләсен урнаштыру, — диде Р. Мостафин, — әлбәттә, минем хата һәм редакция хатасы. Кайбер сәбәпләр буенча, мәсьәләне ашыгычрак хәл итәргә туры килде. Шунысы да бар: безнең журналда үткен темаларга дискуссияләр булырга тиеш. Өлгергән темалардан бөтенләй баш тартсак, дөрес булмас иде. И. Нуруллин мәкаләсе уңае белән килгән материаллар Тукай иҗатын һәм биографиясен ачарга ярдәм итәләр. Бу яктан бәхәснең файдасы тиде, дияр идем.

Редколлегия члены **Ш. Маннур** болай диде:

— Редколлегия члennары арасында коллегиальлек юк димәс идем мин. Без үз утырышларыбызда күп кенә бәхәсле әсәрләр тикшердек. Ә. Еники хикәяләрен, Н. Фәттахның «Артта калган юллар» хикәясен ныклап тикшердек. А. Расихның «Каһарманнар юлы» романын, Г. Минскийның «Яшенле яңгыр» повестен барыбыз да укыдык. Соңгы вакытта Ф. Хөснинең «Язмыш шуклыгы» повесте буенча авторга киңәшләр әйттек. Санып башласаң, күп җыела. Ләкин И. Нуруллинның 3 нче санда басылган мәкаләсен редколлегия членнарының күбесе укымаган. Ә аны безгә укырга кирәк иде. Бу әйбер безнең күңелгә сеңгән Тукайны җиргә сеңдерү нияте белән язылган. Юбилейга килгән кунаклар да безгә: сез әле Тукайның никадәр бөек икәнен белмисез, диделәр һәм бу бик дөрес әйтелгән сүз.

Утырышта чыгыш ясаган күпчелек иптәшләр И. Нуруллин мәкаләсендәге җитди кимчелекләрне билгеләп үттеләр.



Шагыйрьнең Тукай-Кырлай авылындагы һәйкәле янында кунаклар.

— Шушы бер ике ел эчендә, — диде **Г. Бакиров,** — журнал киң эчтәлекле булып чыгуы белән укучыларны кызыксындыра. Районнарда йөргәндә дә, укучылар белән очрашканда да шуны күрдек. Аны авыл интеллигенциясе, ферма эшчеләре, механизаторлар яратып укыйлар. Былның берен че яртысында күзгә күренерлек әйберләр дән И. Газиның «Канатланыр чак», А. Гый ләжевның «Берәү» һәм Г. Гобәйнең «Корьән серләре» повестьларын әйтер идем.

Тел белеме өлкәсендә әле бернәрсә д. күренгәне юк. Киләчәктә журнал бу якк да игътибар итсен иде.

Татарстан язучылары союзы правлениесе председателе **М. Әмир** журнал турында уңай фикерләр әйткәннән соң эштәге кимчелекләргә тукталды:

— Югары таләп мәсьәләсен без барыбыз да бертөрле аңламыйбыз булса кирәк. Язучылар арасында художество таләпләрен ике төрле позициядә аңлаучы иптәшләр бар. Яшьрәк буыннан башланды ул нәрсә: тормышта нинди факт бар, шуны язу. Ә нәтиҗә ясау укучының үз эше санала. Шундый караш аркасында И. Нуруллин мәкаләсе кебек әйберләр дә килеп чыга. Анда да, дөреслекне язам дип, образның кирәкмәгән ягын да күрсәтү тенденциясе бар. А. Гыйләжев иҗатына да шул ук тенденция хас. Ул талантлы иптәш. «Үги ана яфраклары» хикәясе аның зур талантка ия икәнлеген күрсәтә. «Берәү» повестеның да бик әйбәт урыннары бар. Ләкин, чынлабрак карый башласаң, бик таркау әсәр. Бер дә сайлап тормыйча гына, тормышта булган фактларны язып бара. Нинди фәлсәфә, нинди идея үткәрәдер автор. Культ чоры тудырган кимчелекләрне кабатлау шаблонга әйләнә башлады. А. Гыйләжев үз иҗатында тигез бармый. «Зәй энжеләре»ндә максат ачык иде. Ә бу әсәрендә физик һәм рухи яктан гарип образлар алына... Олы язучыларыбыз арасында, нечектер, үзләренең әлектән яшәп килгән иҗат принципларына каршы булырак икенче бер юналеш күрәм мин... вәрым иптәшләрдә яшьләргә ярдәм итү мәсьәлә-

сендә ваемсызлык сизәм. Безгә иҗат принциплары турында күбрәк һәм тирәнрәк сөйләшергә кирәк. Тәнкыйтьчеләр секциясенең житәрлек эшләмәве моңа комачау итә. Бүгенге замечаниеләрдән редколлегия һәм редакция тиешле нәтиҗә ясарлар, дип ышанам.

Утырышта шулай ук иҗади мәсьәләләр буенча И. Гази, Р. Нафиков, Ф. Хөсни, К. Фасеев, Г. Минский, И. Нуруллин һәм башка иптәшләр чыгыш ясады.

## АРЕНАДА — 50 ЕЛЛЫК

Казанның В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Үзәк стадионында 2—3 июль көннәрендә Мәскәүнең массовый тамашалар театры чыгыш ясады. Музыка бәйрәме совет властеның 50 еллыгы темасына багышланган иде. Башта аренада Владимир Ильич Ленин образы гәүдәләндерелеп, аның речендә (артист Д. Массанов) беренче эшчекрестьян дәүләтенең тынычлыкны яклауга юнәлдерелгән тышкы политикасы яңгырады. Тынычлык өчен көрәш идеясе театр программасының башыннан ахырынача дәвам итте.

Халкыбызның гражданнар сугышында җиңеп чыгуы балет труппасы башкарган дуслык биюендә чагылды.

Беренче бишьеллыклар чоры С. Мартинсон, Г. Дударев, З. Федорова, И. Смирнова, А. Стрельченко чыгышлары аркылы бирелде. Илебезнең Бөек Ватан сугышында җиңеп чыгуы күп кенә артистлар иҗатында, аеруча киноартистлар Б. Андреев һәм М. Бернес чыгышларында әйбәт тасвирланды.

Танылган артистларыбыздан О. Стриженов һәм М. Стриженованың «Кигәвен», З. Федорова һәм И. Макарованың «Хатынкызлар» фильмнарыннан өзекләр башкаруы, М. Пуговкинның юмористик чыгышы, украин артисты Ю. Гуляев җырлавы һәм башка номерлар да көчле алкышлар белән каршыланды.

## ГАСТРОЛЬЛӘР, КУНАКЛАР

Казанга Башкорт дәүләт академия театры килде. Аның спектакльләре Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында барды.

Коллектив үзенең гастрольләрен М. Кәримнең «Ай тотылган төндә», Ф. Вольтерның «Мөхәммәт» трагедияләре белән башлап җибәрде.

Кунаклар, бу әсәрләрдән тыш, «Кара йөзләр», «Солдат улы», «Йөрәк белән шаярмыйлар», «Кеше бәхете», «Законлы никах белән», «Караңгылык хөкем сөргәндә» спектакльләрен дә алып килгән иде.

* * *

А. С. Пушкин исемендәге Магнитогорск драма театры 2—3 июльдә В. И. Качалов исемендәге Зур драма театры бинасында Казан тамашачыларын үзенең «Гамлет» спектакле белән таныштырды. Театр репертуарында «Ата хакы — тәңре хакы», «Прометейга һөҗүм», «Яктырта, ләкин җылытмый» һәм башка спектакльләр бар иде.

* * *

Кузбасс оперетта театры гастрольләре М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры бинасында үтте.

Кунаклар казанлыларга Ф. Лоуның «Минем гүзәл Леди», Н. Рябовның «Сорочинск ярминкәсе», О. Сандлерның «Таң атканда», Ф. Легарның «Шат күңелле тол хатын», Б. Александровның «Малиновкада туй», Ф. Легарның «Чегән мәхәббәте», Ж. Оффенбахның «Герцогиня Герольштейнская» һәм И. Кальманның «Цирк принцессасы» әсәрләре буенча эшләнгән спектакльләр күрсәтте.

* * *

М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры Петрозаводск музыкаль-драматик театры бинасында үзенең гастрольләрен Римский-Корсаковның «Патша кәләше» операсы белән тәгәлләде. 17 көн эчендә Татарстаннан килгән кунаклар сәнгате белән 12 меңнән артык кеше танышты.

Карелия АССР газеталары битләрендә безнең күренекле солистларыбызның уңышка ирешүләре, хор, оркестр һәм балет труппаларының уңышлы чыгышлары турында мәкаләләр басылып чыкты. Ул мәкаләләрдә татар сәнгатенең күренекле үрнәкләре «Җәлил» (Н. Җиһанов) операсына һәм Ф. Яруллинның «Шүрәле» балетына аеруча игътибар бирелде.

## КОМПОЗИТОРГА — МАКТАУЛЫ ИСЕМ

Үзенең җырлары, романслары, инструменталь һәм хор, оркестр өчен язган күп әсәрләре белән Исмай Шәмсетдинов — халык күңелендә урын алган композиторларның берсе. Татар халык көйләрен җыю, аларны эшкәртү, үзешчән сәнгать коллективларына ярдәм итү буенча да ул файдалы эш алып бара. Шундый күпьеллык иҗади хезмәтләре өчен Татарстан АССР Верховный Советы композитор Исмай Шәмсетдиновка Татарстанның атказанган культура эшлеклесе дигән мактаулы исем бирде.

## ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР, ИҖАДИ КОМАНДИРОВКАЛАР

Июнь — сабан туйлары белән ямьле. Бәйрәмнәр, басуларда мул уңыш көтү шатлыклары белән берләшеп, авыллардан авылларга күчеп йөрде, республикабызның башкаласы Казанга килеп житте. Халык тормышы, аның уйлары, хыяллары, кичерешләре белән яшәгән язучылар бу тантаналы көннәрдә үз укучылары белән бергә булдылар. Язучылардан Г. Бәширов һәм Х. Вахит Саба районына, С. Хәким — Арча, Р. Ишморат — Актаныш, И. Юзеев — Сарман, И. Нуруллин белән С. Сабиров

Питрәч районына барып укучылар белән очраштылар, бәйрәмнәрдә катнаштылар.

Татарстан язучылар союзы идарәсе бу иптәшләргә сабан туйларын оештыру һәм үткәрү тәҗрибәсен өйрәнү һәм гомумиләштерү бурычын йөкләгән иде.

* * *

Яшь һәм башлап язучыларга ярдәм — союз идарәсенең даими эше. Шул эшнең бер формасы буларак, язучылар районнардагы әдәби түгәрәкләргә җитәкчелек итәләр, алар белән бәйләнеш тоталар. Язучы Г. Галиев, июнь аенда Баулы һәм Азнакай районнарындагы әдәби түгәрәк утырышларында катнашып, анда КПССның XXIII съезды карарлары, колхоз тормышы һәм әдәбиятка кагылган яңа бурычлар хакында әңгәмә уздырды.

Мөслим һәм Сарман районнары әдәби түгәрәкләрендә шундый ук мәсьәләләр буенча драматург Р. Ишморат, Тәтеш районында Г. Паушкин, Түбән Кама районында яшь шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов чыгыш ясады.

* * *

Казанга укытучыларның белемен күтәрү институтына Татарстан АССР районнарыннан һәм РСФСР өлкәләреннән килгән башлангыч мәктәп укытучылары үзләренең бер җыелышларына бер төркем язучыларны чакырдылар. Анда Л. Ихсанова, Ә. Бикчәнтәева, Г. Бакиров, М. Фәйзуллина, С. Шакир үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

Шул ук институтта үткәрелгән икенче бер очрашу республикабыз мәктәпләрендә класс җитәкчесе булып эшләгән укытучылар белән үткәрелде. Алар каршында Б. Камалов, Г. Гобәй, Н. Юзеев, Р. Гатауллин чыгыш ясадылар.

* * *

Язучы Н. Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» китабы буенча Казан гарнизоны хәрби частенда укучылар конференциясе оештырылды. Конференциягә автор үзе дә катнашты.

* * *

Актаныш районының Пучы авылында, Нур Баян исемендәге колхозда Бөек Ватан сугышында һәлак булган патриот шагыйрь Нур Баянга якташлары олы хөрмәт күрсәтәләр, аның исеме белән горурланалар. Июнь аенда монда шагыйрьгә салынган һәйкәл тантаналы төстә ачылды. Митингта драматург Р. Ишморат шагыйрь һәм батыр сугышчының үлемсезлеге хакында сөйләде.

* * *

Ю. Белостоцкий, М. Фәйзуллина Культура работниклары профсоюзының Васильево поселогындагы пионерлар лагеренда ял итүче балаларга үзләренең әсәрләрен укыдылар.

Г. Мөхәммәтшин Минзәлә районындагы пионер лагерьларында булды.

* * *

«Казан утлары» журналы редакторы, әдәби тәнкыйтьче Р. Мостафин июль аенда Баулы, Әлмәт һәм Лениногорск районнарында укучылар белән очрашты һәм аларны әдәбиятыбыз үсешендәге яңалыклар белән таныштырды, журнал битләрендә басылачак әсәрләр турында сөйләде.

Июль аенда Р. Мостафин Фрунзе шәһәренә барып кайтты. Ул, Кыргызстан язучылары съездында чыгыш ясап, кыргыз язучылары әсәрләре турында үз фикерләре белән уртаклашты, әдәбиятларыбыз дуслыгы хакында сөйләде.

* * *

Шагыйрь Х. Камалов, Бөгелмә, Әлмәт һәм Лениногорск районнарына барып, укучылар белән очрашты.

* * *

Казанның М. Горький исемендәге үзәк культура һәм ял паркында инде традициягә кереп киткән китап бәйрәме үткәрелде. Ачык эстрадада Р. Ишморат, Р. Гәрәй, Ә. Бикчәнтәева, Р. Әхмәтҗанов, С. Шакир яңа әсәрләрен укыдылар һәм китап сәүдәсе вакытында сатып алучыларга үзләренең автографлары белән китаплар бүләк иттеләр.

Кичәгә яшь авторлардан Ә. Гайнуллин һәм Р. Хисмәтуллин да катнашты.

* * *

Июль аенда Ә. Еники үзенең язылачак әсәрләренә материал туплау өчен Уфага һәм Башкортстан АССР районнарына барып кайтты.

* * *

Түбән өлкәсенең Аслана урта мәктәбе укучылары Р. Мостафин, З. Нури һәм яшь язучы Х. Гарданов белән очраштылар.

* * *

Казанга кунак булып килгән гарәп язучысы Сахиб Жамал Аккош күлендәге «Солнечный» исемле пионер лагеренда ял итүче балалар белән әңгәмә үткәрде. Очрашуга аның белән бергә Н. Дәүли һәм С. Сабиров килгән иде.

* * *

Шагыйрь Ш. Галиев, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының татар әдәбияты бүлеге студентларының халык иҗатын өйрәнү экспедициясе белән берлектә, Свердловск өлкәсе авылларында булды. Экспедициягә университет укытучысы, тәнкыйтьче Н. Юзеев җитәкчелек итте.

* * *

Казандагы органик синтез заводы тезелешендә әдәбият һәм сәнгать белән кызыксынучылар байтак. Алар язучыларның яңа әсәрләрен укып баралар. Шигырь, хикәя, очерк язарга омтылучылар да бар. Татарстан язучылар союзы идарәсе яшь авторларга булышу нияте белән «Төзүче» газетасы редакциясе каршында әдәби түгәрәк оештырырга карар бирде һәм язучы Б. Камаловны түгәрәкнең җитәкчесе итеп билгеләде.

27 июль көнне М. Садри, Б. Камалов, Н. Гайсин, С. Гәрәева Казанның органик синтез заводын төзүчеләр янында булдылар һәм үзләренең әсәрләрен укыдылар, башлап язучыларга художество осталыгына кагылышлы фикерләр әйттеләр.

## Алдагы саннарда:

С. Рафиков. Авыл иртәсе. Романнан өзек.
С. Таҗетдинов. Үлемнән яшәүгә. Документаль повесть.
Хикәяләр.
Ш. Галиев, Ә. Ерикәй, З. Нури, Б. Сөләйманов шигырьләре.
Җ. Рәхимов. Кобзарь — Тукай кунагы. Очерк.
С. Алишев. Пугачев полковнигы. Очерк.
Ф. Мусин. А. Расихның иҗат портреты.
Н. Исәнбәт. Халык авыз иҗаты материаллары.
М. Мәһдиев. С. Рахманколый иҗаты турындагы фикерләр.
Г. Ибраһимовның тууына 80 ел тулуга карата мәкаләләр, истәлекләр.
Китап күзәтү.
Тәрҗемәләр.
Редакция почтасыннан.
Интермедияләр.

Җаваплы редакторы Рафаэль Мостафин

Редколлегия: Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники,
Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский,
Сибгат Хәким, Нил Юзиев


Производствога бирелде 15/VII-1966 ел. Басарга кул куелды 22/VIII-1966 ел. ПФ 09383. Кәгазь форматы $70 \times 108^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 34800 экз. Заказ Н-1001.
Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1966 ел.

# ОНЫТМА

А. КЛЮЧАРЕВ музыкасы

Н. ДӘҮЛИ сүзләре



1. Гел сине уйлыйм мин,
   Гел сине сагынам,
   Бәхетем син генә дөньяда.
   Шәл салып җилкәңә,
   Зәңгәрсу кичләрдә
   Чык әле, чык әле җырымны тыңларга.
2. Бу җырым тик сиңа,
   Син тыңла, син тыңла,
   Йөрәкнең сагышы бу җырда,
   Кайгылы көнеңдә,
   Караңгы төнеңдә
   Мин телим, мин телим юлдашың булырга.
3. Инде хуш, димә син,
   Юлымны өзмә син,
   Соңгы кат сау бул, дип озатма.
   Чакырсаң килермен,
   Кулымны бирермен,
   Булсам да, булсам да еракта, еракта.
4. Кайгылы чагыңда
   Булырмын яныңда,
   Йолдызлар сүнмәсен офыкта,
   Бар сине сөйгән дус,
   Бәхетем дигән дус,
   Онытма, син шуны онытма, онытма.

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

Индекс
73210

*Ежемесячный литературно-художественный*
*и общественно-политический журнал*

**КАЗАН УТЛАРЫ**

*(Огни Казани)*

**ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ**